ШУРА

№ 21
2018

2000795269987

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

ЭЧТӘЛЕК

ВӘГАЗЬЛӘР

Дога кабул булу ихтималы зур булган мизгелләр 6
Болгар җирләрен зиярәт итүнең әһәмияте 10
Дөнья – ахирәтнең кыры 17
Аның әхлагы Коръән иде 23
Зөлхиҗҗә аеның фазыйләтләре 29
Корбан чалу Аллаһка якынайта 35
Корбан гаете хөтбәләре 40
Корбан гаете хөтбәсенең кириллицага транскрипциясе 44
Беренче хөтбә 44
Икенче хөтбә 45
Корбан гаете хөтбәсенең тәрҗемәсе **47**
Беренче хөтбә 47
Икенче хөтбә 49
Корбан гаете вәгазе 51
Ир-атның гаиләдәге вазифасы 62
Гыйлем алуның фазыйләтләре 69
Мөхәррам ае һәм Гашурә көне 78
«Хизбүт-тәхрир» – адашканнар хәрәкәте 89
Баһһабилар – кемнәр алар? 95
Хариҗиләр һәм аларның дәвамчылары 100
«Сез иң галим кеше икәнсез» 105

СОРАУ-ҖАВАП

Әҗәтле үлмәсме? 113
Гайбәт кайсы очракларда рөхсәт ителә? 116

ҮРНӘК ЗАТЛАР

Икенче тугры хәлифә – Гомәр разыйаллаһу ганһү 119
Хафса бинте Гомәр разыйаллаһу ганһү 136
Әхмәтһади Максуди 143

ФӘН

Мәзһәбкә иярү кирәкме? 155
Хәнәфи мәзһәбенең төп китаплары 175
Коръән турында гыйлем 179

ТАРИХ
Пәйгамбәрләр тарихы 184
Алтынчы мөфти – Сафа Баязидов 188
Җиденче мөфти – Галимҗан Баруди 194

КОРБАН
Корбан чалу 204
Корбан чалу турында сораулар. 207

ХАҖ
Хаҗның фарызлары, вәҗибләре һәм сөннәтләре. 211

НӘСЫЙХӘТ
Сәүдә һәм гаделлек. 220
«Мәрхәмәтле булмаганнар мәрхәмәткә ирешә алмас...» 225
Коръән кыйссалары: «Сөеклеләр һәм көнчеләр турында» 227

ӘДӘБИ СӘХИФӘ
Яшел күлмәк 242
Күперләр салучы мөәзин. 244
Карга бәхете. 249
Шигырьләр. 253

«ШУРА» дини альманах, №21

июль – сентябрь 2018
шәүвәл – мөхәррам 1440

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
12+

БАШ РЕДАКТОР:
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 237-94-53 (кабул итү бүлмәсе)

РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП:
Рәмзилә Шафикова
Телефон: +7 (843) 598-09-42

ДИЗАЙНЕРЛАР:
Рөстәм Даутов
Илшат Хәйретдинов

БИТКӘ САЛУЧЫ:
Раушан Сәйфетдияров

ӘДӘБИ РЕДАКТОРЛАР:
Рәмзилә Шафикова
Лилия Хәләфетдинова

РЕДАКЦИЯ

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тыныч лык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нчы йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

Типографиянең адресы:
«Комбинат программных средств» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.
420044, Казан ш., Ямашев проспекты, 36 Б
Тел./факс: +7 (843) 519-91-10
Сайт: http://kpkp.ru/

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 09.07.2018
Чыгу көне: 23.07.2018

Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый

Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела

Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала

«СОВЕТ»

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

Вәгазьләр

13 нче июль вәгазе,

Шәүвәл аеның 29 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел

Дога кабул булу ихтималы зур булган мизгелләр

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) бер хәдисендә: «Дога гыйбадәтнең асылы», – дип әйтә. Без нинди генә гыйбадәтне алсак та, намаз булсынмы ул, уразамы, хаҗмы – аларның һәрберсе дә дога кылу белән бәйләнгән. Без һәрвакыт Аллаһы Тәгаләгә дога кылабыз, шушы дөнья өчен дә, ахирәт өчен дә Аннан сорыйбыз, ялварабыз. Шуңа күрә без догаларның кабул булу ихтималы зур булган вакытлар турында яхшырак белергә тиеш.

Беренчедән, Габдуллаһ бине Габбас (Аллаһ аннан разый булсын) Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) Гали бине Талибка: «Җомгага каршы төндә дога кабул була торган вакыт бар», – дип әйткәнен җиткерә[1].

Әлеге хәдиснең икенче төрлесендә: «Җомга көнне шундый бер вакыт бар, Аллаһы Тәгалә Үзенең колының догасына, әгәр ул хәрам нәрсә сорамаса, һичшиксез җавап бирә», – дип тә өстәлгән[2]. Әлеге хәдисләрдән аңлашылганча, Раббыбыз Аллаһ ошбу вакытны коллары җомга көнне күбрәк дога кылсын өчен яшергән. Шушы һәм башка сәбәпләр аркасында, җомга көне иң бәрәкәтле көннәрдән санала. Бу көнне күп кенә дини йолаларны, никах мәҗлесләрен, төрле ашлар уздырырга тырышабыз, кылган догаларыбыз әлеге мизгелгә туры килсә иде, дип өметләнәбез.

Икенчедән, дога кабул булу ихтималы зур булган тагы бер вакыт – азан белән камәт арасы. Хәдистән билгеле булганча, Аллаһның Илчесе

[1] Имамнар Тирмизи һәм Әл-Хәким хәдис җыентыкларыннан

[2] Имам Әл-Хәким хәдисләр җыентыгыннан

(аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Азан белән камәт арасында кылынган дога кире кагылмый», – дип әйткән. «Безгә бу вакытта нинди дога кылырга?» – дип сәхабәләре сорагач, Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Бу дөнья өчен дә, ахирәт өчен дә сорагыз», – дип җавап кайтара[1]. Хәдистән күренгәнчә, биш вакыт намазга азан әйтелгәннән соң фарыз намазга камәт төшерелгәнче узган вакыт аралыгында дога кылу бик тә саваплы икән. Без азан әйтелгәч тә азан догасы кылырга ашыгабыз. Азан догасы гына түгел, башка догалар укыр өчен дә бу иң кулай вакыт. Бу вакытны әрәм итмичә дога кылып үткәрергә кирәк.

Өченчедән, төнлә белән күпчелек кешеләр йоклаган вакытта һәм һәрбер фарыз намаздан соң дога кылу. Әбү Өмәмә (Аллаһ аннан разый булсын) болай сөйләгән. Бервакыт ул Пәйгамбәребездән: «Әй Аллаһның Илчесе, нинди дога иң кабул булучан?» – дип сораган. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) аңа: «Төн уртасында һәм намаздан соң кылынганы», – дип җавап биргән[2]. Төнлә гыйбадәт кылу зур әһәмияткә ия, чөнки бу вакытта догалар кабул була, гөнаһлар кичерелә, дөнья мәшәкатьләре хакында азрак уйланыла. Шулай ук һәр фарыз намаздан соң кылынган доганың да кабул булуы ихтимал, дидек. Монда инде безнең көн саен биш вакыт намаздан соң кыла торган догаларыбыз керә.

Дүртенчесе – Раббыбызның догаларны кабул итү ихтималы зур булган вакыт булып изге Рамазан ае чоры санала. Бер хәдистә: «Өч кешенең догасы кире кагылмас: Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен ураза тотучының, тәкъва имамның һәм рәнҗетелгән кешенең», – диелә[3]. Рамазан ае калебләрне чистарту ае булып санала, Аллаһы Тәгалә бу айда ураза тотуны барлык сәламәт булган мөселман өчен фарыз кылды. Димәк, бу айда ураза тоткан кешенең кылган догалары кабул булырга бик тә мөмкин. Тагын әле бу айда Кадер кичәсе дигән бөек кичә барлыгын да беләбез. Бу кичә

[1] Имамнар Әбү Давыт һәм Тирмизи хәдис җыентыкларыннан

[2] Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан

[3] Имамнар Әхмәд һәм Тирмизи хәдис җыентыкларыннан

хакында хәдистә: «Кадер кичәсен Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын өмет итеп йокламыйча гыйбадәттә үткәргән кешенең барлык гөнаһлары кичерелер», – диелә[1]. Ә Изге Коръәндә «Кадер» сүрәсенең 3 нче аятендә: «Кадер кичәсе мең кичәдән дә хәерлерәк», – диелә. Бу төндә Аллаһы Тәгалә җир йөзенә бәрәкәтен, рәхмәтен, чиксез күп фәрештәләрен иңдерә. Ул фәрештәләр гыйбадәт кылучылар янында булып, аларның догаларына «әмин» диеп торачаклар, дип хәбәр ителә.

Тагын бер хәдистә догалар кабул булу вакыты таң алдыннан диелә: «Һәр төнне таң алдыннан Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте күкнең түбәнге катына иңәр һәм Ул: «Кем Миңа дога кыла – Мин аның догасына җавап бирәм, кем Миннән сорый – Миң аңа сораганын бирәм, кем кичерү сорый – Мин аны кичерәм», – дияр»[2].

Тагын бер вакыт – гыйбадәт кылучының сәҗдәдә вакыттагы догасы. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Колы Аллаһы Тәгаләгә сәҗдәдә вакытта якын була, шуңа күрә сәҗдәдә вакыттта сорагыз», – дигән[3]. Фарыз һәм сөннәт намаз сәҗдәләрендә фәкать гарәп телендә Коръән һәм сөннәттә килгән догаларны кылырга мөмкин. Ә нәфел намазларда һәм намаздан тыш сәҗдәләрдә доганы үз телебездә кыла алабыз.

Янә бер вакыт – ул яңгыр яуганда. «Ике очракта Аллаһы Тәгалә колларының догасын кабул итә: азан вакытында һәм яңгыр яуганда», – диелә хәдистә[4]. Яңгыр Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте булып санала, яңгыр аркасында игеннәр, үләннәр үсә, алар белән маллар туклана, кешеләр ризыкка ия була. Яңгыр яву динебездә Аллаһы Тәгаләнең бәрәкәте, рәхмәте иңгән вакыт булып санала, шуңа да бу вакытта кылынган догалар кабул булучан.

---

1 Имамнар Бохари һәм Мөслим хәдис җыентыкларыннан

2 Имамнар Бохари һәм Мөслим хәдис җыентыкларыннан

3 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

4 Имам Әл-Хәким хәдисләр җыентыгыннан

Алга таба тагын бер вакыт – Коръән укыганнан соң. Бер хәдистә: «Кем Коръән укый – шул Аллаһы Тәгаләдән сорасын, чынлыкта, шундый вакыт килер – Коръән укучылар кешеләрдән сорарлар», – диелә[1]. Һәм тагын бер хәдистә Коръәнне хәтем кылучының (ягъни аны тулысынча укып чыгучының) догасы кабул булыр, диелә. Чөнки Коръән укыганда кешенең калебе чистара, ихласлыгы арта. Ә дога кабул булуның иң төп шарты – чиста калеб һәм ихласлылык.

Шуңа күрә дә догаларыбызны ихласлык белән, дөнья эшләре хакында уйларыбызны читкә куеп кылсак, алар елның теләсә кайсы вакытында да кабул булыр, ин шә Аллаһ. Һәм ахырдан өстәп үтәсем килә, раҗәб аеның, Рамазан айларының беренче көне, шәгъбан аеның 15 нче көне, Ураза бәйрәме, Корбан бәйрәме һәм Гарәфә көне шулай ук дога кылу өчен иң кулай вакытлар булып санала. Янә шуны онытмагыз: әти-әнисенең балалары өчен кылган догалары, юлчы кешенең, ураза тотучыларның догалары да иң кабул була торган догалардан санала.

Аллаһы Тәгалә ил-көннәребезгә, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә сәламәтлек бирсен, кушканнарын үтәп тыелганнарыннан тыелып, иманлы булып яшәүләребезне, һәм дә ахирәттә Үзенең җәннәтләрендә дә бергә очрашуларыбызны насыйп итсен. Кылган һәм кылыначак догаларыбыз кабуллардан булса иде.

Илнур хәзрәт Каюмов,

Лениногорск районы Урмышлы авылы имам-хатыйбы

---

[1] Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан

20 нче июль вәгазе,

Зөлкагъдә аеның 14 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел

Болгар җирләрен зиярәт итүнең әһәмияте

Һәр елның җәй көннәрендә Болгар җирләрен, олуг бабаларыбызның каберләрен халкыбыз, дин кардәшләребез күпләп зиярәт итә. Бу чараны «Изге Болгар җыены» дип атыйлар. Быел Болгар җыены 21 июль көнне булачак, ин шә Аллаһ.

Әйтергә кирәк, 1989 елда болгар бабаларыбызның рәсми рәвештә ислам динен кабул итүләренә 1100 ел тулуны тантаналы рәвештә билгеләп үткәрделәр. 1989 елдан башлап, Идел буе Болгар дәүләтенең башкаласы булган Болгар шәһәрен торгызу буенча зур эшләр башкарылды. Елдан ел изге, тарихи Болгар җирләренә баручылар саны арта бара.

Мөхтәрәм җәмәгать! Республикабызда хөрмәт күрсәтелергә (кадерләнергә) һәм зиярәт кылынырга лаеклы булган мәртәбәле урыннар (җирләр) бик күп: бездә тәбигыйннәр, тәбиг-тәбигыйннәр, әүлияләр җирләнгән урыннар бар. Белгәнебезчә, тәбигыйннәр – сәхабәләрдән соң килгән, алардан өйрәнгән, аларның эшләрен дәвам иткән буын, ә тәбиг-тәбигыйннәр – тәбигыйннәрдән соң килгән, алардан гыйлем алган һәм тәбигыйннәрнең изге эшләрен дәвам иткән кешеләр. Болгар чорының рухи мәдәнияте һәйкәлләре Биләрдә, Тәтеш районында, Алабугада, Балык бистәсе районында һәм башка урыннарда да сакланып калган. Кызганыч ки, дәһрилекнең каһәрле елларында хакимият зиярәт кылуны тыйды һәм әлеге йоланы үтәгән мөселманнарны эзәрлекләде. Шуңа күрә, безнең бу борынгы йолабыз һәм аны тиешенчә башкару тәртипләре онытыла башлады. Күпләребез зиярәт кылуның әхлакый кагыйдәләре белән таныш

түгел. Кайбер мөселманнарның зиярәт кылу тәртипләре буенча конкрет (анык) сораулары килеп туа. Бүгенге вәгазебездә без зиярәт кылу буенча килеп туган сорауларга җаваплар табарга тырышырбыз.

Татарларның Болгарга зиярәт кылуларын дин күзлегеннән карап китик. Елның билгеле бер көнендә шәһре Болгарны зиярәт итүнең, шәригать күзлегеннән караганда, ныклы нигезе бар, чөнки Бохарида һәм Мөслимдә түбәндәге хәдис китерелә: «Сөекле Пәйгамбәребез галләйһиссәләм Мәдинәгә килгәндә яһүдиләрнең Гашурә көнендә ураза тотканнарын белә. Ул алардан бу көнне ураза тотуларының сәбәбен сорый. Алар: «Бу көнне Аллаh Муса галәйһис-сәләмне коткарып калып, Фиргавенне суда батырып үтергән. Шуңа күрә, без Аллаhы Тәгаләгә рәхмәт йөзеннән бу көнне ураза тотабыз», – дип җавап бирәләр. Моны ишеткәч, Пәйгамбәр галәйһис-сәләм: «Без Мусага сезгә караганда да якынрак», – дип әйтә». Моннан шундый нәтиҗә чыгарырга була: без дә елның билгеле бер көнендә, Аллаhның безгә биргән нигъмәтләре өчен, Аллаhы Раббыбызга рәхмәтебезне белдерергә һәм аны ел саен кабатларга тиеш. Ә Аның безгә биргән нигъмәтләреннән ислам динен кабул итүебездән дә зуррак тагын кайсы нигъмәте бар?! Шул бәхетле көннән башлап, халкыбызның күпме буын вәкиле иманлы булды һәм җәһәннәм утыннан котылуга иреште; ислам динен кабул итү көненнән башлап, без туры юлда.

Шулай итеп, ата-бабаларыбызның ислам динен кабул итүен билгеләп үтү – Пәйгамбәребез галәйһис-сәләмнең күрсәтмәләренә, аның Аллаh нигъмәтләренә карата булган мөнәсәбәтенә тулысы белән туры килә. Болгар шәһәрен халкыбызның зур гыйлемле ата-бабаларыбыз да зиярәт иткән. Мәсәлән, мәшһүр галимебез, тарихчы Шиhабетдин хәзрәт Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтендә Мәрҗани мәчетенең өченче имамы Ибраhим хәзрәт Хуҗаш турында сөйләнгән бүлегендә аның Болгарга зиярәт кылуы турындагы язмаларны китерә: «1235 (1819) елда андагы тәкъваларның каберләрен

зиярәт кылырга мин Болгарга бардым. Аллаһ бу гамәлләремне кабул итсен!» Шул ук китабында Мәрҗани хәзрәтләре үзе турында болай дип яза: «1287 (1870) елда мин үз гаиләм белән Болгарны кабат зиярәт кылдым һәм аның манарасы башына менгәч, миңа шундый уйлар килде: «Бу манарага беркем дә күтәрелмәгән, аннан беркайчан да азан да әйтелмәгән, анда бервакытта тәкбир әйтү дә ишетелмәгән кебек. Болгарда бервакытта да мөселманнар яшәмәгән, алар аның урамнарыннан үтмәгән кебек. Юк, болар барысы да булган, тик вакыт кына элеккегене үз вакыйгалары белән җуеп бетергән. Мосафирларда сагыш хисләре уяткан гүзәл Болгарга Аллаһ тынычлык әйләсен». Шунысын әйтергә кирәк, Шиһабетдин Мәрҗани Болгарны зиярәт кылганда, анда монастырь (чиркәү) эшләп торган! Хәзерге вакытта, биредә ислам мохите тудырылган, шуңа карамастан, кайберәүләр бу изге эшкә аяк чалырга маташа.

Халкыбызның киләчәктә сакланып калуында милли йолаларыбыз һәм истәлекле көннәребез зур роль уйный. Шуңа күрә тарихыбыз, гореф-гадәтләребез белән бәйле булган даталарны, Мәүлидне билгеләп үтү, мөбарәк урыннарны зиярәт кылу бездә киң таралган. Башка халыкларда да кадерле, мөкаддәс урыннар, истәлекле шәһәр-авыллар бар. Мәсәлән, Бәдер һәм Өхед сугышында шәһид киткәннәрнең (дин өчен үтерелгәннәрнең) каберлекләре, Дагъстандагы Дербент шәһәре, андагы сәхабәләр каберлеге һ. б. Бу урыннарны зиярәт кылырга күп кешеләр килә һәм монда бернинди дә ширек кылу юк. Болгарга халык бары тик Аллаһка гыйбадәт кылу өчен генә җыела. Аллаһка ширек кату белән җир шарының теләсә кайсы урынында да шөгыльләнергә була, хәтта Мәккәнең үзендә дә. Нинди дә булса бер урынны зиярәт кылу берничек тә мөшриклек була алмый, алай дип әйтү – наданлык. Әгәр мәчеттә кем дә булса Аллаһның Үзенә түгел, бәлки андагы ярымайга гыйбадәт кылса, бу – ширек кату була. Шул рәвешле, җир шарының теләсә кайсы урынын-

да Аллаһка гыйбадәт кылырга мөмкин, чөнки ул Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән тулысынча мәчет итеп яратылган.

«Зиярәт кылу» сүзенең мәгънәсе: кайда да булса булу, визит.

Зиярәт кылу өч төргә бүленә:

1) исән-сау яки авыру кешеләрне зиярәт итү (хәлен белү);

2) ниндидер бер урынны зиярәт итү;

3) мәрхүмнәр каберен зиярәт итү.

Хәзер шуларга киңрәк тукталып китәрбез.

1. Исән-сау кешеләрне зиярәт итү.

Исән-сау булган туганнарыбызда, якыннарыбызда, дусларыбызда, галимнәрдә, тәкъвалы кешеләрдә булу, аларның хәлләрен белеп тору – җәмгыять алдындагы бурычыбыз, аларга ихтирам күрсәтүебез, аларны сөю хисләребезне белдерүебез.

Сөекле Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм: «Ризыгы киң һәм гомеренең озын булуын теләгән кеше туганнары белән элемтәне өзмәсен», – дип әйткән.

«Әгәр берәү мөселман кардәшен бер кайгысыннан арындырса, Кыямәт көнендә Аллаһ ул бәндәне бер кайгысыннан арындырыр. Әгәр берәү бер фәкыйрьнең хәлен җиңеләйтсә, Аллаһ аның хәлен бу дөньяда һәм ахирәттә дә җиңеләйтер. Берәү үзенең кардәшенә ярдәм иткәндә, Аллаһ аңа Үзенең ярдәмен ирештереп торыр».

«Әгәр мөселман кешесе үзенең икенче бер мөселман кардәше белән кул биреп күрешсә, аларның гөнаһлары агачтан яфрак коелып төшкән кебек коелып төшәр».

2. Нинди дә булса бер урынны зиярәт итү.

Бу – мөкатдәс (изге) һәм мөбарәк урыннарны зиярәт итү. Исламда өч мөбарәк урын бар: Мәккәдәге Хәрам мәчете, Мәдинәдәге Пәйгамбәр галәйһис-сәләм мәчете, Иерусалимдагы Әл-Әкъса мәчете. Ләкин шул өч изге урыннан тыш, мөселманнар өчен ата-бабалары, алар белән булып үткән, тарих белән бәйле вакыйгаларны искә төшерә торган урыннар

мөбарәк (изге) булып санала. Әлбәттә, кемдер: «Өч урыннан тыш, башка изге урын юк», – дип, моңа каршы чыгарга да мөмкин. Ләкин, Коръән буенча, андый урыннар алардан күпкә артыграк.

Мәсәлән, Аллаһы Тәгалә Коръәндә Муса галәйһис-сәләмгә болай ди:

إِنِّي أَنَا رَبُّكَ فَاخْلَعْ نَعْلَيْكَ إِنَّكَ بِالْوَادِ الْمُقَدَّسِ طُوًى

«Хактыр ки, Мин – синең Раббың. Әйдә, башмакларыңны сал. Син мөкатдәс (изге) Тува үзәнендә».

«Та Һа», 20:12

Күргәнебезчә, Аллаһы Тәгалә Муса галәйһис-сәләмнең изге үзәндә, башка сүзләр белән әйткәндә, изге җирдә булуы сәбәпле, аңа башмакларын салырга куша. Бу җирләрнең нәкъ менә изге булуы сәбәпле, Аллаһы Тәгалә аяк киемнәрен салырга боерганы – ап-ачык, тик бу үзән ул өч урын исемлегендә юк, алар белән берничек бәйләнмәгән дә.

Сөекле расүлебез Мөхәммәд галәйһис-сәләмнең Әл-Куба мәчетен һәм Өхед тавын зиярәт итүе – әлеге хәдиснең шул рәвешле аңланышына тагын бер дәлил. Күргәнебезчә, мөбарәк урыннар өчтән күпкә артыграк.

Шулай итеп, изге урыннар турында сүз барганда, өч урын белән генә чикләнергә кирәкми. Һәр халыкның да үзенә аеруча кадерле булган урыннары бар: элегрәк сугыш булган урыннар; истәлекле, данлыклы урыннар; халыкның рухи, мәдәни мирасы белән бәйле урыннар; халыкның ислам дине белән бәйләнешен күрсәткән урыннар. Әйтик, безгә, татарларга, шундый урын итеп заманында олуг шөһрәткә ия булган Болгар шәһәрен күрсәтергә мөмкин. Аңа безнең традицияләребез, гореф-гадәтләребез, тарихыбыз сеңгән. Мисалга хәнәфи мәзһәбенең хокук буенча «Зөбдәтел мәҗәллә» китабыннан бер өзек китерик. Анда: «Шәригать хөкемнәре чыгарылганда җирле мәдәният һәм йолалар игътибарга алынырга тиеш», – дип язылган.

3. Мәрхүмнәрнең каберләрен зиярәт кылу.

Сөекле Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм үзенең мәшһүр хәдисендә: «Мин сезгә каберләрне зиярәт итүне тыйган идем, хәзер исә рөхсәт бирәм, чөнки каберләрне зиярәт итү Кыямәт көнен искә төшерә», – дип әйткән.

Дәреслектә, кешенең ике төп киңәшчесе бар: аларның берсе сөйләүче булса, икенчесе – дәшмәүче. Сөйләп торган киңәшче булып Аллаһның бөек китабы Коръән тора, ә сөйләшмәүчесе – үлем. Кешеләр менә шушы сөйләшми торган киңәшчедән дәрес, гыйбрәт алсын өчен, бабаларыбыз каберлекләрне шәһәрләрнең үзәгендә булдырган.

Мөхтәрәм җәмәгать, шуны онытмасак иде! Аллаһның расүле галәйһис-сәләм: «Кабер – буш дөнья түгел. Иманлы бәндә өчен ул – җәннәт бакчаларыннан бер бакча, имансыз кеше өчен җәһәннәм чокырларыннан бер чокыр булачак», – дигән.

Сөекле Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм үзе еш кына сәхабәләрнең каберлекләрен зиярәт иткән һәм алар өчен мондый дога кылган: «Сезгә иминлек, тынычлык насыйп булсын! Әгәр Аллаһ теләсә, без дә сезгә тиздән кушылачакбыз. Мин үзебез һәм сезнең өчен Аллаһы Тәгаләдән бәхет сорыйм».

Хөрмәтле мөселманнар! Каберләрне зиярәт итү безгә дәрес бирсә, ин шә Аллаһ, мәетләребезгә җиңеллек китерә. Ибне Габбас разыйаллаһу ганһү риваять итә, бервакыт Расүл әкрам галәйһис-сәләм ике кабер арасыннан үткәндә: «Хәзерге вакытта шушы ике кабердә ятучылар зур булмаган гөнаһлары өчен зур җәза ала. Кабердә ятучыларның берсе гайбәт сөйләп йөргән, ә икенчесе – нәҗестән пакьләнмәгән», – дип әйткән. Аннары, Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм пальма ботагын сындырып, аны икегә бүлеп, шул каберләр өстенә кадап куйган һәм: «Бу ботаклар корыганчыга кадәр шушы кешеләрнең кабер газапларын җиңеләйтеп торырлар», – дип әйткән.

Танылган мөфәссир имам Куртуби рахмәтүллаһи галәйһи бу хәдисне болай дип шәрехли: «Бу ботаклар корыганчыга кадәр» дигән сүзләр шуны

аңлата: әгәр кабергә үсемлекләр утыртылса яки Коръән укылса, мәетләр җиңеллек сизә. Әгәр бер үсемлек мәетнең хәлен җиңеләйтсә, Коръән уку аңа тагын да күбрәк җиңеллек бирәчәк».

Хәдис-шәрифтә: «Әгәр берәүгә үлем ирешсә, аны тиз арада күмәргә тырышыгыз. Мәетне күмгәннән соң, аның баш очында «Фәтихә» сүрәсен, ә инде аяк очына басып «Бәкара» сүрәсенең соңгы аятьләрен (Әмәнәрасүл) укыгыз».

Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә Коръәндә мәетләребез өчен дога кылырга өйрәтә:

رَبَّنَا اغْفِرْ لَنَا وَلِإِخْوَانِنَا الَّذِينَ سَبَقُونَا بِالْإِيمَانِ

وَلَا تَجْعَلْ فِي قُلُوبِنَا غِلًّا لِّلَّذِينَ آمَنُوا رَبَّنَا إِنَّكَ رَؤُوفٌ رَّحِيمٌ

«... Раббыбыз, безне һәм бездән элек килеп киткән иманлы кардәшләребезне, зинһар, ярлыка; күңелләребездә иман китергәннәргә каршы һичбер хөсетлек калдырма. Раббыбыз, шик юк ки, Син – чиксез шәфкатьле, чиксез мәрхәмәтле».

«Хәшер / Сөреп Чыгару», 59:19

Ибне Габбас разыйаллаһу ганһү риваять кыла: «Сәгъд бине Гобәдә разыйаллаһу ганһү дигән сәхабәнең әнисе үлгәч, ул Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм янына килеп: «Йә Расүлүллаһ, минем әнием вафат булды. Ул үлгән вакытта аның янында була алмадым. Әгәр әнием өчен үз җиләк-җимеш бакчамны сәдака итеп бирсәм, бу гамәлем аңа файда китерерме икән?» – дип сораган. Аллаһның расүле галәйһис-сәләм: «Әйе», – дигән.

Аллаһ Раббыбыз барчабызга бай тарихыбызны, динебез, милләтебез өчен хезмәт иткән бабаларыбызны истә тотып, аларның изге хезмәтләрен дәвам итергә һәм ике дөнья бәхет-сәгадәтенә ирешергә насыйп итсә иде!

ТҖ МДН Дәгъват бүлеге

27 нче июль вәгазе,

Зөлкагъдә аеның 7 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел

Дөнья – ахирәтнең кыры

Бар галәмнәрне, барча мәхлукатларны бар кылган Аллаһ Сөбхәнә вә Тәгаләгә хәмед-сәнәләребез булса иде. Без Аңа иман китердек вә Аңа өметләнәбез. Бары тик Аллаһы Тәгаләдән ярдәм, мәгъфирәт, һидәяткә һәм туры юлга бастыруны сорыйбыз. Без, гөнаһлы уй-фикерләр, гамәлләрдән ерагаеп, Аңа мөрәҗәгать итәбез.

Дөреслектә, Бер булган Аллаһтан кала бүтән илаһ юк! Бары тик Ул гына бар нәрсәгә дә кодрәтле.

Шулай ук Мөхәммәд Аллаһның илчесе вә Аның колы, дип шәһадәт китерәбез. Йә, Раббым, Мөхәммәдкә Үзеңнең рәхимлелегеңне ирештерсәң иде. Аның туганнарына, сәхабәләренә вә алардан соң килгән мөэминнәргә дә Үзеңнең юмартлылыгыңны күрсәтсәң иде.

Йә, Аллаһ, Үзеңнең чиксез рәхмәтләреңне вә мәрхәмәтлелегеңне безгә дә күрсәтсәң иде. Синең хакыйкый бөеклелегеңне аңлауда көчсез вә Синең хакыйкый кодрәт иясе булуыңны аңлауда артык белемсез булган колларыңа Үзеңнең шәфкатеңне күрсәтсәң иде.

Аллаһы Тәгалә бу дөньяны кешеләрнең күңелләренә шуның кадәр якын кылды ки, бу дөнья безгә туганыбыз кебек күренә башлады. Кайбер кеше өчен ул хәтта балалары кебек якын булды. Андый кешеләр бу дөньяны һәм анда булган әйберләрне: йомшак караватларда озак йокларга; күп һәм тәмле итеп ашарга; вакытны сәгатьләр буе телевизор алларыннан китмичә, төрле спорт уеннарын, концерт, кино карарга яраталар. Ә бит Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) бу дөньяда үзеңне тоту кагыйдәләрен күптән әйтеп калдырды.

Габдуллаһ бине Гомәр (Аллаһ аннан разый булсын) сөйләгән: «Берва-кыт Аллаһның Илчесе мине җилкәмнән тотты да, болай диде: «Бу дөньяда чит җир кешесе яки мосафир кебек бул».

Бу – үз эченә күп файдалы нәрсә, вәгазьләр туплаган бик әһәмиятле хәдис. Ул кешене бу дөньяга зур ниятләр багламаска өйрәтә, чөнки мөэмин аны үзенең даими яшәү урыны итеп карарга, аңа омтылырга тиеш түгел. Ләкин ул сәфәргә бөтен кирәк-яракны әзерләүче мосафир кебек яшәргә, байлык та, балалар да булышмаячак Кыямәт көненә һәрвакытта да әзер булырга тиеш.

Бер төбәккә кунакка килгәч, син өеңдәге кебек телевизор карап утырмаячаксың, киресенчә, тизрәк матур урамнар буенча йөреп кайтыр-га, истәлекле урыннарны, музейларны зиярәт итәргә ашкыначаксың. Ни өчен? Чөнки вакыт тар, вакытны дөрес сарыф итмәсәң, берни дә эшләргә өлгермичә, кире кайтып та китүең бар.

Беркем дә диңгез яр буйларына ял итәргә баргач, кунакханә номе-рында көннәр буе кино карап утырмый, ул тизрәк диңгезгә барачак.

Шулай ук мосафир кеше дә бөтен җиргә тукталмый, ул юлда бул-ган кунакханәләргә ял итәр өчен генә туктый да, ризыкларын барлап, кабат юлга кузгала. Тукталган урыны никадәр генә матур, уңайлы җир булмасын, ул үзенең барасы урынын онытмый, шунда таба барып җитәр өчен көч туплый да, кабат юлга кузгала. Кабаттан Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) хәдисенә әйләнеп кайтыйк. Әлеге хәдистә риваять кылынганча, Пәйгамбәребез Габдуллаһ бине Гомәрне җилкәсеннән тотып, аның игътибарын үзе өйрәтергә теләгән гыйлемгә юнәлдерергә тырышкан. Бу Пәйгамбәребезнең укыту методикаларын да яхшы белгән дигәнне аңлата.

Ән-Нәвәви үзенең хәдисләр җыентыгы китабында болай дип яза: «Ибне Һаҗәр Хәйтами Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) дәрес бирүенә игътибар биргән һәм болай дигән: «Әлеге хәдистә

укытучы яки вәгазьләүченең укыткан вакытта шәкертнең берәр әгъзасына тиеп алуы турында сөйләнелә. Бу турыда Ибне Мәсгүд: «Аллаһның Илчесе миңа тәшәһһүдне (намазның беренче ике рәкәгатеннән соң һәм ахырында әйтелә торган сүзләр) өйрәткәндә мине кулларымнан тотып торды», – дигән. Бу кеше белән якынрак булу, аның игътибарын кайбер нәрсәләргә юнәлдерү өчен эшләнелә, чөнки болай эшләгән кеше, гадәттә, аны онытмый. Моннан тыш, күңел тарткан кешегә карата гына болай эшлиләр. Димәк, Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) Ибне Гомәргә һәм Ибне Мәсгүдкә карата мәхәббәт хис иткән».

Чыннан да, Пәйгамбәребез һәр уңайлы форсатны кулланган, сәхабәләренә мисаллар китергән, аларның таләпләренә һәм акылларына туры килә торган вәгазьләр сөйләгән. Мәсәлән, берәр сәхабә белән ул бер темага сөйләшкәндә, аны югары дәрәҗәдә, бу кеше аңлый алырлык итеп сөйләгән. Гыйлеме ягыннан түбәнрәк кеше аларга килеп кушылса, Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) үзенең сөйләмен шушы кеше аңларлык дәрәҗәгә кадәр төшерә торган булган. Болай эшләп, ул башкаларга яхшы үрнәк күрсәткән, аларга карата сабыр булган, аларны кайгырткан.

Пәйгамбәребезне (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) иң яхшы аңлаучы халык, буын да – аның сәхабәләре. Алар безгә Пәйгамбәребезнең сөннәтен түкми-чәчми җиткерергә тырышканнар, үзләре дә булдыра алганча шул юл белән барганнар. Алардан соң килгән тәбигыйн һәм тәбигыйннәргә иярүчеләр дә шулай яшәгәннәр. Ислам тарихында алар арасыннан бик күп галим исемнәре мәгълүм. Ибне Гомәр (Аллаһ аннан разый булсын) еш кына: «Кичкә кадәр яшәсәң, иртәнгә кадәр яшәвеңне көтмә, иртәнгә кадәр яшәсең, кичкә кадәр яшәвеңне көтмә. Сәламәт булганда авырган вакытта кирәк булачак нәрсәне ал. Яшәвеңнән үлемең өчен кирәкле нәрсәне ал!» – дип әйтә торган булган.

Сәхабәләр, олуг галимнәр бу дөньяның узып китәчәге, ә ахирәтнең мәңгелек икәнен яхшы аңлаганнар һәм шул гыйлемнәренә таянып бу дөньяда гамәл кылганнар.

Дөньяда кеше Аллаһ теләгән кадәр вакыт кына яши ала, шуннан соң барыбер вафат була.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

كُلُّ نَفْسٍ ذَائِقَةُ الْمَوْتِ

«Һәр җан үлемне татыячак...»

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:185

Әмма беркем дә, бер җан иясе дә әҗәле кайчан җитәчәген белми. Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйткән:

وَمَا تَدْرِي نَفْسٌ مَّاذَا تَكْسِبُ غَدًا وَمَا تَدْرِي نَفْسٌ بِأَيِّ أَرْضٍ تَمُوتُ إِنَّ اللَّـهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ

«Кеше үзе белән иртәгә нәрсә буласын белми; кеше кайсы җирдә үләсен дә белми. Дөреслектә Аллаһ һәрнәрсәне белүче вә һәрнәрсәдән хәбәрдар».

«Локман», 31:34

Нәрсә соң ул әҗәл? Ул – кешегә һәм башка мәхлукатларга Аллаһы Тәгалә тарафыннан язылып карар кылынган гомернең бетүе. Һәрбер кешенең гомере Аллаһы Тәгалә тарафыннан билгеләнгән, һәм әгәр аның гомере бетсә, ягъни әҗәле җиткән булса, ул бер секундка иртәрәк тә килмәс һәм кичектерелмәс тә.

Үлемнең җитүе җәйдән соң көз килгән кебек, ул ел саен шулай кабатлана. Әмма бер генә проблема – кеше үлемнән соң ни булачагы турында белми. Көз җиткәч, амбарларда, өй бакчаларында зур хезмәт башлана. Яз-җәй ни башкардың, көз шуның нәтиҗәсен күрсәтәчәк. Әгәр кеше җәй

буе эшләмичә, ял итеп кенә, су сипмичә, чүбен утамыйча, ә колхозлар ашламаларын кертмичә, көннәр-төннәр иген кырларында ятмасалар, көзен җыеп алырлык икмәк булмаячак. Шуның кебек акыллы мөэмин бу дөнья белән сукыраймый, аңа өметләр багламый, уңышны ахирәттә җыю өчен дөньяны иген кыры итеп, бу дөньяда җиң сызганып эш башкара.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

قُل لَّا أَمْلِكُ لِنَفْسِي ضَرًّا وَلَا نَفْعًا إِلَّا مَا شَاءَ اللَّهُ ۗ لِكُلِّ أُمَّةٍ أَجَلٌ ۚ إِذَا جَاءَ أَجَلُهُمْ فَلَا يَسْتَأْخِرُونَ سَاعَةً ۖ وَلَا يَسْتَقْدِمُونَ ﴿٤٩﴾

«Һәрбер халыкның Аллаһ хөкеменә кайту өчен билгеләнгән вакыты бар. Вакытлары җитсә, үлем бер сәгатькә ашыгып иртәрәк килмәс вә бер сәгать соңга калмас».

«Юныс», 10:49

Кеше күпме генә яшәсә дә, бу дөнья беркөнне аның өчен бетәчәк. Бу – без һәр көн, һәр төн күрә торган, һәр сәгать, һәр мизгел сизә торган хакыйкать. Шуннан соң кешене даими, үзгәрешсез, мәңгелек ахирәт көтеп тора. Аллаһы Тәгалә кешеләрне кабердән чыгаргач һәм хисап өчен җыйгач, аларны яки киңлеге күкләр һәм җиргә тигез булган, тәкъвалар өчен әзерләнгән җәннәткә, яки ягулыгы кешеләр һәм ташлар булган, имансыз кешеләр өчен әзерләнгән җәһәннәмгә кертәчәк.

Аллаһның Илчесе (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Минем бу дөньяда ни эшем бар? Бу дөньяда мин көндез ял итү өчен агач күләгәсенә туктап, аннары аны ташлап китүче мосафирга тиң», дип әйткән.

Дөньяда мөэмин чит җир кешесе яки мосафир кебек яши. Ул аңа өметләнми, аның зиннәтләренә кызыкмый, алданмый. Ул үзенә бәйле булуга, аның өчен тырышлыклар куюга лаек түгел, чөнки ул мәңге яшәү

өчен түгел, ә күчеп китәр өчен генә яратылган. Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

وَمَا الْحَيَاةُ الدُّنْيَا إِلَّا مَتَاعُ الْغُرُورِ ﴿١٨٥﴾

«Дөнья тереклеге кешеләрне алдаудан башка нәрсә түгел».

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:185

Җәй айлары нинди генә матур булмасын, алар үтәр, кемдер өчен алтын, кемдер өчен караңгы, яңгырлы көз җитәчәк.

«Башка биш нәрсә белән очрашканчы биш нәрсәне куллан: картлыгың килгәнче – яшлегеңне, авыру килгәнче – сәламәтлегеңне, мохтаҗлык килгәнче – байлыгыңны, мәшгуль булганчы – буш вакытыңны, үлемең килгәнче исән булуыңны куллан», – дип әйткән Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын).

Аллаһы Тәгалә бу дөньяда да бәрәкәт биреп, киләсе тормышта да яхшылыклар бирсен иде. Бу дөньяны уңышлы иген кыры итеп ясап, Кыямәттә мул уңыш җыеп алырга насыйп итсә иде. Әмин.

«Хозур» редакциясе

3 нче август вәгазе,

Зөлкагъдә аеның 21 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел

Аның әхлагы Коръән иде

Барча галәмнәрне юктан бар кылучы, Бөек кодрәт иясе Раббыбыз Аллаһка мактауларыбыз, хәмед-сәнәләребез, Аллаһы Тәгалә биргән чиксез нигъмәтләренә сансыз шөкранәләребез, рәхмәтләребез булса иде. Җомга көннәрен зурлап, Аллаһ Раббыбызның чакыруларын кабул итеп, ерак араларны якын кылып, Аның мөбарәк йортларына җыелышып, Раббыбызның кадерле кунаклары булып утырганда, шушы сәгатьләрдә һәрберебезнең ихлас күңелләребездән чыккан сәламнәребезне, салаватларыбызны бездән кабул итеп, шушы галәмгә рәхмәт итеп җибәрелелгән, барчаларыбызга да күркәм үрнәк күрсәтүче булган, Аллаһ Раббыбызның әмер-таләпләрен безләргә 23 ел буе ирештереп, илчелек, расүллек вазифасын үтәгән расүлебез Мөхәммәд Мостафа хәзрәтләренә, аның әһел бәйтенә, сәхабәләренә, тәбигыйннарга Аллаһ Раббыбыз ирештерсә иде.

Раббыбыз «Нун» сүрәсенең 4 нче аятендә:

وَإِنَّكَ لَعَلَىٰ خُلُقٍ عَظِيمٍ ﴿٤﴾

«Дөреслектә, син (Мөхәммәд) күркәм холыклысың», – дип әйтә.

«Нун», 68:4

Кешенең дәрәҗәсен күтәргән, камиллеккә ирешергә мөмкинлек биргән һәм башка махлуклардан аерып торган нигез булып әхлак тора. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) әхлакны кешенең табигый асылында булырга тиешле сыйфат дип санаган. Бер хәдистә: «Мин әхлакны камилләштерергә җибәрелдем», – диелә.

Ислам дине аеруча зур игътибар иткән нигезләрнең берсе булып әхлак һәм әдәп тора. Моны Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм дә бик еш кабатлый. Мисалга мондый хәдисне китерергә була: «Күркәм әхлаклы мөэминнең иманы камил. Арагыздан иң яхшыгыз – хатынына карата яхшы мөгамәләдә булганыгыз»[1].

Әхлак – кешенең әйләнә-тирәдәгеләр белән мөнәсәбәтләрендә чагыла торган гадәтләре. Гадәтләр уңай һәм начар булырга мөмкин. Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешү өчен начар гадәтләрдән арынырга һәм, изге гамәлләр кылып, әкренләп үзеңне Исламның югары әхлагына якынайтырга кирәк. Ислам максатларының берсе – югары әхлаклы кешеләр тәрбияләү. Сөекле Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Мин сезгә әхлакны камилләштерергә җибәрелдем», – дип әйтә. Янә: «Минем өчен иң сөеклеләрегез һәм Кыямәт көнендә иң якыннарыгыз – күркәм әхлак ияләре»[2].

Мөселманнар Аллаһка аларның бар гамәлләре билгеле булуын, фәрештәләрнең аларны язып баруын беләләр. Шулай ук Кыямәт көнендә изге гамәлләребез өчен саваплар алачагыбыз, һәм Аллаһ ярлыкамаса, начарлары өчен җәза алачагыбыз мәгълүм.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

فَمَن يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ خَيْرًا يَرَهُ ﴿٧﴾ وَمَن يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ شَرًّا يَرَهُ ﴿٨﴾

«Берәү тузан бөртеге хәтле генә яхшылык кылган булса, аның җәзасын күрер. Вә берәү тузан бөртеге хәтле гөнаһ эшләсә, аның җәзасын күрер».

«Зүллзилят / Җир Селкенмәк», 99:7-8

---

1 Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан

2 Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан

Моны белә торып, мөселман гөнаһ кылмаска тырыша һәм игелек кылырга өнди. Ышанмаучы яки иманы зәгыйфь булган кеше Аллаһы Тәгалә каршында җаваплылык тоймый һәм төрле гөнаһлы гамәлләр башкара.

Гыйбадәт ихласлылыкны көчәйтә: биш вакыт намаз безне һәрдаим Галәмнәрне бар кылучы – Аллаһы Тәгаләне искә алырга өйрәтә, ураза күңелләрдә мәрхәмәтлелекне арттыра, кулларны хәрамнан, ә телне ялганнан саклый, зәкәт саранлыктан коткара һәм үзара ярдәмләшү хисен ныгыта. Боларның барысы да җәмгыятькә файда китерә.

Гыйбадәт кылу фарыз булган кебек, әхлак кануннарын саклау да – Аллаһы Тәгаләнең әмерләреннән. Асылда, Ислам диненең максаты булып кешеләрне начар гамәлләрдән ерагайту һәм аларда югары әхлак тәрбияләү тора.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) – Аллаһы Тәгаләнең ихтыяры белән югары дәрәҗәдәге әхлакка һәм күркәм кешелек сыйфатларына ия булган кеше. Бервакыт Гайшәдән (Аллаһ аннан разый булсын) Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) турында сорагач, ул: «Аның әхлагы – Коръән иде», – дип әйтә.[1]

Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) әхлак кануннарына таянып яшәгән һәм үзенең сәхабәләрен дә шуңа өйрәткән. Коръән Кәримдә болай дип әйтелә:

لَّقَدْ كَانَ لَكُمْ فِي رَسُولِ اللَّهِ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ لِّمَن كَانَ يَرْجُو اللَّهَ وَالْيَوْمَ الْآخِرَ وَذَكَرَ اللَّهَ كَثِيرًا ﴿٢١﴾

«Аллаһтан савапны һәм ахирәттә җәннәтне өмет иткән хәлдә Аллаһны күп зекер итүче мөәминнәр өчен, дөреслектә, Аллаһның Расүлендә сез иярергә тиешле булган күркәм холык вә яхшы сыйфатлар бардыр».

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:21

[1] «Шәрхуш-шифа. Галиййуль-Кари», I том, 222 б.

Бу аять белән Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) яшәү рәвеше безнең Ислам канун-нарына нигезләнгән тормышыбызның үрнәге булырга тиешлеген әйтә.

Бу дөньяга бала саф һәм гөнаһсыз хәлдә туа. Әгәр әти-әнисе аңа күркәм тәрбия бирсә, ул югары әхлаклы кеше булып үсәчәк, ә инде мон-дый тәрбия алмаганда, мондый кешедән әхлаклылыкны һәм кешелекле-лекне көтүе авыр.

Авырудан савыгу өчен без тәнебезне төрле дарулар ярдәмендә дәвалыйбыз. Шулай ук без күңелебезне дә начарлыктан чистартып, камилләштерәбез.

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын): «Әхлагыгызны камилләштерегез», – дип әйткән. Аның бу сүзләре кешенең хасиятләре үзгәрә ала дигәнне раслый.

Әхлаксыз кеше белән аралашып, кеше тора-бара аның кимчелекләрен үзенә ала. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) бо-лай дип әйткән: «Гадел һәм гөнаһлы кеше белән булган дуслык мускус сатучы һәм тимерче арасындагы дуслыкка охшаш. Беренчесеннән син йә мускусны сатып ала аласың, йә аның хуш исен тоярсың. Икенчесе янында очкыннар киемеңне яндырып алса, син аның начар исен сизәрсең»[1].

Әхлаклылык намуслы кешеләр белән аралашу юлы белән тәрбияләнә. Халык телендә: «Начар үрнәк йогышлы», – дип юкка гына әйтелмидер. Шуңа да кешенең әхлакка карата карашлары тотрыклы түгел икән, аңа әхлак сыйфатлары булмаган кешеләр белән аралашудан читләшергә кирәк.

Безнең максат – яхшы кешеләр белән дус булып, начар холыклылар-дан читләшү, алар белән якынайсак та, бары тик аңа яхшы якка үзгәрергә ярдәм итү максатыннан гына аралашу.

---

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

Безнең тирә-ягыбыздагы мәгълүмати мәйданда да әхлаклылыкның мөһимлеген күрәбез. Без нинди музыка тыңлыйбыз, нинди фильмнар карыйбыз – болар барысы да мөһим. Киемнәребезнең эстетикасы да мөһим, ул нигезендә әхлак гадәтләре яткан безнең этикабыз белән каршылыкка керергә тиеш түгел.

Янә үзебезгә үрнәк булган шәхесләрнең берсен карап китик. Имам Әбү Хәнифә (аңа Аллаһның рәхмәте булсын) – киңкырлы гыйлем, зирәк акыл һәм югары әхлакка ия булган күренекле ислам галиме. Ул үз үрнәгендә хакыйкатьне эзләүчеләрне дөрес юлга юнәлдерә. Сәүдә эшләре белән шөгыльләнгәндә дә ул әхлакый принципларына каршы бармаган. Үзенә караганда күбрәк башкалар турында уйлаган.

Бервакыт бер хатын аңа ефәк күлмәген сатарга теләгән. Имам аннан иң элек күпме акча алырга теләвен сораган. Хатын: «Йөз дирһәм», – дип әйткән. Әбү Хәнифә каршы килеп: «Бу күлмәк йөз дирһәмнән артыграк тора. Аның бәясен әйтегез», – дигән. Хатын хакын йөз тәңкәгә арттырган. Ләкин Әбү Хәнифә янәдән аның белән килешмәгән. Аның сүзләренә караганда, күлмәк кыйммәтрәк булган.

Шулай итеп күлмәкнең бәясе 400 дирһәмгә кадәр җиткән. Имам барыбер үз сүзен куәтләгән. Хатын аны шаярта дип уйлаган, ләкин имам башка берәүдән күлмәкнең хакын белешергә кушкан. Бу хатын шулай эшләгән һәм күлмәкнең бәясе билгеле булган. Әбү Хәнифә аны 500 дирһәмгә сатып алган.

Бу үрнәге белән Әбү Хәнифә безгә башкаларның мәнфәгатьләрен дә онытмаска кирәклеген күрсәтә.

Мөселманнардагы күркәм әхлак һәм яхшы тәрбия Ислам динен таратуда иң яхшы ысуллардан була. Мисалга, Малайзия, Индонезия, Бруней кебек илләр Ислам динен гарәп диңгезчеләренең һәм сәүдәгәрләренең күркәм әхлакларына, гаделлекләренә карап кабул

иткәннәр. Мөселманнарның әхлагы аерым шәхесләрнең һәм дә тулы бер халыкларның Ислам динен кабул итүләрендә мөһим урынны алып тора.

Аллаһы Тәгалә безнең гөнаһларыбызны гафу итсен, ярлыкасын һәм кешеләрдән иң күркәм булган Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) әхлагына һәм әдәбенә иярергә мөмкинлек бирсә иде. Әмин.

Зәкәрия хәзрәт Тимганов,

Комлы-Кавәл бистәсе мәчетенең имам-хатыйбы

10 нчы август вәгазе,

Зөлкагъдә аеның 28 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел

Зөлхиҗҗә аеның фазыйләтләре

Барча галәмнәрне бар кылып, аларны тәрбия кылып торучы, барлык нигъмәтләр белән безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итеп кылучы Аллаһ Сөбхәнә вә Тәгаләгә хәмед вә сәнәләребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек бирсә иде!

Бүгенге вәгазебез зөлхиҗҗә ае турында булыр. Зөлхиҗҗә аеның атамасы «Хаҗ» сүзеннән алынган. Ул мөселманнар өчен изге, ислам диненең биш баганасының берсе булган Хаҗ сәфәре кылына торган ай булуга ишарә итә. Без, мөселманнар өчен әлеге ай аерым мәгънәгә ия һәм аңа аерым әһәмият тә бирү кирәк, чөнки ул – һиҗри календарьның соңгы ае. Ул – тулы бер елга йомгак ясый, яңа елга кергәндә чистарыну, гөнаһлардан арыну, тәүбә кылу, яңа планнар кору ае. Аллаһы Тәгаләнең безгә – адәм балаларына җибәргән бер рәхмәте-бәрәкәте бу: ел изге Хаҗ кылына, корбан чалына торган зөлхиҗҗә ае белән тәмамлана. Игелек кылыйм дигән кешегә бәрәкәте, әҗер-савабы әйтеп бетергесез күп. Ислам динендә аерым айларның, мисал өчен, раҗәб, мөхәррам, зөлкагъдә айлары, аннан соң килә торган зөлхиҗҗә ае хәрам айлардан санала. Бу айларда билне

кысыбрак буарга, гыйбадәтләребезне арттырырга, саваплы гамәлләрне күбрәк кылырга кирәк. Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ عِدَّةَ الشُّهُورِ عِندَ اللَّهِ اثْنَا عَشَرَ شَهْرًا فِي كِتَابِ اللَّهِ يَوْمَ خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ مِنْهَا أَرْبَعَةٌ حُرُمٌ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ ۚ فَلَا تَظْلِمُوا فِيهِنَّ أَنفُسَكُمْ ۚ وَقَاتِلُوا الْمُشْرِكِينَ كَافَّةً كَمَا يُقَاتِلُونَكُمْ كَافَّةً ۚ وَاعْلَمُوا أَنَّ اللَّهَ مَعَ الْمُتَّقِينَ ﴿٣٦﴾

«Җирне һәм күкләрне яраткан көннән бирле Аллаһ хозурындагы китапта айлар саны унике, ул унике айдан дүртесе хәрам айлар: ягъни раҗәб, зөлкагъдә, зөлхиҗҗә, мөхәррам айлары. Ул дүрт айда үзегезгә золым кылмагыз, бер-берегезгә ярдәмдә булыгыз, ташламагыз! Белегез, Аллаһ тәкъвалылар белән бергә».

«Тәүбә», 9:36

Мөселманнар исә изге айларда, көннәрдә, кичәләрдә күбрәк вакыт намазда булырга, сәдака бирергә, Аллаһны зикер итергә тырышалар. Шул рәвешле җәннәткә якынаялар, шайтаннан ерагаялар. Нәкъ менә шул рәвешле Аллаһка омтылган мөселманнар өчен зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне иң кулай мөмкинлек. Бу турыда Пәйгамбәребез галәйһиссәләм болай дип әйткән: «Аллаһ бу ун көндә кылынган игелекле эшләрне башка көннәрне кылынган игелекле эшләргә караганда ныграк ярата». Әгәр дә сәүдәгәргә: «Менә шундый вакыт җитә: 10 көн эчендә сез 1 еллык ризык, товар җыеп куя аласыз», – дисәләр, ул алдан ук бөтен акчасын әзерләп куячак, билгеләнгән көннәрне, бөтен эшен ташлап, товар җыюга гына багышлаячак. Соңыннан җиңел, рәхәт яшәр өчен шушы 10 көнне кулыннан ычкындырмаячак. Әйдәгез, без дә Аллаһ биргән мөмкинлекне кулдан ычкындырмыйк. Рухи үсеш юлында киләсе 12 айга җитәрлек күләмдә бәрәкәт, савап җыеп калыйк. Ибне Габбас разыйаллаһу ганһү

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләмнең түбәндәге хәдисен китерә: «Расүлүллаһ галәйһис-сәләм зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне хакында: «Изге һәм саваплы гамәлләр Аллаһы Тәгалә тарафыннан аеруча яратып кабул ителгән бу ун көннән дә хәерлерәк башка көннәр юктыр», – дип әйтте». Кешеләр: «Хәтта Аллаһы Тәгалә хакына җиһад итү дәме?» – дип сорадылар. Ул: «Адәм баласы Аллаһы Тәгалә хакына бөтен байлыгын, барлыгын калдырып чыгып китеп, бернәрсәсез кайтып кергән очрактан кала, хәтта җиһадтан да хәерлерәк», – дип әйткән.

Әлеге көннәрнең бөеклеген раслау өчен, Коръәнгә күз салыйк. Изге китапта Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَلَيَالٍ عَشْرٍ ﴿٢﴾

«Ун төн белән ант итәм, ун төннәр зөлхиҗҗә аеның әүвәлге ун төннәредер, яки Рамазан аеның ахыргы ун төннәредер!»

«Фәҗер /Таң», 89:2

Галимнәр әлеге сүрәгә таянып, зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне фазыйләтләрен Рамазан аеның соңгы ун көнлеге белән чагыштыралар. Бу көннәр Аллаһы Тәгаләнең бәрәкәте, рәхмәте белән тулган көннәр.

Үзенең хәдисләренең берсендә Пәйгамбәребез: «Аллаһ юлында тоткан бер көн ураза Аллаһ колының йөзен җәһәннәм утыннан җитмеш еллык ераклыкка читләтер», – дип әйткән. Зөлхиҗҗә ае башлану белән нәфел уразасын тотабыз. Ул 9 көн дәвам итә. 9 нчы көн – Гает алды көне Гарәфә көне дип атала. Ул көн дә мөбарәк көннәрдән санала. Һичьюгы Гарәфә көнендә ураза тоту бик күркәм һәм саваплы булыр. Хаҗ гамәлләре дә шул вакытта үтәлә. Һәр елны дөньяның барлык илләреннән җыелган берничә йөз мең хаҗи Гарәфә көнендә Гарәфәт тавында дога һәм гыйбадәт кыла.

Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм хаҗның кабул булуын Гарәфә көне белән бәйләгән. Хәдисләрдә Гарәфә көне ничек узса, ул көнне кылынган

гыйбадәтләрне Аллаһы Тәгалә ничек кабул итсә, аның хаҗы да шулай кабул булыр, дип килә.

Гарәфә көнендә бирелә торган тагын бер зур бүләк – ураза тоту. Әгәр дә без зөлхиҗҗә аеның беренче көненнән 9 нчы көненә кадәр ураза тота алсак, бу тагы да фазыйләтле. Мөслим җыентыгында китерелгән хәдистән күренгәнчә, Аллаһ илчесе галәйһис-сәләмнән Гарәфә көнендә ураза тоту хакында сораганнар. Ул: «Әлеге көндә ураза тоту үткән елгы һәм киләсе елгы гөнаһларны кичерелүгә сәбәп була», – дип җавап биргән. Димәк, Гарәфә көнендә тотылган бер көн ураза ике еллык гөнаһларны кичерерлек дәрәҗәдә саваплы булып чыга. Әйдәгез, мөселман кардәшләр, әлеге мөмкинлекне кулдан ычкындырмыйк. Бу көнне Аллаһы Тәгаләгә тәкъвалылыкта, гыйбадәтнең ихласлылыгында ярышыйк.

Зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне турында сөйләгәндә тагын бер мәсьәләне читләтеп үтәргә ярамас. Мөселманнар өчен атна саен тырнак кисү һәм чәч-сакал кыскарту сөннәт гамәл санала. Әмма зөлхиҗҗә аеның беренче ункөнлегендә бу гамәлләрне читкә куеп торсак яхшырак булыр. Аллаһы Тәгаләнең сөекле колларының берсе Әбү Хәнифә бу уңайдан болай дигән: «Зөлхиҗҗәнең беренче ун көнендә әлеге сөннәтне калдырып торсагыз хәерлерәк. Пәйгамбәребез галәйһис-сәләмнең: «Корбан чалырга җыенган кеше зөлхиҗҗә ае керүгә тырнагын да, чәчен дә кисмәсен», – дигән хәдисе катгый күрсәтмә түгел. Әмма шулай да әлеге гамәлләрне Корбан чалынганнан соң гына үтәү мөстәхәб саналыр».

Димәк, корбан чалырга ниятләгән кешегә, хаҗиларга охшау йөзеннән, чәч, сакал, мыек кыскартмау, тырнак кисмәү мөстәхәб гамәл саналыр. Әмма бу гамәлне вәҗиб, ягъни мәҗбүри дип санау дөрес түгел. Тырнагын яки чәч-сакалын кискән кеше гөнаһлы булмас, аның Корбан чалуының савабы да кимемәс, ин шә Аллаһ!

Зөлхиҗҗә аеның беренче ун көнендә кылынырга мөмкин булган иң саваплы гамәл – хаҗ сәфәрендә булу. Аллаһы Тәгалә әлеге изге

гамәлне гомердә бер тапкыр булса да кылырга насыйп итсен иде, чөнки хаҗ сәфәренә барган, андагы барлык йолаларны тиешле дәрәҗәдә үтәгән мөселманнарга Аллаһы Тәгалә гаҗәеп дәрәҗәдә әҗер-саваплар әзерли. Пәйгамбәребез галәйһис-сәләмнең бер хәдисендә: «Кабул кылынган хаҗның әҗере җәннәт нигъмәтләренә тиңдер», – дигән.

Аллаһы Тәгалә адәм балаларының изге юлда булуын, аларның саваплы гамәлләр белән яшәвен хуп күрә. Шуңа күрә Аның рәхмәтенә ирешү өчен хаҗга ния итәргә кирәк. Изге сәфәргә барам дип ния иткән мөселманга Аллаһы Тәгалә акчасын да, җаен да, яхшы юлдашын да насыйп итә. «Изге ния – ярты гамәл» дигән мәкальне ишеткәнегез бардыр. Хаҗ кылу мөмкинлеге булмаган очракта да, көннәребезне гамәл-гыйбадәттә үткәрергә тырышсак иде.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ ﴿٢﴾

«Раббың ризалыгы өчен намаз укы һәм ятимнәрне, фәкыйрьләрне ашатыр өчен корбан чал!»

«Кәүсәр» , 108:2

Корбан чалырга теләүчеләр бу изге гамәлне башкарырга алдан ук әзерләнә башлый. Аллаһы Тәгалә мөмкинлеге булган һәр кешегә Корбан чалуны фарыз итә.

Бу уңайдан Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм: «Аллаһы Тәгалә каршында иң бөек көннәр булып Корбан бәйрәме һәм Әл-Карр көннәре тора», – дип әйткән. Әл-Карр көне – зөлхиҗҗә аеның унберенче көне, ул гарәп теленнән сүзен сүзгә тәрҗемә иткән вакытта — «урнашу, булу»ны аңлата, чөнки хаҗ кылучылар бу көнне хаҗ кылуның бар йолаларын да башкарып бетереп (тәваф әл-ифада (Кәгъбә тирәсендә җиде кат әйләнү), корбан чалу), Мина үзәнендә булалар.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләм үзенең кызы Фатыйма разыйаллаһу ганһәгә: «Корбан чалдыр, чөнки корбан канының тамган беренче тамчысы ук гөнаһларның ярлыкануына сәбәп булыр. Кыямәт көнендә исә ул корбан ителгән хайванның мөгезләре, тиресе, әгъзалары, йоны h.б мизанга салынып, барча гөнаһлардан да авыррак булыр. Корбан ителгән хайванның һәрбер бөртек йоны өчен 40 мең әҗер-савап язылыр», – дип әйткән.

Әбү Сәгыйть Әл-Хөдри разыйаллаһу ганһү исемле сәхабә Пәйгамбәребез галәйһис-сәләмнән: «И Аллаһ илчесе! Бу эштән хасил булган әҗер-саваплар синең йорт әһеленә генә хас рәвештә булырмы, әллә барча мөэмин-мөселманнарга да кагылырмы?» – дип сораган. Пәйгамбәребез: «Өммәтемнән һәркем корбан чалса, ул кешегә бу әҗер-саваплар һәммәсе дә бирелер»,–диде. Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә, Корбан гаетендә кылынган гыйбадәтнең әҗер-савабы исә гаять зур булган кебек, гөнаһ өчен дә газап зур булачак. Корбан итенең өчтән бер өлеше туганнарга, күршеләргә өләшенергә тиеш. Өчтән бер өлеше мохтаҗларга, калган өлеше гаилә әһелләренә кала.

Шулай итеп, бер зөлхиҗҗә ае өчен генә дә бик күп гыйбадәтләр җыела. Ул –гает намазы, ураза, хаҗ, Корбан чалу, сәдака бирү һәм башка бик күп төрле гамәлләр. Бу – Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән мөмкинлеге һәм бу форсатны кулдан ычкындырмасак идее! Әмин.

ТҖ МДН Дәгъват бүлеге

17 нче август вәгазе,

Зөлхиҗҗә аеның 6 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел

Корбан чалу Аллаһка якынайта

Корбан бәйрәме (Гыйд әл-әдха) – хаҗ тәмамлануын билгеләгән Ислам бәйрәме. Ул Ураза бәйрәме тәмамлангач 70 көн узуга, зөлхиҗҗә аеның унынчы көнендә билгеләнә, мөселманнарның иң зур бәйрәме булып санала. Аллаһы Тәгалә ике пәйгамбәребезне зур сынау белән сыный. Ибраһим пәйгамбәрдән улы Исмәгыйльне корбан итәргә алып барганда, Аллаһның рәхмәтеннән сөрелгән шайтан аңа килеп вәсвәсә кыла: «Сине әтиең үтерергә алып бара. Кач, тизрәк», – ди. Сөекле әти-әнисенең һәм Раббысының сүзеннән чыгарга ияләшмәгән бала: «Мин Аллаһ әмеренә каршы килмим. Әтием барын да белеп эшли», – дип мәлгунне ташлар атып куып җибәрә.

Колларынының итагатьләренә күрә, Аллаһы Тәгалә Үзенең киң рәхмәте итеп Исмәгыйльне саклап кала. Ата кешенең кулындагы пычагы үтми һәм күктән корбан итәргә дип, Аллаһ тарафыннан бәрән төшерелә.

Шул көннәрдән бирле изге бер йола итеп Корбан гаете билгеләп үтелә. Бу тарихи вакыйга барыбыз өчен дә бик мөһим һәм гыйбрәтле. Шул ук вакытта без бу кыйссадан Аллаһның киң кодрәтен күрәбез.

Безнең буынга әлеге бәйрәм төрле гадәт, әдәби әсәрләр аша килеп җиткән. Гадәттәгечә, ул Мәккәгә хаҗ кылу белән туры килә. Бәйрәм ир кешеләр өчен госел алып, чиста-пакь киемнәрне киеп, мәчеткә гает намазын уку өчен бару белән башлана. Гадәт буенча, мәчеткә барганда тәкбир – «Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, лә иләһә иллә Ллаһү вә-Ллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр вә-ли-Лләһил-хәмд» – сүзләре әйтелә. Гает намазыннан соң корбан чалына. Аннан соң туганнарны, танышларны зиярәт кылу, табыннар әзерләү, бүләкләр тарату кабул ителгән.

Корбан чалу хөкемнәре һәм кешегә бу гамәл мәҗбүри булсын өчен үтәлергә тиешле шартлар бар.

Байлыгы һәм мөмкинчелеге булган һәрбер мөселман кешесе өчен корбан чалу вәҗиб гамәл санала. Быел корбан чалу өчен нисаб күләме 18 мең сум дип билгеләнде. Ягъни, шушы күләмдәге акчасы булган кеше корбан чалырга тиеш.

Шулай ук бу эшкә тотынган кешенең акыллы, балигъ яшендә булуы, сәфәрдә булмавы шарт. Әгәр дә инде кешенең корбан чалырга мөмкинчелеге юк икән, аңа гөнаһы да юк. Шулай да бу изгелекле эшнең әҗере бик бөек икәнлеген онытырга ярамый, чөнки корбан чалганда хайванның беренче тамчы каны җиргә тамганчы ук суючының гөнаһлары кичерелә.

Бу гамәлдә, башкалардагы кебек үк, ният мөһим әһәмияткә ия. Аллаһы Тәгалә «Хаҗ» сүрәсенең 37 нче аятендә әйтеп үтә:

لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَٰكِن يَنَالُهُ التَّقْوَىٰ مِنكُمْ ۚ ... ﴿٣٧﴾

«Сез чалган дөяләрнең итләре вә каннары Аллаһка ирешмәс, мәгәр тәкъвалыгыгыз вә изге гамәлләрегез ирешер».

«Хаҗ», 22:37

Корбан ителәсе хайванның кимчелекләре булырга тиеш түгел. Әмма әгәр дә хайванның кайбер кимчелекләре булса, аны корбан итәргә була әле. Алар түбәндәгеләр:

– хайванның күз күреме начар булу, кылыйлык;

– бер аягы аксау, әгәр бу аксаклык хайванның йөрүенә комачау итмәсә;

– тумыштан мөгезләре яисә мөгезенең бер өлеше булмау;

– колаклары тишелгән булу;

– берничә теше булмау;

– койрыгының яки колагының зур әһәмияткә ия булмаган өлеше булмау.

Ләкин иң яхшысы хайванның бу кимчелекләрдән пакь булуы.

Ә кайбер җитдирәк кимчелекләр аркасында хайваннар корбанга чалынырга лаек түгел. Алар түбәндәгеләр:

– бер күзе яки ике күзе дә дөм сукыр булса;

– аксаклыгы берәр урынга барып җитәр өчен комачау итсә;

– бер яки ике колагы да тулысынча киселгән булса;

– күпчелек тешләре булмаса;

– бер яки ике мөгезе төптән сынган булса;

– койрыкның яртысына яки аннан да күбрәгенә зыян килгән булса;

– имчәкләре булмаса;

– бик талчыккан хәлдә яки хәлсез хайван булса;

– тумыштан колаксыз яки койрыксыз булса;

– көтүдәге калган хайвннарга кушыла алмаслык дәрәҗәдә котырынган булса;

– нәҗес (чиста булмаган ризык) белән тукланса.

Корбанга суелырга лаеклы хайваннар булып сарык, кәҗә, сыер, үгез, буйвол, дөя тора.

Ә калган хайваннарны корбанга тотарга ярамый. Югарыда әйтелгән хайваннар ата җенесеннән дә, ана җенесеннән дә булса ярый. Нигездә сарык яисә кәҗә сую хуплана. Алар бер еллык булырга тиеш. Әгәр дә хайван ярты еллык, әмма көр һәм таза, бер еллык кебек булса, андый да ярый. Ә эре мөгезле хайваннар ике яшьлек, ә дөя биш яшьлек булырга тиеш. Эре мөгезле хайван белән дөя бер кешедән дә, җиде кешедән дә чалына ала. Ләкин бергәләп эре хайванны чалырга теләгән кешеләрнең нияте Аллаһ ризалыгы өчен генә булырга тиеш. Әгәр дә инде араларыннан берсе ит алырга теләгәннән генә чалса, берсенең дә корбаны кабул ителми.

Корбан чалу рәвешен искә төшереп китик. Башта тыныч кына итеп корбанны чалынасы урынга илтеп җиткерергә кирәк. Аннары газап кылмыйча, сул ягына яткырасы һәм башын кыйблага борып куясы. Вак мөгезле хайванның арткы уң аягыннан кала өч аягы да бәйләнә. Суясы кеше ниятен әйтә, янәшәдәгеләр тәкбир әйтә. Шуннан «Әл-Әнгам» сүрәсенең (162-163) аятьләре укыла:

قُلْ إِنَّ صَلَاتِي وَنُسُكِي وَمَحْيَايَ وَمَمَاتِي لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ﴿١٦٢﴾ لَا شَرِيكَ لَهُ ۖ وَبِذَٰلِكَ أُمِرْتُ وَأَنَا أَوَّلُ الْمُسْلِمِينَ ﴿١٦٣﴾

«Әйт: «Дөреслектә, минем намазым, гыйбадәтем Аллаһка, яшәвем дә, үлемем дә Галәмнәрнең Раббысы ихтыярында, Аңа тиңдәшләр юк».

«Әнгам / Терлек», 6:162-163

Моннан соң «бисмилләһ, Әллаһү әкбәр», дип хайван чалына. Һәм дога кылына.

Өстәмә рәвештә ике рәкәгать нәфел намазын укырга була. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Корбан чалган кеше пычагын куйгач та, ике рәкәгать намаз укыса, Аллаһ аңа ни теләсә шуны бирер», – дип әйткән.

Корбан ите ничек итеп таратылырга тиеш соң?

Корбан, нигездә, фәкыйрь, мохтаҗ, мескен, ятим, кимчелекле кешеләргә, тол хатыннарга, сәфәрдә булучыларга өләшенә. Әгәр дә корбан чалган кешенең үз әнисе тол хатын була икән, аңа да бирелергә тиеш. Корбанлык итен ике төрле юл белән корбан әһелләренә ирештерәләр. Берәүләр кисәкләргә бүлеп, итне тарата, икенчеләр, табын ясап, мохтаҗ кешеләрне чакырып, Коръән мәҗлесе үткәрә. Икесе дә күркәм гамәл санала. Һәм ничек эшләсәң дә, дөрес була.

Итне өч өлешкә бүлү яхшы. Бер өлеше күршеләргә һәм туганнарга таратыла, икенчесе ярлыларга һәм мескеннәргә, ә өченче өлеше чалучының гаиләсенә кала.

Корбан чалу, беренчедән, Аллаһка һәм Аның ризалыгына якынайта. Раббыбыз ул корбанга мохтаҗ түгел, тик Ул моның белән безнең Үзенә якынлык дәрәҗәсен тикшерә. Шулай ук корбан Исмәгыйь галәйһис-сәләм кыйссасын искә төшерә, аның коткарылуы хакында фикерләвебезне яңарта. Мөселманнарның корбан чалуы аларның Аллаһ юлында малларын кызганмавын күрсәтә. Бу канун мескеннәрне һәм ятимнәрне шатландыруга китерә.

Ә файдасына килгәндә, кешенең гөнаһлары ярлыкана, ул Аллаһка шөкер итеп, Аның алдында булган бурычын үти, чалынган хайван Кыямәт көнендә чалучыны Сират күпере аша алып чыга һәм аның котылуында сәбәпче була. Мескен, ятимнәрне сөендереп, без аларның канәгатьләнүенә ирешәбез.

Гадәттә, без һәр елны көчебездән килгәнчә, гает бәйрәмен олылап үткәрергә тырышабыз. Күпләребез бу йоланы авылларына якыннары янына кайтып үти, ә менә андый мөмкинчелекләре булмаучылар шәһәребез мәчетләренә мөрәҗәгать итә ала. Быел Корбан гаете 21 август көненә туры килә. Корбанны 21, 22, 23 август көннәрендә чалырга мөмкин. Аллаһы Тәгалә барча гыйбадәтләребезне кабул кылсын!

Тимергали хәзрәт Юлдашев,

Галиев мәчете имам-хатыйбы

Корбан гаете хөтбәләре

خُطْبَةُ عِيدِ الاَضْحَى

الْخُطْبَةُ الْاُولَى

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَقَدَّسَ ذَاتُهُ عَنِ الشِّرْكِ وَالزَّوَالِ وَنَطَقَتِ الْاَدِلَّةُ بِاَوْصَافِهِ الْجَلاَلِ وَالْجَمَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَحَيَّرَ فِي كُنْهِ ذَاتِهِ الْعُقُولُ وَالْاَفْهَامُ وَعَجَزَ عَنْ اِدْرَاكِ صِفَاتِهِ الرَّاسِخُونَ الْاَعْلَامُ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ اَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِالشُّهُورِ وَالْاَيَّامِ فِصَالِ. وَاَوْجَبَ فِي هَذِهِ الْاَيَّامِ عَلَى الْاَغْنِيَآءِ الْحَجَّ وَالطَّوَافَ بِالْبَيْتِ الْمُكَرَّمِ عِنْدَ الْكَبِيرِ الْمُتَعَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. نَحْمَدُ اللَّهَ الَّذِي لَمْ يَتَّخِذْ صَاحِبَةً وَلاَ وَلَدًا وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ شَرِيكٌ فِي الْمُلْكِ وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ وَلِيٌّ مِّنَ الذُّلِّ وَكَبِّرْهُ تَكْبِيرًا وَاَشْهَدُ اَنْ لَّا اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ

وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ شَفِيعُ الْعُصَاةِ فِي يَوْمِ الْجَزَاءِ بِاَمْرِ اللَّـهِ الْكَرِيمِ الْمُتَعَالِ.

صَلَّى اللَّـهُ تَعَالَى وَسَلَّمَ عَلَيْهِ وَعَلَى ءَالِهِ وَاَصْحَابِهِ الْمَوْصُوفِينَ بِاَحْسَنِ الْاَخْلَاقِ وَاَطْيَبِ الْاَحْوَالِ.

يَا اَيُّهَ النَّاسُ. اِعْلَمُوا اَنَّ يَوْمَكُمْ هَذَا يَوْمٌ شَرِيفٌ وَعِيدٌ لَّطِيفٌ لِّلْخَوَاصِّ وَالْعَوَامِّ يَوْمٌ عَظِيمٌ قَدَرُهُ لِلْاَنَامِ، عَظِّمُوا هَذَا الْيَوْمَ بِالْاِنْعَامِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيْصَالِ الْاَرْحَامِ. اِنَّ اللَّـهَ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا النَّحْرَ بِقَوْلِهِ وَانْحَرْ، وَاَمَرَ خَلِيلَهُ بِذَبْحِ وَلَدِهِ الْاَشْهَرِ وَاُفْدِيَ بِكَبَشٍ مِّنَ الْجَنَّةِ بِوَاسِطَةِ الْمَلَكِ الْمُقَرَّبِ وَلاَ يَجِبُ عَلَى الْفَقِيرِ عَلَى الْقَوْلِ الْمُعْتَبَرِ الْبُدْنَةُ عَنْ سَبْعَةٍ وَالضَّأْنُ وَالْمَعْزُ عَنْ وَاحِدٍ مُجْزِأَةٌ وَلاَ يَجُوزُ الْعَجْفَآءُ وَالْعَرْجَآءُ وَمَقْطُوعَةُ الْاُذُنِ وَالْاِلْيَةِ وَالَّذِي لاَ يَمْشِي عَلَى الْمَنْسَكِ عِنْدَ الْمَذْهَبِ الْمُعْتَبَرِ.

ضَحُّوا عَنْ اَطْيَبِ اَمْوَالِكُمْ وَعَظِّمُوهَا امْتِثَالاً لِّاَمْرِ رَسُولِ اللَّـهِ الـمُقَرَّرِ كَمَا قَالَ رَسُولُ اللَّـهِ صَلَّى اللَّـهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: عَظِّمُوا ضَحَايَاكُمْ فَاِنَّهَا عَلَى الصِّرَاطِ مَطَايَاكُمْ. وَاِنَّ اللَّـهَ تَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا تَكْبِيرَ التَّشْرِيقِ عَقِبَ الْفَرْضِ مِنْ فَجْرِ يَوْمِ عَرَفَةَ اِلَى اخِرِ اَيَّامِ التَّشْرِيقِ بِقَوْلِهِ تَعَالَى: وَاذْكُرُوا اللَّـهَ فِي اَيَّامٍ مَّعْدُودَاتٍ. اَعُوذُ بِاللَّـهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللَّـهِ الرَّحْمَنِ

الرَّحِيمِ: يَآ اَيُّهَ الَّذِينَ ءَامَنُوا اتَّقُوا اللَّـهَ وَلْتَنْظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ وَاتَّقُوا اللَّـهَ اِنَّ اللَّـهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ.

بَارَكَ اللَّـهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرْءَانِ الْعَظِيمِ وَنَفَعَنَا وَاِيَّاكُمْ بِالْاَيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ وَاَسْتَغْفِرُ اللَّـهَ الْغَفَّارَ لِي وَلَكُمْ وَلِسَائِرِ جَمَاعَةِ الْمُسْلِمِينَ الْحَاضِرِينَ اَجْمَعِينَ اِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَادُ الْكَرِيمُ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ.

الْخُطْبَةُ الثَّانِيَةُ

اَلْحَمْدُ لِلَّـهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذُ بِاللَّـهِ مِنْ شُرُورِ اَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ اَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللَّـهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ. وَاَشْهَدُ اَنْ لَا اِلَهَ اِلاَّ اللَّـهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ.

اِنَّ اللَّـهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ. يَآ اَيُّهَا الَّذِينَ ءَامَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا.

اَللَّـهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ صَلَّى وَصَامَ.

اَللَّـهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ قَعَدَ وَقَامَ.

صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَيْهِ وَعَلَى جَمِيعِ الْاَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلَائِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى اَهْلِ طَاعَتِكَ اَجْمَعِينَ مِنْ اَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْاَرَضِينَ. وَارْحَمْنَا وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ الْاَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْاَمْوَاتِ اِنَّكَ اَنْتَ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ وَمُنْزِلُ الْبَرَكَاتِ وَرَافِعُ الدَّرَجَاتِ وَقَاضِيُ الْحَاجَاتِ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللَّهُمَّ ارْحَمِ الْخُلَفَاءَ الرَّاشِدِينَ وَالْاُمَرَاءَ الْمَاضِينَ الَّذِينَ قَضَوْا بِالْحَقِّ وَكَانُوا يَعْدِلُونَ.

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ وَاهْدِ مَنْ خَذَلَ الدِّينَ.

عِبَادَ اللَّهِ، اِنَّ اللَّهَ يَاْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ.

اُذْكُرُوا اللَّهُ الْعَلِيَّ الْعَظِيمَ الْحَيَّ الْقَيُّومَ يَذْكُرْكُمْ وَاشْكُرُوهُ يَزِدْكُمْ وَاسْتَغْفِرُوهُ يَغْفِرْ لَكُمْ وَلَذِكْرُ اللَّهِ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَعْلَى وَاَوْلَى وَاَعَزُّ وَاَجَلُّ وَاَعْظَمُ وَاَتَمُّ وَاَكْبَرُ.

Корбан гаете хөтбәсенең кириллицага транскрипциясе

Беренче хөтбә

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллаһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мән тәкаддәсә ҙәәтүһү ганиш-ширки вәззәүәәл. Вә нәтакатил-әдилләтү би әүсаафиһил-җәләәли вәл-җәмәәл.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр, вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мәң тәхәййәра фии күнһи ҙәәтиһил-гукуулү вәл-әфһәәм, вә гаҗәзә ган идрааки сыфәәтиһир-раасихуунәл-әгләәм.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мән әкрамә гыйбәәдәһүл-мүэминиинә бишшүһүүри вәл-әййәәмил-фисааль. Вә әүҗәбә фии һәәҙиһил-әййәәми галәл-әгънийәәил-хәҗҗә вәт-таүәәфә бил-бәйтил-мүкәррами гыйндәл-кәбиирил-мүтәгааль.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Нәхмәдүллааһәл-ләҙии ләм йәттәхыйҙ саахибәтәү-үә ләә вәләдә, вә ләм йәкүнләһү шәриикүң фил-мүлки, вә ләм йәкүнләһү вәлийүн-минәҙ-ҙүлли вә кәббирһү тәкбиираа. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү вәхдәһүү ләә шәриикә ләһ. Вә әшһәдү әннә сәйидәнәә Мүхәммәдән габдүһүү вә расүүлүһү шәфиигуль-гусаати фии йәүмил-җәзәә'и би әмрилләәһил-кәриимил-мүтәгааль. Салләллааһү тәгаалә вә сәлләмә галәйһи вә галәә әәлиһи вә әсхәәбиһил-мәүсууфиинә би әхсәнил-әхләәкый вә әтъйәбил-әхүәәл.

Йә әййүһән-нәәс! Игләмүү әннә йәүмәкүм һәәҙәә йәүмүн шәриифүн вә гыйидүн ләтыйифүн лил-хаүәәссый вәл-гаүәәмм. Йәүмүн гаҙыймүң кадәруһү лил-әнәәм. Гаҙҙыймүү һәәҙәл йәүмә бил-ингаами

вәл-ихсәәни вә иисаалил-әрхәәм. Вә иннәллааһә тәбәәракә вә тәгәәлә әүҗәбә галәйнән-нәхра би каулиһи вәнхәр. Вә әмәра халииләһүү би ҙәбхи вәләдиһил-әшһәри вә үфдийә би кәбәшин минәл җәннәти би вәәситатил-мәләкил-мукарраб, вә лә йәҗибү галәл-фәкыйри галәл-каулил-мүгьтәбәр. Әл-бүднәтү ган сәбгәтин вәд-да'нү вәл-мәгзү гән вәәхидин мүҗзиәтү вә лә йәҗүүзүл-гәҗфәә'ү вәл-гарҗәә'ү вә мәкътуугәтүл-үҙүни вәл-илйьәти вәлләзии лә йәмшии галәл-мәнсәки гиндәл-мәҙһәбил-мүгьтәбәр.

Даххүү ган әтъйәби әмүәәликүн вә гаҙҙыймүүһәәмтиҫәәләән лиәмри расүүлилләәһил-мүкаррар. Кәмәә каалә расүүлүллааһи салләллаһү галәйһи вә сәлләм: «Гәҙҙыймүү дахәәйәәкүм фәиннәһәә гәләс-сыйраати мәтаайәәкүм». Вә иннәллааһә тәгәәләә әүҗәбә галәйнәә тәкбиират-тәшриикый гәкыйбәл-фәръды мин фәҗри йәүми гарафәтә иләә әхыйри әййәәмит-тәшриикый би каулиһи тәгалә: «үәҙкүруллааһә фии әййәәмим-мәгъдүүдәәт». Әгүүҙү билләәһи минә шәйтаанир-раҗиим: Йәә әййүһәлләҙиинә әәмәнүт-тәкуллааһә вәлтәңҙур нәфсүм-мәә каддәмәт лигаад. Вәттакуллааһә иннәллааһә хабиирум бимәә тәгъмәлүн.

Бәракә Ллаһу ләнә вә ләкум фил-Куръәнил-гаҙыйм, вә нәфәганәә вә ийәкүм бил-әәйәәти вәҙ-ҙикрилхәкиими вә әстәгъфируллаһәл-гаффәәра лии вә ләкүм вә лисәә'ири җәмәәгәтил-мүслимиинәл-хәәдыйриинә әҗмәгыйн. Иннәһү һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүс-сәмиигуль-гәлиим.

Икенче хөтбә

Әлхәмдү лилләәһи нәхмәдүһү вә нәстәгинүһү вә нәстәгъфируһү вә нү'минү биһи үә нәтәүәккәлү гәләйһи вә нәгүүҙү билләәһи мин

шүруури әңфүсинәә вә мин сәййиәәти әгмәәлинәә мән-йәһдиһил-Лләәһү фәләә мүдыйллә ләһү вә мән-йүдәлилһү фәләә һәәдийә ләһ. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү вәхдәһү ләә шәриикә ләһү вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән гәбдүһү вә расүүлүһ.

Иннәллаһә вә мәләәикәтәһүү йүсаллүүнә галән-нәбий. Йәә әййүһәлләҗиинә әәмәнү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәдин бигадәди мән салләә вә саам. Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәдин бигадәди мән кагәдә вә каам.

Саллии вә сәллим гәләйһи вә гәләә җәмиигиль-әнбийәә'и вәл-мүрсәлиин. Вә галәә мәләәикәтикәл-мүкаррабиинә вә галәә әһли таагәтикә әҗмәгиин мин әһлис-сәмәәүәәти вәл-әрадиин. Вәрхәмнәә вәхшүрнәә мәгәһүм бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимин.

Аллаһүммә-гъфир лилмү'миниинә вәл-мү'минәәт, вәл-мүслимиинә, вәл-мүслимәәт, әл-әхъйәә'и минһүм вәл-әмьүәәт, иннәкә әнтә мүҗиибүд-дәгәүәәт вә мүнзилүл-бәракәәт, вә раафигуд-дәраҗәәт, вә каадыйүл-хәәҗәәт, бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин.

Аллаһүммәр-хәмил хуләфәә'әр-раашидиинә вәл-үмәрааа'әл-мәдыйнәл-ләҗиинә кадау билхәккы вә кәәнүү йәгъдилүүн. Аллаһүммән-сурмән нәсараддиинә вәһди мән хаҗәләддиин. Гибәәдәллааһ, иннәллааһә йәъ'мүрү бил-гадли вәл-ихсәәни вә ийтәәәи җил-курбәә вә йәнһәә ганил-фәхшәәәи вәл-мүнкәри вәл-бәгъйи йәгыйиҗукум ләгәлләкүм тәҗәккәрүүн. Үҗкүруллааһәл-галиййәл-гаҗыымәл-хәййәл-кайүүм, йәҗкүрүкүм вәшкүрүүһү йәзидкүм, вәстәгъфирууһүү йәгъфир ләкүм вә ләҗикруллааһи тәбәәракә вә тәгәәләә әглә вә әүләә вә әгәззү вә әҗәллү вә әгҗамү вә әтәммү вә әкбәр.

Корбан гаете хөтбәсенең тәрҗемәсе

Беренче хөтбә

Аллаһ бөек! Аллаһ бөек! Аллаһтан башка илаһ юк. Аллаһ бөек! Аллаһ бөек һәм Аллаһка мактаулар булсын!

Ширек һәм юкка чыгу кебек сыйфатлар каршында мөкатдәс булган Аллаһның заты барча кимчелекләрдән пакьтер. Аллаһның матурлыгына һәм олуглыгына барлык мәхлуклар дәлил булып тора.

Аллаһ бөек! Аллаһ бөек! Аллаһтан башка илаһ юк. Аллаһ бөек! Аллаһ бөек һәм Аллаһка мактаулар булсын!

Аллаһның үзенчәлегенә (Аның рәхмәтле зат булганына) акыл ияләре хайран калды.

Аның сыйфатларына төшенүдән тирән белем ияләре гаҗиз калды.

Аллаһ бөек! Аллаһ бөек! Аллаһтан башка илаһ юк. Аллаһ бөек! Аллаһ бөек һәм Аллаһка мактаулар булсын!

Мөэмин колларына карата айлар һәм көннәр аша юмартлык күрсәткән Зат барча кимчелекләрдән пакьтер. Бу көннәрдә байларга хаҗны, Олуг Аллаһ каршында изге йорт булган Кәгъбәтуллаһны тәваф кылырга йөкләгән Зат барча кимчелекләрдән пакьтер.

Аллаһ бөек! Аллаһ бөек! Аллаһтан башка илаһ юк. Аллаһ бөек! Аллаһ бөек һәм Аллаһка мактаулар булсын!

Үзенә тормыш иптәше алмаган, балалар тудырмаган, падишаһлыгында тиңдәше булмаган, кимсетелүдән коткаручы дустына мохтаҗ булмаган Аллаһны мактыйбыз һәм Аңа тәкбир әйтегез. Аллаһтан башка бернинди илаһ булмаганлыгы турында гуаһлык бирәм, Ул — бердәнбер, Аның тиңдәше юк, Пәйгамбәребез Мөхәммәд Аның колы һәм расүледер. Ул (Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм) җәза алу көнендә гөнаһлылар өчен юмарт булучы һәм олуг Аллаһның әмере белән шәфәгать кылучыдыр.

Аллаһы Тәгалә аңа, аның гаиләсенә, иң күркәм әхлак һәм иң яхшы әхвәл белән сыйфатланган сәхабәләренә салават һәм сәлам ирештерсен.

Әй кешеләр! Белегез ки, сезнең бу (бәйрәм) көнегез — хөрмәтле көндер, байлар һәм ярлылар өчен юмартлык бәйрәмедер, бу көннең кадере халыклар өчен бөектер, бу көнне изгелек, ихласлылык, туганлык мөнәсәбәтләрен ныгыту аша бөекләгез. Чынбарлыкта, безгә Аллаһ Тәбәракә вә Тәгалә Корбанны «Корбан чал!» дип йөкләде. Шулай ук Үзенең хәлиленә (Ибраһим галәйһис-сәләмгә) иң танылган баласын корбан итәргә боерган. Якын фәрештә (Җәбраил галәйһис-сәләм) аша җәннәттән куй бирелгән. Иң могтәбәр сүзгә таянсак, фәкыйрь корбан чалырга тиеш түгел. Эре терлек җиде кешедән һәм бәрән вә кәҗә бер кешедән йөкләмәне төшерә. Могтәбәр мәзһәб буенча, сукыр, аксак, колагы киселгән, җенес әгъзасы өзелгән, мөгезе сынган һәм корбан чалу урынына үзе бара алмаслык дәрәҗәдә хәлсез булган терлек корбанга ярамас.

Корбаннарыгызны иң яхшы малларыгыздан чалыгыз, һәм Аллаһ Расүленең әмеренә буйсынып, корбаннарыгызны хөрмәт итегез (чалганда йомшаклык күрсәтегез). Аллаһның Расүле (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) болай дип әйткән: «Корбанлыкларыгызны хөрмәт итегез, ник дисәгез, алар Сират күперендә сезнең утырып чыга торган хайваннарыгыздыр». Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә безгә фарыз намазларыннан соң тәкбир-тәшрикне Гарәфәт көненең иртәнге намазыннан алып, Тәшрик көненең ахырына кадәр Үзе йөкләгән: «Саналган көннәрдә Аллаһны искә алыгыз», – дигән. Таш белән атылган шайтаннан Аллаһка сыгынам. Рәхимле, Шәфкатьле Аллаһ исеме белән.

Аллаһ Коръәндә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَلْتَنظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ ۖ وَاتَّقُوا اللَّهَ ۚ إِنَّ اللَّهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ ﴿١٨﴾

«Әй иман китергән кешеләр! Аллаһтан куркыгыз һәм һәр җан иясе иртәгәсе көн өчен нәрсә әзерләгәнен күрсен. Аллаһтан куркыгыз, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә эшләрегездән хәбәрдар».

«Хәшер / Сөреп Чыгару», 59:18

Аллаһ безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Гөнаһларны гафу итүче Аллаһ каршында үзем һәм сезнең өчен, шулай ук башка мөселман җәмәгатьләренең бөтенесе өчен, Аллаһ каршында истигъфар кылам (ярлыкау сорыйм). Чынбарлыкта Ул (Аллаһ) — Гафу итүче, Рәхимле, Данлы, Юмартлык иясе, Ишетүче һәм Белүче.

Икенче хөтбә

Аллаһка мактау булсын, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, истигъфар кылабыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Нәфесләребезнең начарлыгыннан һәм гамәлләребезнең кабахәтлегеннән Аллаһка сыгынабыз. Кемгә Аллаһ һидәят бирсә —аны адаштыручы булмас, кемне адаштырса — аңа беркем дә һидәят бирә алмас. Аллаһтан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд — Аның колы һәм хак илчесе булуына гуаһлык бирәм.

«Шик юктыр ки, Аллаһ та, фәрештәләр дә Пәйгамбәргә күп салаватлар әйтә. Әй иман китергән адәмнәр, сез дә аңа салават әйтегез һәм сәламнәрегезне күндерегез».

Аллаһым, Мөхәммәдкә һәм Мөхәммәднең гаиләсенә намаз укучыларның һәм ураза тотучыларның саны кадәре салават ирештер.

Аллаһым, Мөхәммәдкә һәм Мөхәммәднең гаиләсенә утырган һәм басып торган кемсәләрнең саны кадәре салават ирештер.

Аңа салават һәм сәлам ирештер, шулай ук бөтен пәйгамбәрләргә һәм илчеләргә (расүлләргә), якын булган фәрештәләреңә, шулай ук күкләрдә

һәм җирләрдә яшәүче Сиңа итагать әһелләренә салават һәм сәлам ирештер. Шулай ук, безгә карата рәхимле бул һәм безне алар белән бергә мәхшәр мәйданында җый. Синең рәхмәтең белән, йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, мәгъфирәтең белән мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, аларның исәннәрен дә, үлгәннәрен дә гафу ит. Чынбарлыкта, Син догаларны кабул итүче, бәрәкәт иңдерүче, дәрәҗәләрне күтәрүче, хаҗәтләребезне үтәүче. Синең рәхмәтең белән, йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, тугры хәлифәләргә һәм хак белән казыйлык иткән вә гаделлек кыла торган булып үткән әмирләргә карата рәхимле бул.

Аллаһым, кем дингә ярдәм итә, шуңа ярдәм ит һәм кем динне кимсетә, шуңа һидәят бир.

Аллаһының коллары! Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә гаделлек, ихсан, якыннар белән йөрешүне әмер итә һәм фәхешлекне, кире кагылган нәрсәләрне, чиктән чыгуны тыя. Аллаһы сезне вәгазьли, шаять, сез искә алырсыз.

Бөек, Олуг, Тере, Уяу булган Аллаһны зикер итегез – Ул сезне зикер итәр, Аңа карата шөкер итегез – Ул арттырыр. Аның каршында тәүбә-истигъфар кылыгыз – Ул мәгъфирәте белән гафу итәр. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләне зикер итү исә – иң бөек, иң гүзәл, иң олуг, иң җәляләтле, иң камил, иң зур гамәл.

21 нче август вәгазе,

Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел

Корбан гаете вәгазе

Әссәләмүгаләйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәракәтүһү!

Һәрбарчаларыбызга да Аллаһның сәламе, рәхмәте вә бәрәкәте булса иде! Мөхтәрәм дин кардәшләребез!

Бүген без сезнең белән зур бәйрәм – Гыйд әл-әдха – Корбан гаетен каршы алабыз. Аллаһы Тәгалә барлык яхшы гамәлләребезне кабул итеп, гыйбадәтләребез өчен савапларын арттырып, ике дөньяда да Үзенең чиксез мәрхәмәтен насыйп итсә иде! Гаетебез мөбарәк булсын, һәр йортка да шатлык, иминлек һәм Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен алып килсен.

Әлеге изге көндә Россиянең уннарча миллион мөселманнары, дини хисләре тулган хәлдә, иртә таңнан мәчеткә Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәттә булу һәм гаиләләребезгә, туганнарыбызга, дусларыбызга, мохтаҗларга дога кылу өчен җыелдылар.

Корбан бәйрәме – җир шарының барлык почмакларында зурлап билгеләп үтелә торган мөселман бәйрәме ул. Корбан – Аллаһы безгә насыйп иткән зур гыйбадәт, Раббыбыз биргән сансыз нигъмәтләр өчен рәхмәтебезне белдереп, буйсынуыбызны күрсәтү. Кәләм шәрифтә:

فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ ﴿٢﴾

«Раббың ризалыгы өчен намаз укы һәм ятимнәрне, фәкыйрьләрне ашатыр өчен корбан чал!» – диелгән.

«Кәүсәр» , 108:2

Корбан чалуның асыл мәгънәсе корбан китерелгән хайванда, аның итендә түгел, ә күндәмлек күрсәтү, тәкъвалык һәм диндарлыкта яшерелгән. Коръәндә:

لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَٰكِن يَنَالُهُ التَّقْوَىٰ مِنكُمْ ۚ كَذَٰلِكَ سَخَّرَهَا لَكُمْ لِتُكَبِّرُوا اللَّهَ عَلَىٰ مَا هَدَاكُمْ ۗ وَبَشِّرِ الْمُحْسِنِينَ ﴿٣٧﴾

«Чалган корбаннарыгызның итләре вә каннары Аллаһка ирешмәс, ләкин сездән Аллаһка тәкъвалык вә изге гамәлләр ирешер», – диелгән.

«Хаҗ», 22:37

Ел да корбан чалу – Аллаһы Тәгалә әмеренә буйсыну һәм гыйбадәт хакына бар милкеңне корбан итәргә әзер булуның, Раббыбызның әмерләренә буйсынуның чагылышы ул.

Корбан чалу бай кешеләргә аларның Аллаһы Тәгалә каршында да, мөселман өммәте каршында да билгеле бер бурычлары барлыгын искә төшереп тора. Кеше ниндидер мөмкинлекләргә ия булса, димәк аларны үз байлыгыңны арттыру өчен генә түгел, ә изге максатларда кулланырга кирәк. Аллаһы Тәгалә бай кешеләргә мохтаҗ һәм фәкыйрьләрне кайгыртырга, бар кешеләр белән яхшы мөнәсәбәттә булырга омтылырга боера.

Кәләм шәрифтә болай дип әйтелә:

وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا ۖ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا وَبِذِي الْقُرْبَىٰ وَالْيَتَامَىٰ وَالْمَسَاكِينِ وَالْجَارِ ذِي الْقُرْبَىٰ وَالْجَارِ الْجُنُبِ وَالصَّاحِبِ بِالْجَنبِ وَابْنِ السَّبِيلِ وَمَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ ۗ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ مَن كَانَ مُخْتَالًا فَخُورًا ﴿٣٦﴾

«Аллаһның Үзенә генә ихлас гыйбадәт кылыгыз, Аңа һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылмагыз, аннары ата-анага изгелек итегез һәм якын кардәшләргә, ятимнәргә, мескеннәргә, кардәш булган күршеләргә һәм кардәш булмаган күршеләргә дә изгелек итегез. Шулай ук сәфәрдә ят юлдашларга, үзегезгә кунак булып килгән юлчыларга һәм хезмәтче колларыгызга изгелек итегез. Тәкәбберләнеп мактанучыны Аллаһ, әлбәттә, сөйми!»

«Нисә / Хатыннар», 4:36

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм юкка гына: «Күршесе ач булганда тук булган (кеше) бездән түгел», – димәгән.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу хәдисеннән, әгәр кемнең дә булса мөмкинлеге бар икән, башкаларга ярдәм күрсәтү җаваплылыгы йөкләнелгәне аңлашыла.

Корбан чалу кешеләр арасындагы аермалыкларны бетерә, аларны берләштерә, кардәшлек-дуслык җепләре ныгуга китерә, чөнки бәйрәм көннәрендә мөселманнар якыннарына гына түгел, ә бар кешегә дә яхшы эшләре вә изге гамәлләре белән ярдәм итәргә омтыла, корбан итләрен тарата. Бу көнне һәр мөселман өендә кунакчыллык, шатлык, юмартлык хөкем сөрә. Табигый ки, мөселман кешесе Рамазан аенда һәм Корбан бәйрәме көннәрендә генә түгел, ә һәрвакытта да кунакчыл һәм юмарт булырга тиеш. Моңа дәлил булып «Юмарт кеше Аллаһка һәм Җәннәткә, адәм балаларына якын һәм Җәһәннәм утыннан ерак» дигән хәдис тора.

Шулай ук балаларыбызда башка көннәр түгел, ә барыннан да бигрәк мөселман гаетләре шатлык, куаныч һәм бәхет хисләре тудырсын өчен, бу көннәрдә аларга бүләкләр бирү, аларны татлы ризыклар белән сыйлау киңәш ителә.

Гает вакытында юмарт һәм тирән акылга ия кеше күпләргә шатлык һәм куаныч китерә ала, ә иң мөһиме – Раббысының рәхмәтенә ирешеп,

кайбер кешеләр гомере дәвамында да тоя алмаган җан тынычлыгына ирешергә мөмкин.

Бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге сүзләре китерелә: «Саран кешеләрдән иң начары – корбан чалуны башкарырга тиеш була торып та, бу эшне башкармаучылар».

Корбан бәйрәмендә Аллаһ Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе ике корбан чала торган булган: берсен – үзе, ә икенчесен бар мөселман өммәте өчен. Шуңа күрә, җитәрлек байлыклары булган мөселманнар тагы да күбрәк савап алырга теләсәләр, шулай ук ике яки аннан күбрәк корбан чала ала.

Шул рәвешле, корбан чалу мөэминнең үзенең рухи чистарынуын гына түгел, ә күпмедер вакытка булса да, мохтаҗларны ризык белән дә тәэмин итә.

Ә хәзер кыскача гына Корбан бәйрәменең барлыкка килү тарихына тукталып китик. Ул бөек пәйгамбәр, Аллаһның дусты Ибраһим галәйһис-сәләм һәм аның улы Исмәгыйль галәйһис-сәләм белән бәйле.

Аллаһы Тәгалә Ибраһим пәйгамбәргә зур сынау әзерли. Аңа үз улын корбан китерергә әмер бирелә. Ибраһим иң кадерле, көтеп алган һәм йөрәгенә якын булган кешесен корбан китерергә кирәклеген аңлый. Беләбез, Аллаһы Тәгалә Ибраһимга улын ул инде бик өлкән яшьтә булганда гына бирә.

Ибраһим галәйһис-сәләм иң хөрмәтле Пәйгамбәрләрнең берсе, аның исеме белән Коръән-Кәримнең ундүртенче сүрәсе аталган, аны шулай ук яһүдиләр һәм нәсаралар да таный. Аллаһ Сөбхәнәһү вә Тәгалә аның югары дәрәҗәгә ия булуын безгә түбәндәге аятьтә белгертә:

وَمَن يَرْغَبُ عَن مِّلَّةِ إِبْرَاهِيمَ إِلَّا مَن سَفِهَ نَفْسَهُ ۚ وَلَقَدِ اصْطَفَيْنَاهُ فِي الدُّنْيَا ۖ وَإِنَّهُ فِي الْآخِرَةِ لَمِنَ الصَّالِحِينَ ﴿١٣٠﴾

«Ибраһим галәйһис-сәләм тоткан ислам диненнән һичкем баш тартмас, мәгәр үз-үзенә ахмаклык кылган җәһил кеше

генә баш тартыр. Шиксез, Ибраһим галәйһис-сәләмне Үзебез дөньяда имамга һәм пәйгамбәрлеккә сайладык, ә ахирәттә ул изгеләр белән җәннәттә булыр».

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:130

Коръән Кәримдә Ибраһим галәйһис-сәләм белән күптөрле хикмәтле тарихлар һәм нәсыйхәтләр китерелә, әмма әлеге вәгазебездә без аларның берничәсенә генә тукталырбыз.

Олы яшькә җитеп тә, Ибраһим галәйһис-сәләмнең балалары булмый. Шул чакта ул Аллаһка дога кыла: **«Ий Раббым, миңа бер изге ир бала бирче, миңа ярдәмче булсын!»** («Саффат», 37:100). Пәйгамбәрнең догасын кабул итеп, Аллаһы Тәгалә аны ул белән бүләкли, аны Исмәгыйль дип атыйлар.

Еллар уза һәм Исмәгыйль үзенең әтисенә терәк һәм таяныч булырлык яшькә җитә. Шул чакта Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһис-сәләмне зур сынауга тарта, аңа үз улын корбан итәргә боера. Бу хакта түбәндәге аятьтә хәбәр ителә:

فَلَمَّا بَلَغَ مَعَهُ السَّعْيَ قَالَ يَا بُنَيَّ إِنِّي أَرَىٰ فِي الْمَنَامِ أَنِّي أَذْبَحُكَ فَانظُرْ مَاذَا تَرَىٰ ۚ قَالَ يَا أَبَتِ افْعَلْ مَا تُؤْمَرُ ۖ سَتَجِدُنِي إِن شَاءَ اللَّهُ مِنَ الصَّابِرِينَ ﴿١٠٢﴾

«Ул бала җиде яшенә җитеп атасы илә йөри башлагач, Ибраһим әйтте: «Ий углым, мин төшемдә Аллаһ тарафыннан сине корбан итеп чалырга боерыламын, уйлап күр, бу эшкә ничек карыйсың? Улы Исмәгыйль: «Ий атам, ни белән боерылган булсаң, шуны эшлә, мин Аллаһ хөкеменә ризамын, бу эштә мине, Аллаһ теләсә, сабыр итүчеләрдән табарсың», – ди».

«Саффат / Сафта Торучылар», 37:102

Шул рәвешле Ибраһим иң кыйммәтле, күптән көтелгән һәм аңа иң якын булган улын корбан итәргә кирәклекне аңлый, чөнки Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһис-сәләмгә улны аның хәләл җефете олы яшьтә булганда бүләк итә. Әмма барлык авырлыкларга да карамыйча, Ибраһим галәйһис-сәләм Аллаһы Тәгаләгә ышанып, аның тәлапләрен үтәде.

Ибраһим галәйһис-сәләм улы белән ерак юлга чыга. Берничә мәртәбә кеше рәвешенә кереп, алар каршысына Иблис очрый. Кешелекнең дошманы аны мөрәҗәгатьне үтәмәскә һәм Корбан китермәскә үгетли. Аллаһның әмереннән баш тарткан шайтанны күргәч, ул аңа ташлар ата. Шул вакыттан башлап, хаҗ кылган вакытта хаҗилар «Җәмарат» җирендә таш ыргыта.

Әмма дөньяларның Раббысы беркемнең дә корбанына мохтаҗ түгел, бигрәк тә кеше корбанына. Аллаһның кушканын үтәгән Ибраһим галәйһис-сәләм, улы Исмәгыйльгә пычак белән кул күтәргәннән соң, мондый өндәмә ишетә:

قَدْ صَدَّقْتَ الرُّؤْيَا ۚ إِنَّا كَذَٰلِكَ نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ ﴿١٠٥﴾

«Төшеңдә күргән Безнең әмерне тәсъдыйк кылдың, үтәгән хөкемендә булдың. Әнә шулай үзебезгә итагать иткән яхшы мөэминнәрне изге җәзалар белән нигъмәтлибез!»

«Саффат / Сафта Торучылар», 37:105

Шулай итеп, улының корбаны хайван белән алышынды. Бу хакта «Саффат» сүрәсенең 107 нче аятендә болай диелә:

وَفَدَيْنَاهُ بِذِبْحٍ عَظِيمٍ ﴿١٠٧﴾

«Без аны (Исмәгыйльне) бөек корбан (бәрән) белән түләп алдык».

Аллаһ бу корбанны бөек дип атый. Моңа берничә сәбәп бар. Беренчедән, Ул бөек пәйгамбәрнең бөек улына йолым иде. Икенчедән,

Корбан чалу буынның бөек йолаларның берсенә әйләнә. Өченчедән, бу йола сакланып калды һәм Кыямәт көненә кадәр дәвам итәчәк.

Бу гамәлләрдән соң, Ибраһим галәйһис-сәләмгә игелекле рәвештә икенче улы – Исхак галәйһис-сәләмгә туарга насыйп булды. Ул да бөек пәйгамбәр була.

Ибраһим галәйһис-сәләм Аллаһы Тәгаләнең ныклыкны һәм тугрылыкны тикшерергә кушкан барлык авыр сынауларны да намус белән башкарып чыкты. Аллаһы Тәгалә алдында бөек юашлык кичереп һәм Аллаһка бөек тугрылык күрсәтеп, ул аның чын дустына әйләнде.

Ибраһим галәйһис-сәләмнең тарихы безгә Аллаһы Тәгаләнең юлында үзебезнең милкебезне, вакытыбызны, көчебезне корбан итәргә өйрәтә. Бу динне ныклап тотучы кешегә зур үрнәк. Мин һәр мөселманга йоклар алдыннан «Мин бүген Аллаһ ризалыгы өчен нәрсә эшләдем?» дигән сорауны бирүен теләр идем.

Мөхтәрәм җәмәгать! Корбан һәм Ураза гаете уңаеннан уздырылган бәйрәм намазларына бик күп дин кардәшләребез килә, гәрчә динебездә аларның хөкеме вәҗиб, ә көндәлек намазларыбызныкы – фарыз дәрәҗәсендә. Әбү Хәнифә хәзрәтләре: «Фарыз белән вәҗиб арасы җир белән күк кебек», – дигән. Башкача әйткәндә, көндәлек биш тапкыр укыла торган фарыз намаз Аллаһы каршында гает намазларыннан күпкә кадерлерәк. Шуңа күрә, җәмәгать, сезне Аллаһ йортына гыйбадәт кылырга һәр намазга чакырам, ә мөмкинлелегез булмаса, җомга көнне бәйрәм намазына килегез! Тормышыбыз кайнап тора, бик күп вакыйгаларның шаһиты булабыз, каядыр ашыгабыз, кабаланабыз. Шушы кыска гына гомер эчендә иң мөһим булган гыйбадәтне – намазны онытмыйк! Ул Кыямәт көнне беренчеләрдән булып бездән соралачак! Хәдисләрнең берсендә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлләмнең сүзләре китерелгән: «Чыннан да, Кыямәт көнендә беренче булып биш вакыт намаз соралачак. Ул тәртиптә булса, башка гамәлләрең дә тәртиптә булачак».

Корбан бәйрәменә кире әйләнеп кайтканда, бу көнне кемгә корбан чалу важиб (тиешле) булуын карап китик.

Корбан чалучы:

1. Мөселман,

2. Үз акылында,

3. Балигълык яшендә,

4. Ирекле булырга тиеш;

5. Сәфәрдә булмавы,

6. Нисаб күләмендә мал-мөлкәте булуы шарт.

Нисабка ел дәвамында ия булмаска да мөмкин.

Ничек һәм кайчан корбан чалырга була?

Корбан фәкать Корбан бәйрәменең әүвәлге өч көнендә генә чалына. Иң яхшысы – беренче көнне. Бәйрәм намазлары үткәреләчәк шәһәрләрдә һәм башка торак пунктларда корбан намаздан соң ук чалына башлый. Ә бәйрәм намазы укылмаган авылларда таң җиткәннән соң чалына башлый. Ышанычлы хәдистә болай дип әйтелә: «Бүген безнең иң беренче эшебез – бәйрәм намазы уку, ә аннары – корбан чалу. Кем шулай эшли, сөннәтебезне үти. Әгәр дә кемдер корбанны намаздан иртәрәк чалса, аның ите гаиләсенә бирелгән гади иттән китәчәк».[1] Корбанны кич һәм төнлә чалу – мәкруһ, чөнки карангы вакытта кеше хата җибәрә ала, әгәр бу җир яхшы яктыртылган булса, мәкруһ саналмый.

Өченче көннең ахшам намазыннан соң Корбан чалу дөрес булмый.

Корбанлык хайванын, газап кылмыйча, сул ягына яткырырга һәм башын кыйблага борып куярга, үткен пычак кулланырга тиешле. Чаласы кеше хайванны: «Бисмилләһ, Аллаһу Әкбәр», – дип чала һәм дога кыла.

Хайванның җаны тәненнән киткәнче, башын аеру һәм тиресен алу дөрес булмас. Чалган вакытта «Бисмилләһ» дип кенә әйтү җитми, «Бисмилләһ, Аллаһу Әкбәр», дип тутырып әйтү тиешле. Әгәр чалучы

[1] Имамнар Бохари, Мөслим хәдис җыентыкларыннан

белә торып шулай әйтмәсә, әлеге ит тыелган булып санала. Әгәр онытып әйтмәгән булса, бу очракта Аллаһ гафу итәр.

Дөрестән дә, хәрам белән хәләл мәсьәләсе Исламның төп аспектлары булып санала һәм аларга бик җитди караш сорала. Коръәндә хәләл ризыкларны гына куллану турында болай әйтелә: **«Ий ышанучылар! Без рөхсәт иткән сыйлардан (хәләл) авыз итегез һәм Аллаһка табынсагыз, Аңа рәхмәтле булыгыз»** («Әл-Бәкара / Сыер», 2:172) яки бүтән аятьтә: **«Хәләл сыйлардан авыз итегез һәм яхшы гамәлләр кылыгыз»** («Әл-Мөэминүн / Мөэминнәр», 23:51).

Аллаһ Илчесе (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) үзенең бер вәгазендә чәчләре тузган, тузан белән капланган, озак вакыт юлда булган һәм кулларын өскә күтәргән кешене искә төшерә. Ул: «Йә Раббым, йә Раббым!» – дигән, әмма аның ризыгы, эчемлеге, өс киеме, куллана торган әйбере дә хәрам булган. Аллаһ Илчесе аңа ничек җавап бирергә була, дигән.

Без, мөселманнар, бары тик хәләл ризык, продукция һәм гамәлләр генә кулланырга тиешбез. Кызганыч, күп мөселманнарда бары тик ризыклар гына хәләл була ала дигән күзаллау туды. Дөреслектә исә «хәләл» термины кеше тормышының барлык сферасына карый, ә ризыкка гына түгел. Бүгенге көндә инде «хәләл туризм», «хәләл маркетинг», «хәләл косметика» һәм хәзер модада булган «хәләл криптовалюта» терминнары популяр.

Рөхсәт ителгән сыйларны ашап, гамәлләрне кылып, без Аллаһның савабын алабыз. Кешелек Аллаһка ышанырга һәм аңа гыйбадәт кылырга яратылган. Бу турыда Коръән аятендә әйтелә:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен яраттым».

«Зарият / Таратучы», 51:56

Икенче сүз белән әйткәндә, хәләл ризык куллану һәм гамәлләр кылу – Аллаһка итагать итүнең бер чарасы, шуңа без хәләл яшәү рәвешен төп девизыбыз итәргә тиешбез.

Аллаһка шөкер, Татарстан Республикасы шул юнәлештә бара. 2017 елның декабрь ахырында, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановка Дубайның Ислам икътисады үсеш үзәгенең җитәкчеләре белән очрашуда Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең «Halal lifestyle» («Хәләл яшәү рәвеше») исемле 2017-2021 елларга юнәлдерелгән яңа икътисади стратегиясе тәкъдим ителде. Әлеге концепциягә барлык икътисади һәм җәмгыяви яшәү рәвешләре керә. Бу «хәләл»нең XXI гасыр илләре һәм халыкларының икътисади локомативына әверелгән, конкурентлыкка сәләтле бренд, перспективалы финанс юнәлеш, модалы дөньякүләм тренд икәнен дәлилли. Бу очрашу нәтиҗәсендә Татарстан Республикасының хәләл яшәү рәвеше планын барлыкка китерү буенча карар кылынды. Шул рәвешле, Татарстан Республикасы мөселманнары дөньякүләм хәләл индустрия алдынгылары белән бер рәткә басарлык. Бу безнең республика кешеләре өчен икътисади файда китерә ала, чөнки продукцияне импорт һәм экспортка чыгаруның яңа мөмкинлекләре барлыкка килә.

Хәзер безнең янәшәдә бәйрәм намазында төрле шәһәр, илләр, хәтта төрле кыйтгалардан килгән мөселманнар катнаша. Тышкы аерымлыкларыбыз, тел, тән төсе төрле булса да, без бер-беребезне ихластан сәламлибез һәм бер Аллаһка итагать итеп гыйбадәт кылабыз. Ислам безнең йөрәкләрне берләштерде һәм барлык мөселманнарны бер-берсенә карата дин кардәш итте.

Аллаһы Тәгалә бу көндә без рухи шатлык һәм аның шәфкатьлелеген күрергә чын күңелдән намаз укырга рөхсәт бирсә иде. Аллаһы Тәгаләдән безнең корбаннарыбызны кабул итүен сорыйм. Аллаһы Тәгаләдән үсеп килүче яшь буын гыйлемле, әхлаклы, намуслы, талантлы, Татарстан Ре-

спубликабыз һәм Россиянең барлык халыкларына файда китерә торган булуын сорыйм. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешүне, бәхет һәм сәламәтлек, ә безнең илебезгә һәм Татарстан Республикасына тынычлык, иминлек һәм чәчәк атуны сорыйм. Бәйрәм белән сезне, мөселман дин кардәшләрем.

Камил хәзрәт Сәмигуллин,

Татарстан Республикасы мөфтие

24 нче август вәгазе,

Зөлхиҗҗә аеның 13 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел

Ир-атның гаиләдәге вазифасы

Барча галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Тәгаләгә хәмед-сәнәләребез булса иде, җир йөзенә рәхмәт өчен җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләмгә йөрәкләребезнең түрләреннән чыккан салават шәрифләребез ирешсә иде.

Кадерле җәмәгать! Минем сезгә бер-ике сорау бирәсем килә: ни өчен бүгенге көндә никахлашучылар белән беррәттән аерылучылар арта? Ник бүгенге көндә хатын-кызлар үзләренең ирләренә зарланып, елап казыйлар янына киләләр?

Безнең өчен иң төп үрнәк Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм, шулай булса да, ник соң без тормышыбызны ниндидер бүтән кешеләрнеке кебек корабыз. Әгәр дә ир-атларыбыз Аллаһы Тәгаләнең һәм Пәйгамбәребез галәйһис-сәләмнең хатын-кызларга карата мөнәсәбәтләрен нинди булуын камил рәвештә белсәләр, шулай ук хатын-кызларыбызда шул чор хатын-кызларына хас сабырлык, ир-атларга карата ихтирам булса, гаиләләр күпкә ныграк, ә гаилә эчендәге мөгамәлә күпкә җылырак булыр иде.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

وَلَهُنَّ مِثْلُ الَّذِي عَلَيْهِنَّ بِالْمَعْرُوفِ

«Хатыннарның ирләре өстендә хаклары бар, ирләрнең дә хатыннары өстендә хаклары бар. Ир һәм хатын бер-берсен хөрмәтләп һәм хакларын ригая кылып, Аллаһ кушканча яшәргә бурычлы».

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:228

Хатын-кызларның да, ир-атларның да үз вазифалары бар. Ир-атныкы күбрәк матди як булса, хатын-кызныкы – булган гаилә учагын сүндермичә саклап тоту. Аллаһы Тәгалә һәрбер кешенең үз ризыгын алдан билгеләгән. Шуңа күрә ризык табу бары тик хәләл юл белән башкарылырга тиеш. Тырышып та, байлык килмәсә, бу гаилә эчендәге низагларга сәбәп булырга тиеш түгел. Мондый очракта хатын кыз бигрәк тә сабыр, хикмәтле булырга тиеш һәм, шулай булганда, гаилә гөнаһлы гамәлләрдән ерак булыр, ин шә Аллаһ.

Мөселман җәмгыятендә ир-атлар гаилә башлыгы, ә хатын-кыз – аның тулы хокуклы тормыш иптәше, көрәштәше. Коръән Кәрим ир-атның башлыгын каимә мәгънәсендә бирә:

لرِّجَالُ قَوَّامُونَ عَلَى النِّسَاءِ

«Ирләр хатыннарга әдәп, тәрбия бирү өчен каимнәрдер».

«Нисә / Хатыннар», 4:34

Кайимә – татар теленә гарәп теленнән алынган сүз, әммә бүгенге көндә аның мәгънәсен белүче кешеләр бик аздыр. Ул икенче төрле «басып тору (кыям)», яки терәк мәгънәсендә кулланылган. Бу очракта кайимә сүзе аятьтә терәк мәгънәсендә килеп, ир-атка кайбер вазифаларны йөкли. Аллаһы Тәгалә бу аятьтә терәк булуның асылын аңлатып, болай дип дәвам итә:

مَا فَضَّلَ اللَّهُ بَعْضَهُمْ عَلَىٰ بَعْضٍ وَبِمَا أَنفَقُوا مِنْ أَمْوَالِهِمْ ۚ

«Аллаһ мәхлукларны кайберләрен кайберләреннән артык кылды, ирләр гакылда, куәттә хатыннардан өстен булды һәм малларын хатыннарга инфак кылу белән дә ирләрнең дәрәҗәсе өстендер».

«Нисә / Хатыннар», 4:34

Инфак сүзе «нәфәка» тамырыннан, бүлеп бирү, өлеш чыгару дип тәрҗемә кылып булыр иде. Ир-атларның өстенлекләре булып нибары аның физик яктан көчлерәк булуы, ментальлек, ягъни тирән фикер йөртә белүе һәм гаиләне тәэмин итәргә тиешле мал тупларга ашкынуы тора. Икенче төрле әйткәндә, ир-ат гаиләнең попечителе, ягъни үз гаиләсен шул җирлектәге гадәтләр буенча һәрьяклап барлык төр кирәк-ярак белән тәэмин итүе, гаиләнең һәрбер әгъзасы турында тирән кайгыртуы була. Монда бернинди дә абсолют хуҗа, ягъни абсолютизм турында, тирания, башбаштаклык турында сүз бармый, бу, киресенчә, ир-атның гаиләгә карата булган җаваплылык хисләрен югары планкага күтәрү булып санала һәм аннан гаиләнең ныклы булуы өчен барлык көчләрен куюын таләп итә.

Хатын-кызны тәэмин итү никахлашканчыга кадәр үк башлана. Бу – мәһер. Мәһер – ислам буенча бирелергә тиешле бүләк, аны кайбер шәрык илләрендә киң таралган калым белән бутарга ярамый. Мәһер – өйләнү уңаеннан ир-атның хатын-кызның хакын кайтару, бүләк ясау. Ул акча, күчемсез милек, бизәнү әйберләре, кием һәм башка төрле әйберләр була ала. Шул ук вакытта, мәһер кияү өчен күтәрә алмаслык дәрәҗәдә кыйммәт булмаска тиеш, чөнки Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм: «Иң яхшы мәһер булып сезнең өчен авырлык китермәгәне санала», – дип әйтә, ягъни материаль яктан күтәрә алырдай булганы. Әмма Ислам динендә бурычка мәһер алу; бурычка кереп, зур туй мәҗлесләре үткәрү; кредитка машина я бүтән нәрсә алу хупланмый.

Никахтан соң гаилә чыгымнары да түбәндәге хәдис кысаларында була: «Бервакыт Пәйгамбәребез янына бер сәхабә килеп: «Йә Пәйгамбәр, безнең хатыннарыбыз каршында булган вазифаларыбыз нидән гыйбарәт?» – дип сорады. Пәйгамбәребез аңа: «Үзең ашаганда аны да ашат, үзеңә кием сатып алсаң, аңа да ал. Аның йөзенә сукма, начар сүзләр

әйтмә һәм талашканнан соң өйдә берүзен генә калдырма», – дип җавап кайтара».

Гаилә башлыгы буларак ир-ат һәрдаим ризык эзләүдә, ягъни үзенең гаиләсен тәэмин итәргә тырышуда булырга тиеш. Пәйгамбәребез: «Үзенең тәрбиясе астында булучыларны кайгыртмаган кешегә шул гөнаһы җитәрлек булыр», – дип әйтә. Ир-ат үз милкен саранланмыйча гаиләсенә, хатынына бирергә тиеш. Әмма бу мәсьәләдә исраф кылу турында да онытырга ярамый. Өй эчендә ул хатынына төрле әйберләр алып бирә ала, әмма урамга чыккач, хатын-кыз бу матурлыкларны яшерә белергә тиеш. Ә инде хатыны, кыз балалары урамга яулыксыз, гаурәтен капламый торган киемдә, кыска итәкләрдә чыксалар, ир-ат та алар алган гөнаһны алачак. Шуңа күрә ир-ат өстенә гаиләнең дини булуы, аларның Аллаһы Тәгалә каршында булган хакларын кайтаруы турында кайгыртырга тиеш.

Ир-ат үзенең хатынын (аның көченнән килгәнче) яшәгән җирлеккә карап, яхшы кием белән тәэмин итәргә тиеш. Өй эчендә ул аңа хатыны нәрсә теләсә, шундый кием алып бирә ала. Әмма урамга чыккач, хатын-кыз бу матурлыкларны яшерә белергә тиеш.

Аллаһы Тәгалә кешене гөнаһ кылучан итеп яратты. Ир-ат гөнаһ кылса, аны башка мөселманнар, үз хәләл җефете төзәтә ала. Әгәр дә тр хатынында берәр шелтәле, гөнаһлы гамәл күрсә, ул аңа йомшаклык белән нәсыйхәт кылырга, бу хатаны шулай ук бергәләп төзәтү өстендә эшләргә тиеш. Әмма хатынына кул күтәрү, аңа сугу кебек әйберләр диндә беркайчан да кабул ителмәде. Киресенчә, Пәйгамбәребез : «Үзләренең хатыннарына сугучы ир-атлар өстеннән мин Кыямәт көнендә шикаять бирәчәкмен», – дип әйткән. Ә тормышта була торган ниндидер кечкенә генә кимчелекләр өчен, хатын-кызга сугу түгел, каты сүз белән дә бәрелергә ярамый. Кызганычка, бүгенге көндә үзләренең хатыннарына кул күтәрүчеләр әле дә бар һәм бу хәлне мөселман гаиләләрендә дә күзәтергә мөмкин. Мөселман кешегә үзенең дин кардәше белән 3 көннән дә артык сөйләшмичә торыр-

га ярамый. Әмма хатыны шәригать кануннарын үтәмәсә, ир-атка хатыны белән сөйләшмәү срогы бер көннән дә артмый. Аллаһы Тәгалә гаиләләргә өлфәт мәхәббәт кенә салса иде. Әмин!

Без үзебез өчен үрнәк итеп Пәйгамбәребез галәйһис-сәләмне сайладык. Бер генә үрнәк китерик: Пәйгамбәребез үзенең хатыны Гайшәнең исемен кыскартып, аны тагын да якын икәнен күрсәткән. Ул аңа назлы итеп: «Йә Гаиш», – дип дәшә торган булган. Кайчакларда ул аңа: «Алсуланган», – дип дәшкән, чөнки Гайшә анабызның бит очлары алсу булган. Әгәр дә Гайшә анабызга берәр нәрсә кирәк булса, берәр нәрсәне тели торган булса, Пәйгамбәребез аны үтәргә тырышкан. Пәйгамбәребез Гайшә анабыз эчкән савыттан, аның иреннәре кагылган җиреннән эчкән. Ул бик еш үзенең башын аның тезләренә куеп ятып, Коръән укыган. Гайшә анабызның берәр гамәлендә шелтәле эш күрсә дә, ул аны шаяртып, уйнап төзәтә торган булган.

Ир-ат үзенең хатынының кәефен һәрвакыт күтәрергә тырышырга, аның белән шаярырга, көлергә тиеш, әмма шул ук вакытта үзенең дәрәҗәсен түбән төшермәү турында да уйланырга кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд: «Ир-ат үзенең хәләл җефетенә карап, хәләл җефете дә аңа ярату белән караса, Аллаһ та аларга рәхимлелек белән карар. Әгәр алар кулга-кул тотышсалар, аларның гөнаһлары бармаклары арасыннан аска коелачак», – дип әйткән. Пәйгамбәребез икенче бер хәдистә болай дип әйткән: «Бозык бер хатын кызның азгынлыгы, мең бозык ир-ат азгынлыгына тиң. Ә бер хатын-кызның диндарлыгы, тәкъвалыгы 70 тәкъва ир-ат дәрәҗәсенә тиң». Бу, әлбәттә, гөнаһтан ерак булып, әдәпле, тәкъва булуга этәрүче бик көчле мотиватор да булып тора.

Җенси мөнәсәбәткә килгәндә, күрем көннәре булганда якынлык кылу тыела. Бу көндә ир-атка хатынын якынлык кылуга мәҗбүр итү – бик зур гөнаһ (бу көннәрдә бергә бер караватта йокларга ярый, әмма кочаклаган очракта да куллар билдән өстә булырга тиеш).

Ир-ат үзенең хәләл җефете белән һәрвакыт киңәшләшеп эшләү яхшы. Хатынның рөхсәтеннән башка ир-ат өстәмә хаҗ кыла, кая да булса сәфәргә чыгу да алмый.

Гүзәл хатын-кызларыбызга багышланган берничә хәдис китерәсем килә:

«Һәр төн саен йөкле хатын-кыз төне буе гыйбадәт кылып чыгучы һәм көне буе ураза тотучы кебек савап ала».

«Бала тудырганы өчен хатын-кыз 70 ел намаз укыган һәм ураза тоткан кебек әҗер-савап ала. Ә тудыргандагы кичергән авырту өчен аңа бер хаҗ дәрәҗәсендәге савап языла».

«Бала имезүче анага балага имезгән 1 тамчы сөт өчен 1 әҗер языла».

«Әгәр берәр ана төн уртасында елаган баласына уфтанмыйча сөт имезергә дип торса, ул 1 ел буе укыган намаз һәм 1 ел буе тоткан ураза савабын алачак».

«Ир-ат өенә кайткач, хатыны аның (тугры һәм чиста күңелле булган халәтендә) ашарына бирсә, ул 12 ел гыйбадәт кылган кебек савап алыр».

Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм: «Бу дөньяда кылган изге гамәлләре өчен җәннәткә кергән хатын кызлар һур кызларына караганда да матуррак булачаклар», – дип әйткән.

Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм: «Ий, хатын-кызлар! Сезнең иң хәерлеләрегез җәннәткә ир-атларыгызга караганда да иртәрәк керәчәксез. Анда кереп, госелләнеп, бизәнгәннән соң, иң яхшы атларга атланып, кыйммәтле әйберләр тагып алар үзләренең ир-атлары янына чыгачаклар. Аларның янәшәсендә ялтырап тора торган энҗегә охшаган хезмәтчеләр дә барырлар».

Әл-Әсвәд разыйаллаһу ганһү болай дип тапшыра: «Мин Гайшә анабыздан: «Пәйгамбәребез өйдә вакытта ни белән шөгыльләнә иде», – дип сорадым. Ул исә: «Ул өй өчен тиешле барлык гамәлләрне кыла иде, ә намаз вакыты җиткәч, тәһарәтләнеп, намазга китә иде», – дип әйтте».

Аллаһы Тәгалә һәрбарчаларыбызга да күркәм гаилә, тугры балалар язсын. Никахлашканнан соң без үзебез өчен генә җаваплы түгел икәнне исебездән чыгармаскак иде. Аллаһы Тәгалә догаларыбызны кабул кылып, өйләнмәгәннәргә күркәм хатыннар, кияүдә булмаган кызларга яхшы ирләр насыйп әйләп, җәннәттә дә бергә яшәүне ирештерсә иде. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

«Хозур» редакциясе

31 нче август вәгазе,

Зөлхиҗҗә аеның 20 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел

Гыйлем алуның фазыйләтләре

Хира тавының мәгарәсендә пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһис-сәләм янына Җәбраил килә һәм аңа Коръәннең беренче аятьләрен индерә. Бу хәл турында Пәйгамбәребез болай сөйли: «Шунда ул мине бик каты кысты, соңыннан җибәрде, аннары: «Укы», – диде. Мин: «Укый белмим», – дидем. Ул мине икенче кабат кысты, аннан җибәрде һәм: «Укы», – диде. Мин янә: «Укый белмим», – дидем. Ул мине өченче мәртәбә кысып янә җибәрде һәм: «Ий, Мөхәммәд, һәрнәрсәне халык кылучы Раббың исеме белән Коръәнне укы. Ул кешене оешкан каннан халык кылды. Укы, синең Раббың – Аллаһ бик хөрмәтле вә юмарттыр. Ул – Аллаһ, каләм белән язуны өйрәтте. Кешегә белмәгән нәрсәләрен өйрәтте», – дип әйтте».

Коръән اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ дигән сүзләр белән, ягъни: «Ий, Мөхәммәд, һәрнәрсәне халык кылучы Раббыңның исеме белән Коръәнне укы», – дигән сүзләр белән башлана. Беренче сүзләр, беренче боеру укырга, ягъни белем алырга боеру була. Кеше Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылу өчен яратыла. Бу хакта Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә кешенең исенә төшерә. Ничек гыйбадәт кылырга, ничек яшәргә тиеш икәнлеген аңлаткан боерулар кешегә яшәү рәвешен билгелиләр һәм бу Ислам дине була. Кеше Ислам диненең хаклыгын белмәве сәбәпле, гыйбадәтен тиешенчә кылмый, яшәү рәвешен тиешенчә алып бармый. Ягъни аның бөтен бәласе – белемгә тиешенчә игътибар бирмәвендә. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

مَا تَعْبُدُونَ مِن دُونِهِ إِلَّا أَسْمَاءً سَمَّيْتُمُوهَا أَنتُمْ وَآبَاؤُكُم مَّا أَنزَلَ اللَّهُ بِهَا مِن سُلْطَانٍ ۚ إِنِ الْحُكْمُ إِلَّا لِلَّهِ ۚ أَمَرَ أَلَّا تَعْبُدُوا إِلَّا إِيَّاهُ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ وَلَٰكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَعْلَمُونَ ﴿٤٠﴾

«Аллаһ Үзеннән башкага гыйбадәт кылмаска әмер кылды, бу Ислам дине – хак дин, ләкин күп кешеләр белмиләр».

«Йосыф», 12:40

Аллаһы Тәгалә бу аяти-кәримәдә адәм баласына Үзеннән башкага гыйбадәт кылмаска боера, Ислам диненең генә хак дин булуын, боерыкларны үтәүнең тиешлеген һәм Ислам диненең хаклыгын күпләрнең белмәгәнлеген исләренә төшерә. Гыйбадәтләрне тиешенчә үтәү һәм Ислам диненең хаклыгын аңлау өчен Аллаһы Тәгаләдән курку тиешенчә булырга тиеш. Ә инде Аллаһтан тиешенчә курку өчен тиешенчә белемгә ия булу кирәк. Аллаһы Тәгалә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ حَقَّ تُقَاتِهِ وَلَا تَمُوتُنَّ إِلَّا وَأَنتُم مُّسْلِمُونَ ﴿١٠٢﴾

«Ий, мөәминнәр, Аллаһтан каты куркыгыз, Аның хөкемнәрен бозудан бик нык сакланыгыз һәм Коръән белән гамәл кылып, чын мөселман булган хәлегездә генә үлегез!» – дип әйтә.

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:102

Һәм «Фатыр» сүрәсенең 28 аятендә Аллаһтан куркучыларны тасвирлап Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَمِنَ النَّاسِ وَالدَّوَابِّ وَالْأَنْعَامِ مُخْتَلِفٌ أَلْوَانُهُ كَذَٰلِكَ ۗ إِنَّمَا يَخْشَى اللَّهَ مِنْ عِبَادِهِ الْعُلَمَاءُ ۗ إِنَّ اللَّهَ عَزِيزٌ غَفُورٌ ﴿٢٨﴾

«Аллаһтан Аның хөкемнәрен белгән галим кешеләр куркырлар».

«Мәләикә / Фәрештәләр», 35:28

Гыйлемгә омтылу гомер-гомергә безнең халыкка хас сыйфат булган. Әмма соңгы вакытта гыйлем алу беләм диплом алуны бутаучылар күбәйде. Нәтиҗәдә дипломлы кешеләр күп, ә белемле кешеләр аз. Һәркем үзенең баласын югары белемле дәрәҗәле дипломга ия булуын тели. Әмма диплом алу гына белемгә ия булу түгел. Шуңа күрә дә илдә ришвәт, коррупция, динсезлек, эшсезлек, җинаятьчелек хөкем сөрә, чөнки кешенең белем белән эш йөртерлек белеме юк. Бу дөньяви белемгә дә, дини белемгә дә кагыла. Кеше үзенең белеме булмаган нәрсәләр турында бәхәс алып бара. Бүген китаплар күп. Мәсәлән, кибеттән күп кенә табиплык турында китаплар алып, шуларны укыган кешенең, медицина институтын тәмамлап кайткан кешене өйрәтүе, яисә мәктәпне көчкә-көчкә тәмамлаган кешенең профессорны өйрәтүе акылга сыймый. Ә инде гарәпчә хәреф тә танымаган кешенең шәригать кануннары турында югары дини белемгә ия булган остазлар белән бәхәс алып баруын ничек аңларга була. Бу бит Ислам дине. Физика, математика, яисә медицина гына түгел.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

قُلْ هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ ﴿٩﴾

«Әйт, белүчеләр белән белмәүчеләр бертигез булырлармы?»

«Зүмәра / Халык Төркеме», 39:9

Аллаһы Тәгалә белүчеләрне югары дәрәҗәләргә күтәрә һәм бу аятьтә дә сүз дипломга ия булучылар турында түгел, бәлки белемгә ия булучылар турында бара. Кеше хәтта дини түгел, бәлки дөньяви белемне генә булса да тиешенчә өйрәнсә, әгәр дә ул сихер гыйлеме кебек тыелган гыйлем булмаса, бу да аны ислам диненә алып килә, чөнки белем кешене фикерләүгә этәрә, ә фикерләгән кеше дөньяга күз сала һәм аның

үзеннән-үзе генә барлыкка килмәгәнлеген күрә. Дөнья үзеннән-үзе генә барлыкка килмәгән икән, димәк аны юктан бар итүче Зат бар һәм Ул Зат анда үзенең кануннарын урнаштырган. Кеше шул кануннарга ышанырга, аларны кабул итәргә һәм тормышын шул кануннарга нигезләнеп алып барырга тиеш.

Кешегә беренче боерылган нәрсә – белем алу. Һәм ул аңа омтылырга тиеш. Без балаларыбызны мәктәпләргә илтәбез. Фәлән кеше оста укыта дип, фәлән кешегә илтмибез бит. Дини белем белән дә шулай ук: кемнәндер билгесез кешедән белем алганчы, мәчет-мәдрәсәләрдә белем алу яхшырактыр. Башлангыч белемне, әлбәттә, бала ата-анадан алырга тиеш. Әгәр дә ата-ананың тиешле белеме булмаса, баланы мәчет-мәдрәсәләргә, яисә ышанычлы кешеләргә илтү яхшырак.

Белем алуда белмәүче кеше үзенең яшенә карамастан белүче кешегә иярергә тиеш, хәтта ул аңардан яшьрәк булса да. Коръәни-Кәримдә Ибраһим галәйһис-сәләм үзенең әтисенә белем өйрәтергә тәкъдим ясый:

يَا أَبَتِ إِنِّي قَدْ جَاءَنِي مِنَ الْعِلْمِ مَا لَمْ يَأْتِكَ فَاتَّبِعْنِي أَهْدِكَ صِرَاطًا سَوِيًّا ﴿٤٣﴾

«Ий, әтием, Аллаһтан миңа гыйлем килде, ул гыйлем синдә юк, миңа ияр, мин сине туры юлга күндеремен».

«Мәрьям», 19:43

Белемне үзеннән түбәнрәк дәрәҗәдә торучыдан да, хәтта кош, хайван кебек башка җан ияләреннән дә алырга мөмкин. Коръәндә Аллаһы Тәгалә бу хакта Сөләйман галәйһис-сәләм белән һуд-һуд кошы арасында барган сөйләшү мисалында күрсәтә. Һуд-һуд кошы югала һәм табылгаеннан соң Сөләйман галәйһис-сәләм аны җәзага тартырга уйлагач, һуд-һуд кошы болай дип әйтә:

فَمَكَثَ غَيْرَ بَعِيدٍ فَقَالَ أَحَطتُ بِمَا لَمْ تُحِطْ بِهِ وَجِئْتُكَ مِن سَبَإٍ بِنَبَإٍ يَقِينٍ ﴿٢٢﴾

«Һәм әйтте: «Ий, патшам, мин ерак җиргә барып син белмәгәнне белдем һәм Сәба шәһәреннән сиңа хак булган яңа хәбәр белән килдем».

«Нәмел / Кырмыска», 27:22

Монда һуд-һуд кошының Сөләйман галәйһис-сәләм белмәгәнне белгәнлеге күрсәтелә. Һәм Адәм галәйһис-сәләмнең уллары Кабил һәм Һабил мисалында карганың кешене өйрәтүен күрсәтә:

فَبَعَثَ اللَّهُ غُرَابًا يَبْحَثُ فِي الْأَرْضِ لِيُرِيَهُ كَيْفَ يُوَارِي سَوْءَةَ أَخِيهِ ۚ قَالَ يَا وَيْلَتَىٰ أَعَجَزْتُ أَنْ أَكُونَ مِثْلَ هَٰذَا الْغُرَابِ فَأُوَارِيَ سَوْءَةَ أَخِي ۖ فَأَصْبَحَ مِنَ النَّادِمِينَ ﴿٣١﴾

«Аллаһ Кабил янына Бер карга җибәрде, ул карга Кабилгә җирне казып күрсәтте, ягъни Һабилнең гәүдәсен күмәргә өйрәтте (чөнки Кабил Һабилне үтергәч, кайда куярга белмичә, берничә көн күтәреп йөрде). Карганы күргәч, Кабил әйтте: «Һай, миңа үкенеч! Каргадан да көчсезрәк идемме әллә? Карга белгәнне белгән булсам, кардәшемнең гәүдәсен ничә көннәр күтәреп йөрмичә, үтерү белән күмгән булыр идем», дип, бу эшеннән үкенүчеләрдән булды»

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:31

Бүген дөньяви белем нык алга китте. Кеше бу белемгә, күпчелек очракта, үзеннән күпкә түбән булган җан ияләрен тикшереп, күзәтеп ирешә. Мәсәлән, кошларның очышына карап очкычлар, ягъни самолетлар уй-

лап табылды. Гади генә бөҗәкләр медицинада зур-зур ачышлар ясалуга сәбәп булды.

Белем алу, белем белән генә гамәл кылу һәр кешенең бурычы. Әмма һәр нәрсәне белеп бетерү мөмкин түгел, шуңа күрә дә Аллаһы Тәгалә белмәгәннәргә белгәннәрдән сорарга куша:

فَاسْأَلُوا أَهْلَ الذِّكْرِ إِن كُنتُمْ لَا تَعْلَمُونَ ﴿٤٣﴾

«Белмәгән һәрнәрсәгезне белгән кешеләрдән сорагыз!»

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:43

Хәреф тә танымаган, хәтта намаз, ураза кебек гыйбадәтләрне дә белмәгән һәм үтәмәгән кешеләрнең белемле дин әһелләреннән сорамыйча үзләреннән дин турында сөйләп йөрүләре дингә файда китерми, киресенчә, дингә зыян гына сала торган гамәл. Кемгә генә булса да диндә белмәгән нәрсәсен сөйләү тыела.

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا أَطِيعُوا اللَّهَ وَأَطِيعُوا الرَّسُولَ وَأُولِي الْأَمْرِ مِنكُمْ ۖ فَإِن تَنَازَعْتُمْ فِي شَيْءٍ فَرُدُّوهُ إِلَى اللَّهِ وَالرَّسُولِ إِن كُنتُمْ تُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ ۚ ذَٰلِكَ خَيْرٌ وَأَحْسَنُ تَأْوِيلًا ﴿٥٩﴾

«Ий, мөэминнәр! Аллаһка итагать итегез, һәм Расүлгә итагать итегез! Шулай ук үзегездә булган Коръән белән гамәл кылып, Коръән дәлилләре белән әмер итүче дин хуҗаларыгызга да итагать итегез!»

«Нисә / Хатыннар», 4:59

Ягъни, бу аятьтән күренгәнчә, диндә ни дә булса үзеңә сөйләп йөрергә түгел, бәлки белгәннәрдән сорап, аларга буйсынырга кирәк. Бу дин тоту принцибы.

وَمَا أُوتِيتُم مِّنَ الْعِلْمِ إِلَّا قَلِيلًا ﴿٨٥﴾

«Ий, кешеләр сезгә белемнән бик аз өлеш бирелде».

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:85

Аллаһы Тәгалә «белемнән бик аз өлеш бирелде» ди һәм бу аз өлеш тә бөтен кешегә дә бирелми. Кемгәдер бирелә, кемгәдер юк. Бирелгәннәр бирелмәгәннәргә үзләренең белемнәрен ирештерергә тиешләр, ягъни гавәм халыкны укытырга, шәригатьне өйрәтергә тиешләр. Белем бирелмәгәннәр дә бирелгәннәрдән үзләренә тиешлесен сорарга тиешләр, ягъни мөмкинлек табып, белем алырга тиешләр. Белем алучылар алган белемнәрен гамәлгә кертергә бурычлы. Белем бирүчеләрнең дә сүзләре гамәлләренә туры килергә тиеш. Аллаһы Тәгалә безгә болай дип әйтә:

أَتَأْمُرُونَ النَّاسَ بِالْبِرِّ وَتَنسَوْنَ أَنفُسَكُمْ وَأَنتُمْ تَتْلُونَ الْكِتَابَ ۚ أَفَلَا تَعْقِلُونَ ﴿٤٤﴾

«Сез кешеләрне яхшылыкка өндисез, ә үзегезне онытасызмы? Сез бит китапны (Коръәнне) укыйсыз».

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:44

Дин гыйлемендә, чын галимнәр дөньяда бик азлар. Бездә ел саен җәй көннәрендә ястү намазы турында, Рамазан ае җәйге чорга керү сәбәпле тәравих намазларын уку, сәхәр ашау турында бәхәсләр куертыла. Яңа һиҗри айның ничек башлануы шәригатьтә билгеле булуга карамастан, ел саен гает көннәре турында бәхәс бара. Бу бәхәс яңа ай туганны күрү сәбәпле түгел, бәлки ай башланырга атна-ун көн кала башлана. Бу бәхәс, күргәнебезчә, чын галимнәр сүзенә дәллилләп түгел, бәлки диндә дәлиле булмаган бәхәс, ягъни шәйтан вәсвәсәсе генә. Фәтвалар бирергә ашыгырга кирәк түгел. Дөрес фәтва бирмичә гөнаһка гына батуың мөмкин. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Кем белеме

булмаган көенчә фәтва бирә, шул сәбәпле кылынган гөнаһ фәтва бирүчегә төшә», – дип әйткән.

Сәхабәләр сорауга җавап бирергә ашыкмаганнар, башка кешедән сорарга куша торган булганнар. Гали (Аллаһ аннан разый булсын): «Мине ике кеше һәлак итә: оятын югалткан галим һәм үзен тулысынча гыйбадәткә багышлаган надан», – дип әйткән.

Белемсез фәтвалар бирелү заманның бозыклыгын, халыклардан белемнең китүен һәм Ахырзаманның якынаюын күрсәтә.

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Чынлыкта, Аллаһ белемне Үзенең колларын белемсез калдыру белән алмый, бәлки ул белем ияләрен алу белән белемне ала. Һәм белемгә ия булучыларның берсе дә калмагач, кешеләр үзләренә җитәкче итеп наданнарны сайлап куячаклар. Ә алар исә бирелгән сорауларга белемсез рәвештә җаваплар бирәчәкләр, нәтиҗәдә үзләре дә туры юлдан тайпылачаклар, башкаларны да туры юлдан яздырачаклар», – ди.

Мөхтәрәм җәмәгать! Менә инде көзләр җитеп, укулар башлана. Күпме ата-ана баласын шатлана-шатлана мәктәпләргә укырга илтәчәк. Шулай ук шатлана-шатлана дин белемен алырга, дип мәчет-мәдрәсәләргә дә илтсәләр, тагын да яхшырак булыр иде. Безне, дин әһелләрен, дөньяви белемгә каршы, дини белем турында гына сөйлисез, дип гаепләргә тырышалар. Кош ике канатлы булган кебек, кеше да ике канатлы булырга тиеш, диләр. Ягъни кеше дөньяви белемне дә, дини белемне дә тигез алырга тиеш. Безнең халык бит дөньяда иң белемле халыклардан булган. Империя кул астында булып та, Коръән Кәримне беренче булып бастыручы безнең татар халкы тора, ә ул вакытлардагы хәлифәлекләр түгел. Бүген дә халкыбыз үзенең ата-бабадан калган диненә тиешенчә игътибар бирмичә нык ялгыша. Шул сәбәпле ул Раббысын һәм үзен ихтирам итми. Үз-үзен ихтирам итмәгән халыкны башкалар да ихтирам итмиләр. Раббысына битараф халыктан Раббысы да битараф.

Милләтебезнең бүгенге көндә иң зур проблемасы – дини белемнең җитәрлек булмавы. Кеше бөтен нәрсәдән дөнья малын өстен куя, шул сәбәпле туганлык җепләре өзелә, гаиләлә таркала, зина, эчкечелек чәчәк ата, милли горурлык юк дәрәҗәсендә, ягъни кеше хайваннан да түбәнрәк булган тормыш алып бара.

Мөгаз бине Җәбал болай дип әйткән: «Белем алыгыз! Чөнки Аллаһ ризалыгын алу өчен белем алу – Аннан куркуның билгесе, белемгә омтылу – гыйбадәт, башкалар белән нәрсә дә булса өйрәнү – тәсбих, белем алу – җиһад, белемсезгә белем өйрәтү – сәдака, аңларлык кешеләргә белем тапшыру – Аллаһка якынаю чарасы. Белем ялгыз вакытта әңгәмәдәш, дус булачак, дингә юлны күрсәтәчәк, авырлыкларга сабыр итәргә өйрәтәчәк. Белемнәре сәбәпле Аллаһ кайбер кешеләрне җитәкче итеп күтәрәчәк, башкалар аларга иярәчәкләр. Белем турында фикерләү – уразага, башкалар белән белем алу – төнге намазга тиң. Ул кешегә Аллаһка итагать итәргә, Аңа гыйбадәт кылырга, туганнар белән элемтәдә торырга, хәрам һәм хәләлне белергә булыша. Белем – идарәче, ә гамәл аңа иярүче. Ул бәхетле кешеләргә бирелә, ә бәхетсез кешеләр аннан мәхрүм кала».

Аллаһы Тәгалә һәммәләребезгә дә иман байлыгы, саулык-сәламәтлек, бәрәкәтле тормыш насыйп итсен, хәерле белем, милләтебезнең туры юлдан баруын һәм дә Аллаһның рәхмәтендә булуын насыйп итсен.

Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев,

Яр Чаллы шәһәренең «Ак мәчет» мәдрәсәсе директоры

7 нче сентябрь вәгазе,

Зөлхиҗҗә аеның 27 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел

Мөхәррам ае һәм Гашурә көне

Мөхәррам аеның 10 нчы көне – «Гашурә» көне. Үз вакытында Гомәр Әл-Хаттаб разыйаллаһу ганһү нәкъ менә мөхәррам аен һиҗри календарьнең беренче ае итеп билгеләде. Мөселманнар яңа елны бәйрәм кебек билгеләп үтмәсәләр дә (Пәйгамбәребез ике бәйрәм – Ураза һәм Корбан гаете белән килде), аны яңа фазага аяк басу кебек кабул итәләр. Яңа елда бер елга үтәләсе яңа планнар корыла, яңа өметләр баглана h. б.

Мөхәррам ае зөлхиҗҗә аеннан соң килгәнгә күрә дә, Гомәр Әл-Хаттаб бу айны беренче ай итеп куйгандыр. Моның да үз сәбәбе бар.

«Кем дә кем начар сүзләр сөйләшмичә, бозыклыклар кылмыйча бу Йортка (Кәгъбәгә) хаҗ кылса, ул өенә анадан туган сабый кебек (пакь, гөнаһларсыз) кайтыр»[1].

Хаҗ кылганнан соң кеше үзенең гөнаһларының авырлыгыннан котылып кайтыр, шуңа күрә аны сабый бала белән чагыштырып булыр иде. Һәм әле генә хаҗ кылып, гөнаһларыннан арынып кайткан кеше, яңа елга чиста килеш аяк баса. Бу халәт кешегә алдагы елга оптимизм һәм уңай караш белән карарга мөмкинлек бирә, шулай ук элеккеге хаталарга һәм гөнаһларга әйләнеп кайтмыйча, елны тулысы белән шушы рухи чисталыкта үткәрергә этәргеч була.

Әмма мөхәррам аеның беренче ай булуы гына аны шундый зур дәрәҗәләргә күтәрми. Беренчедән, бу айда олы кичә – «Гашурә» көне бар, икенчедән, бу ай һәр көнендә ураза тоту бик фазыйләтле булуы белән аерылып тора. Мөхәммәд Мостафа галәйһис-сәләм:

---

[1] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан: 1819

«Рамазан аеннан соң иң фазыйләтле ураза – Аллаһ аенда, мөхәррамда», – дип әйткән[1].

Мөхәррам аеның һәрбер көне фазыйләтле, шуңа күрә мөселман кешегә мөхәррам ае буе, яки калган айларга караганда бу айда күбрәк көннәр ураза тоту рөхсәт ителә. Гашурә көне бу көннәр арасында аерым урынны биләп, Аллаһы Тәгаләдән зур саваплар бирелә торган көн буларак аерылып торса да, ул әле Ислам дөньясындагы кайбер тарихи вакыйгаларга да бәйле.

Мөхәммәд Мостафа галәйһис-сәләмгә пәйгамбәрлек кешеләр мәҗүсилек динендә булганда, потларга табынган вакытта иңә. Әмма пәйгамбәрләр алып килгән барлык кануннар да юкка чыкмаган була: гарәпләр телдән телгә, нәселдән нәселгә Ибраһим, Исмәгыйль галәйһимуссәләм пәйгамбәрләрнең законнарын тапшырган, яһүдиләр һәм насараларда Муса һәм Гайсә галәйһимуссәләм пәйгамбәрләргә иңгән китаплар (үзләре үк тарафыннан үзгәртелгән булса да) бар иде. Кызганычка, ул гореф-гадәтләрдә, ул китапларда һәм законнардагы күп кенә әйберләр үзгәртелгән, зур хаталар ясалган, шуңа күрә кайда шайтан вәсвәсәсе аша бозылган текст, ә кайда Аллаһы Тәгалә әмере икәнлеген әйтү кыен иде.

Мөхәммәд пәйгамбәр исә аларның берсенә дә таянмады, чөнки аңа турыдан-туры Аллаһы Тәгаләдән вәхи иңдерелде. Ул кешеләргә аларның хаталарын һәм алдашуларын күрсәтте, шулай ук яхшылыкка һәм файдалы гамәлләргә өйрәтте.

Мөшрикләрнең Аллаһы Тәгалә шәригатенә туры килмәгән күп кенә гамәлләре кире кагылды, ә берәр пәйгамбәрдән үзгәрешсез килгән гамәлләр шул килеш калдырылды. Әгәр дә берәр гамәл үзгәреш кичергән булса, ул беренчел халәтенә китерелде. Исламда калдырылган гамәлләргә хаҗ, гомрә (ел әйләнәсендәге кече хаҗ), хаҗ вакытындагы тәлбия

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан: 1163

(мөшрикләр аны үзгәрткән булалар, әмма Пәйгамбәребез аны шәригатькә муафыйк итеп үзгәртте), Гашурә көнне ураза тоту h. б. керә.

Гашурә уразасы турында Гарәбстанда яшәүчеләргә бик күптәннән билгеле була. Гарәпләр ул көнне ураза тотканнар һәм Кәгъбәтуллаһның тукымасын алыштырганнар. Гайшә разыйаллаһу ганһә: «Рамазан (аенда ураза тоту) мәҗбүри булганчы, алар Гашурә көнендә ураза тоттылар һәм бу көн Кәгъбәне каплый торган көн иде», – дип әйткән[1].

Гайшә разыйаллаһу ганһәдән шулай ук: «Җаһилият чорында корәешләләр Гашурә көнендә ураза тоттылар, Рамазан ае уразасы мәҗбүр булганчыга кадәр Пәйгамбәребез бу көндә ураза тотарга кушты. (Рамазан уразасы мәҗбүр булгач), Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм: «Кем тели, шул тотсын, ә кем тели – калдырсын», – дип әйтте», – дигән хәдис тапшырыла[2].

Яһүдиләр дә бу көнне зур бәйрәмгә санаганнар. Әбү Муса Әл-Әшгаридан тапшырыла: Хәйбәр кешеләре (яһүдиләр) Гашурә көнендә ураза тоттылар, ул көнне бәйрәмгә санап, хатын-кызларын кыйммәтле киемнәргә киендерделәр, бизәндерделәр. Шуннан соң Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләм (мөселманнарга): «Сез дә бу көнне ураза тотыгыз», – дип әйтте.

Кайбер хәдисләрдә насараларның да бу көндә ураза тотулары турында сөйләнелә. Шуңа күрә пәйгамбәрләрнең законнары, гореф-гадәтләре гасырлар аша узып, халык арасында сакланып калган, дип әйтергә була.

Рамазан аенда ураза тоту мөселманнарга беренче этапта ук фарыз булмады. Ул фарыз булганчы әле ике баскыч үтте. Мөгаз бине Җәбәл дигән сәхабә: «Намаз өч этап үтте, ураза да өч этап үтте. Башта (Пәйгамбәребез) һәр айның 3 көнендә һәм Гашурә көнендә ураза тота иде, аннан соң Аллаһы Тәгалә:

---

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан (1592)

2 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан (1893)

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ
لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾ أَيَّامًا مَّعْدُودَاتٍ ۚ فَمَن كَانَ مِنكُم مَّرِيضًا أَوْ عَلَىٰ
سَفَرٍ فَعِدَّةٌ مِّنْ أَيَّامٍ أُخَرَ ۚ وَعَلَى الَّذِينَ يُطِيقُونَهُ فِدْيَةٌ طَعَامُ مِسْكِينٍ ۖ فَمَن
تَطَوَّعَ خَيْرًا فَهُوَ خَيْرٌ لَّهُ ۚ وَأَن تَصُومُوا خَيْرٌ لَّكُمْ ۖ إِن كُنتُمْ تَعْلَمُونَ ﴿١٨٤﴾

«Ий мөәминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгәне кебек, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде, шаять, аны калдырудан яки аңа кимчелек китерүдән сакланырсыз! Ураза саналмыш көннәр. Сезләрдән берәрегез авырса, яки сәфәрдә булса, уразаны тотмасын. Авыру кеше сәламәтләнгәч, сәфәрдәге кеше өенә кайткач, калган көннәрен бер көн өчен бер көн тотып тәмам итәр. Авырлык белән тотучыларга фидия лязем – бер көн өчен бер мескенне бер көн ашату. Берәү бер мескен урынына күбрәк мескенне ашатса, артыгы үзенә хәерле. Әммә мескеннәрне ашатып өстегездән төшерүгә караганда, ураза тотуыгыз сезнең өчен хәерле, әгәр белсәгез».

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183-184

дигән аятьләрне иңдергәч, кайбер кешеләр ураза тотты, кем тели исә бер көн ураза өчен бер фәкыйрь кешене ашатты һәм бу алар өчен ураза кебек язылды. Бу бер ел буена сузылды, аннан соң Аллаһы Тәгалә:

شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ
وَالْفُرْقَانِ ۚ فَمَن شَهِدَ مِنكُمُ الشَّهْرَ فَلْيَصُمْهُ ۖ وَمَن كَانَ مَرِيضًا أَوْ عَلَىٰ سَفَرٍ
فَعِدَّةٌ مِّنْ أَيَّامٍ أُخَرَ ۗ يُرِيدُ اللَّهُ بِكُمُ الْيُسْرَ وَلَا يُرِيدُ بِكُمُ الْعُسْرَ وَلِتُكْمِلُوا
الْعِدَّةَ وَلِتُكَبِّرُوا اللَّهَ عَلَىٰ مَا هَدَاكُمْ وَلَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ ﴿١٨٥﴾

«Рамазан ае бик шәрифле ай, ул айда Аллаһтан кешеләргә туры юлны күрсәтүче һәм һидаятьне ачык бәян кыла торган Коръән иңдерелде. Сезләрдән Рамазан аена ирешкән һәрберегез, әлбәттә, ураза тотсын! Рамазан аенда берәү авыру булса яки мәшәкатьле озын сәфәрдә булса, ураза тотмасын, авыру кеше сәламәтләнсә, мосафир өенә кайткач, калдырылган көннәр санынча башка вакытта каза кылырлар».

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

дигән аятьне иңдерде. Шушы вакыттан бирле Рамазан аена ирешкән кешеләр өчен ураза фарыз булды. Сәфәрдә булган кешеләр кайткач, каза кылырга, ә ураза тота алмаучы олы кешеләр фәкыйрь кешеләрне ашатырга тиеш булдылар», – дип әйткән[1].

Кыскача бу чорларны түбәндәгечә аңлатып булыр иде:

1. Иң башта нәфел уразасы буларак ураза Гашурә көнендә һәм һәр айның 3 көнендә тотылган. (Бу Мәккә шәһәрендә башланып (һиҗрәткә кадәр), Мәдинәгә күчү белән тәмамлана).

2. Шуннан соң бу ураза фарызга әйләнде, әмма ураза тотучы ураза белән фәкыйрьләрне ашату арасында сайлый алган. Шулай итеп, мөселман ел дәвамында 37 көн ураза тотарга яки шуның кадәр кеше ашатырга тиеш булган. (Бу период Мәдинәгә күчкәч, бер ел дәвам итә).

3. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә әмер рәвешендә Коръәндә уразаны Рамазан ае буена тотарга куша. Һәм Рамазан аенда фәкыйрьләрне ашату һәм ураза арасында сайлау мөмкинчелеге булмый, әмма олы кешеләргә, авыру һәм юлда булучыларга карата хөкем шул ук кала.

Менә шушы этаплардан соң Гашурә һәм 3 көнлек ураза нәфел булып калдылар.

Гашурә уразасының фазыйләтләре:

---

[1] Имам Әбү Давыт хәдисләр җыентыгыннан: 507

1. Ислам диненең беренче елларында Гашурә уразасы фарыз ураза булып, соңыннан нәфелгә генә калса да, ул үзенең олуг дәрәҗәсен югалтмады. Әр-Рубайа бинт Мөгаза разыйаллаһу ганһә:

«Пәйгамбәр галәйһис-сәләм Гашурә көненең уртасында әнсарлар янына бер кешене җибәреп, аларга: «Кем иртәдән уразага кермәде, көннең калган өлешен уразада үткәрегез, ә кем иртәдән уразада, шул кеше уразасын дәвам итсен», – дип әйтергә кушкан. Шуннан соң без үзебез дә уразага кердек, балаларыбызга да уразага керергә куштык. Без аларга буялган йоннан уенчыклар ясый идек. Әгәр берәрсенең карыны ачып, елый башласа, без аларга ифтарга кадәр шушы уенчыкларны бирә идек», – дип әйткән[1].

2. Гашурә көнендә күп гасырлар элек бер зур вакыйга – Аллаһы Тәгаләнең могҗизасы була: Муса галәйһис-сәләм үзенең халкы белән артыннан куып барган гаскәрдән кача. Ул гаскәрнең башлыгы Фиргавен була. Аллаһы Тәгалә Муса халкына диңгездә юл яра, диңгез суы икегә бүленеп, коридор барлыкка килә, ә диңгез төбендәге җир коры була. Бу могҗизаны күрсә дә, үзенең имансызлыгы белән сукырайган Фиргавен барыбер шушы коридорга керә. Муса үз халкы белән икенче ярга җитүгә, Аллаһы Тәгалә диңгезне кире куша һәм Фиргавен үз гаскәре белән су астында кала. Бу баләдән котылу хөрмәтенә Муса шул көнне ураза тота башлый, аның халкы да аңа иярә. Ибн Габбас разыйаллаһу ганһү мондый хәдис тапшыра:

«Пәйгамбәребез Мәдинә шәһәренә һиҗрәт кылганнан соң, шушы шәһәрдә яшәгән яһүдиләрнең Гашурәдә ураза тотканнарын күрде. Ул алардан: «Нәрсә бу?» – дип сорады. Яһүдиләр: «Бу көнне Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребез Мусаны Фиргавеннән һәм аның гаскәреннән коткарган. Муса да бу көнне ураза тоткан», – дип җавап кайтардылар. Пәйгамбәребез аларга: «Муса пәйгамбәргә карата минем хокукым беренчедер…(мин ла-

[1] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан: 1960

еклырак)», – дип җавап бирде һәм үзе дә уразага кереп, калганнарга да бу уразаны тотарга кушты», – дип әйткән[1].

3. Аллаһ илчесе бу көнне ураза өчен аерым билгели торган булган. Гашурәдән кала төгәл датасына кадәр Пәйгамбәребез тарафыннан билгеләнә торган бүтән бер көн дә булмаган. Бу көн турында Ибн Габбастан сорагач, ул: «Пәйгамбәребезнең бер көннең икенчесенә караганда бөегрәк булганы аркасында, шулай ук бер айның икенче айга караганда бөегрәк булганлыгы аркасында ураза тотканын хәтерләмим. Бары тик бер ай һәм бер көннең бөеклеге аркасында ураза тота иде, ул – мөхәррам. Әмма Рамазан моңа карамый»[2], – дип җавап биргән.

4. Әгәр дә кеше бу уразаны хак курку белән куркып, ярлыкауга өмет белән башкарып чыга алса, аның узган ел өчен булган гөнаһлары ярлыканачак. Пәйгамбәребез галәйһис-сәләмнән Гашурә уразасы турында сорагач, ул: «Ул узган елгы гөнаһларның кичерелүенә сәбәп була», – дип әйткән.

Гашурә көне – мөхәррам аеның 10 нчы көне, бу сүз «гашәрә» тамырыннан, ягъни «ун» сүзеннән ясалган. Аллаһ илчесе уразаны Гашурә көнгә бер көн өстәп, йә 9 һәм 10, йә 10 һәм 11 тотарга кушты. Бу калган дин әһелләреннән аерылып тору өчен шулай кертелгән. Ибне Габбас разыйаллаһу ганһүдән тапшырылган хәдистә:

«Әгәр мин икенче елга кадәр яшәсәм, тугызы көнне, һичшиксез, ураза тотачакмын», – дип әйтелә. Шулай ук Ибне Габбас болай дип әйткән: «Аллаһ илчесе Гашурә көнне ураза тотканда, калганнарга да тотарга кушты. Әмма алар: «Йә, Аллаһ илчесе, бу көнне яһүдиләр һәм насаралар да олуглыйлар», – дип әйттеләр. Шуннан соң Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләм:

---

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан: 2004

2 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан: 2718

«Киләсе ел җиткәч, ин шә Аллаһ, тугызынчы көнне дә ураза тотачакбыз», – дип әйте»[1].

Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгында мондый хәдис китерелә: «Гашурә көнендә ураза тотыгыз. Бу эшегездә яһүдиләргә каршы булып, йә бер көн алдан, йә бер көн арттан уразага өстәгез».

Әлеге хәдисләрдән чыгып, шуны әйтергә була: Гашурә уразасын ике көн тоту хәерлерәк. Шулай итеп:

1. Иң яхшы ураза булып тугызы һәм унысы тоткан ураза булачак.

2. Дәрәҗәсе ягыннан бераз түбән булып унысы һәм унбере тоткан ураза тора.

3. Тагын да түбән булып бер генә көн тоткан ураза санала (10 нчы мөхәррам).

Бу уразадан нинди файда алып була? Бу дата нинди вакыйгаларга бәйле?

1. Гашурә көнендә ураза тоту – Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең сөннәте, шуңа күрә бу көндә ураза тоту хәерле гамәл санала. Кеше Пәйгамбәрнең үрнәгенә күбрәк иярген саен, ул кешене Аллаһы Тәгалә дә шулкадәр күбрәк ярата. Шулай ук, һәрбер яхшы гамәл үзе артыннан икенче яхшы гамәлне ияртә. Ә һәрбер начар гамәл үзе артыннан икенче начар гамәлне ияртә.

2. Бу көннең уразасын Пәйгамбәр Мөхәммәд һәм аның сәхабәләре генә тотып калмыйча, шулай ук Муса һәм аның сәхабәләре дә тоткан. Бу урында шуңа басым ясарга кирәк: Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм бу көндә ураза тотуны яһүдиләрдән алмаган. Алда әйтеп үтелгәнчә, ул бу уразаны Мәдинәгә күченгәнче үк тоткан. Ә Мәдинәгә күченгәч, ул яһүдиләрдән ни өчен алар да бу көнне уразада булуларын һәм бу көнгә нинди мәгънә биргәннәрен беләсе килеп кенә сорый. Шуңа күрә Пәйгамбәребез бу ура-

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан: 2722

зага тагын бер көн өсти. Бу, киресенчә, Пәйгамбәребезнең аларга охшарга тырышмаганлыгын күрсәтә.

3. Гашурә көне безгә Аллаһы Тәгаләнең рәхимлелеге турында, Аның пәйгамбәрләренә карата яратуын исебезгә төшерә. Пәйгамбәрәрнең үз халкы аларны онытсалар да, зурламасалар да, Аллаһ бу вазифаны икенче халыкка бүләк итә. Шуңа да мөселманнар бу вакыйгалар турында онытмаска тиеш.

4. Бу көн безгә кешеләр арасындагы якынлык туганлык җепләре белән генә үлчәнмәгәнлеген күрсәтә. Чын туганлык дип диндәге кардәшлекне атап булыр иде. Пәйгамбәр галәйһис-сәләм яһүдиләргә үзен Мусага аларга караганда да якынрак дип әйткән. Гәрчә алар Муса яки аның сәхабәләре нәселеннән булсалар да. Алар Муса алып килгән тәгълиматтан күптәннән читләштеләр, ә мөселманнар әле дә Мусаны пәйгамбәр буларак яраталар.

5. Гашурә көне Аллаһы Тәгаләнең кодрәтен дә күрсәтә торган көн. Аллаһы Тәгалә бу көндә зур могҗиза – диңгезне икегә аерып күрсәтте. Бу исә Аллаһы Тәгалә өчен бернинди мөмкин булмаган әйберләр юк икәнен күрсәтә. Барлык физика законнары, без белгән һәм белмәгән фәннәрне Аллаһы Тәгалә Үзе бар кылды һәм Үзе теләгәнчә алар белән идарә итә ала. Әмма бу законнар Аллаһның Үзенә берничек тә тәэсир ясый алмыйлар.

6. Бу датаны истәлекле иткән вакыйгалар безгә иман китергән бәндәләрнең көчен аларның иманнарында икәнен күрсәтә. Ягъни кеше куәт, корал, ниндидер әзерлекләр белән көчле түгел, ә үзенең Алаһка булган иманы белән көчле. Муса артыннан куган Фиргавен гаскәре ул вакытларда иң көчле армияләрнең берсе була, ә бәлки андый көчкә ия бердәнбер гаскәр дә булгандыр. Муса һәм аның халкы алар белән каршы торырлык түгел иде, алар бер кырда очрашкан булсалар, әлбәттә, җиңелгән булырлар иде.

Шуңа күрә, тормышта ниндидер кайгы-хәсрәт килеп чыкса, бу Аллаһтан сынау булып, аннан чыгу юлын да Аллаһы Тәгалә Үзе бирәчәк дигәнне аңлата. Безгә үзебез өстендә эшләргә генә кала.

7. Бу хәдисләрдән тагын бер файда – һиҗри календарь. Ислам динендә һәрбер олы вакыйгалар безнең хәтердә һиҗри календарь даталары буенча истә калган. Бу исә без, мөселманнарга, бу календарь белән дә яшәргә кирәклекне аңлата. Кояш календаренда да 30-31 көн бер ай дип атала. Ай календаренда яңа ай туып, икенчесе туганчы бер ай булып санала. Кояш календәре безгә күп очракта авыл хуҗалыгында кирәк булса (утырту, чәчү эшләре елның бер вакытына көйләнгән), ай календаре дини вакыйгалар, бәйрәмнәр өчен кирәк.

Ай календаре куллануда уңайлы һәм һәрбер кеше өчен җиңел календарь. Әмма Татарстан җирлегендә ай берничә көн чыкмыйча торуы бар. Шулай да кояш календаре кебек аерым математик санаулар кирәк түгел.

Гашурә көне барлык мөселманнар өчен дә күркәм бәйрәм булып саналса да, шигыйлар бу көнне кайгы һәм хәсрәт көне буларак билгеләп үтәләр. Бу көндә Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләмнең оныгы Хөсәен гаделсез рәвештә үтерелә. Шигыйлар бүгенге көнгә кадәр 10 нчы мөхәррәмне траур матәм буларак билгеләп үтәләр. Үз-үзләрен кыйнау, аркаларын, битләрен кисү – болар барысы да алар үзләре уйлап чыгарган һәм пакь Ислам диненә кагылышы булмаган гамәлләр. Аллаһ безне мондый ялгышлыклардан ерак тотсын!

Гашурә – бик күркәм көн. Гашура көнендә шактый күп әһәмиятле, тарихи, сөенечле вакыйгалар булган. Шуларның аеруча мөһим булганнары Аллаһның пәйгамбәрләре белән бәйледер. Бу көнне Бөек Раббыбыз бу дөньяны, Адәмне яраткан, нәкъ бу көнне Адәм тәүбәсе кабул ителгән; Нух көймәсе тауга килеп җитеп, андагы мөэминнәр туфаннан котылган; бу көнне Ибраһим пәйгамбәр туган һәм мәҗүсиләрнең учагыннан коткарылган, Гайсә һәм Идрис пәйгамбәрләр күккә ашкан; Муса пәйгамбәр һәм

аңа ияргәннәр Фиргавеннең эзәрлекләвеннән котылганнар, Фиргавенне шул көнне диңгез сулары йоткан; Юныс балык карыныннан исән-имин чыгып котылган; Әюб пәйгамбәр авыр чирдән савыккан; озак елларга сузылган аерылышудан соң Ягъкуб улы Йосыф белән очрашкан; Йосыф зинданнан чыккан; Сөләйман пәйгамбәр патша булган.

Шулай итеп, догалар, теләкләр кабул ителгән һәм бик күп бәлә-казалардан котылуга сәбәп булганы өчен, Гашура көне котлы вә шатлыклы бер көн булып исәпләнә.

Камил хәзрәт Сәмигуллин,

Татарстан Республикасы мөфтие

14 нче сентябрь вәгазе,

Мөхәррам аеның 4 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел

«Хизбүт-тәхрир» – адашканнар хәрәкәте

Галәмнәрнең Раббысы булган, безне хак юлга күндерер өчен үзенең пәйгамбәрләрен җибәргән Аллаһка барча мактауларыбыз, шөкраналарыбыз булса иде. Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вәсәлләмгә, аның хөрмәтле гаиләсенә һәм барлык сәхабәләренә күңел түрләребездән чыккан ихлас сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Мөхтәрәм җәмәгать! Соңгы елларда Россиядә «Хизбүт-тәхрир әл-ислами» («Ислам азатлык партиясе») дип аталган дини хәрәкәт тарала башлады. Бу дини төркемнең юлы гасырлар дәвамында илебез җирендә яшәгән мөселманнарның дини карашларына, гамәл тәҗрибәләренә туры киләме? Аларның фикерләрен кабул итә алабызмы? Бүгенге вәгазебезне без шушы темага багышлыйбыз.

«Хизбүт-тәхрир» – адашкан фирка, аларның карашлары һәм гамәлләре турыдан-туры Коръәнгә, Сөннәткә һәм мәзһәбкә каршы килә. «Хизбүт-тәхрир» агымына нигез салучы – Тәкыеддин Ән-Нәбһәни. Ул 1909 елда Фәләстыйн җирендәге Иҗзим авылында туа. Тәкыеддин Ән-Нәбһәни яшьтән үк Коръәнне күңелдән өйрәнә, дини гыйлемне шушы өлкәдәге шәех-остазлардан ала, аннан соң, белемен арттыру нияте белән, мәшһүр ислам уку йортында – «Әл-Әзһәр» университетында укый.

1953 елда ул Үрдүн (Иордания) җирендә үзенең яңа җәмәгатен оештыра, җәмәгатьнең төп юнәлеше ислам хәлифәлеген төзүгә, аны булдыруга юнәлгән була, ләкин хөкүмәт тарафыннан аның карашлары хуплан-

мый: Тәкыеддин Ән-Нәбһәнине Иордания дәүләтеннән куып җибәрәләр. 1977 елда ул Бәйрут шәһәрендә вафат була һәм шунда күмелә.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Һәрбер дини юнәлешнең нигезе булырга тиеш. Безнең нигезебез (хак ислам дине) өч әйбердән гыйбарәт: Коръән, Сөннәт һәм мәзһәб. Хизбиләр исә – Коръәнгә, Сөннәткә һәм мәзһәбкә каршы килүчеләр, башкача әйткәндә, алар үз нәфесләренә ияреп, наданлык чокырына баткан кешеләр. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип кисәтә:

وَمَن يُشَاقِقِ الرَّسُولَ مِن بَعْدِ مَا تَبَيَّنَ لَهُ الْهُدَىٰ وَيَتَّبِعْ غَيْرَ سَبِيلِ الْمُؤْمِنِينَ نُوَلِّهِ مَا تَوَلَّىٰ وَنُصْلِهِ جَهَنَّمَ ۖ وَسَاءَتْ مَصِيرًا ﴿١١٥﴾

«Әгәр кем дә кем туры юлны (исламны) табып та, Расүлгә (фикере, сүзе яки гамәле белән) каршы килеп, хак мөселманнар юлына (сәхабәләр, тәбигыйннәр юлына) иярмәсә, Без аны үзе теләгән юлдан җибәрербез, җәһәннәмгә кертербез. Аһ, бик тә хәтәр ул җәһәннәм».

«Нисә / Хатыннар», 4:115

Бу аять ислам гакыйдәсендә иң әһәмиятле хөкемнәрдән санала. Аятьнең мәгънәсенә игътибар итик әле: Аллаһ Раббыбыз аятьтә ияру асылын төгәл аңлата. Беренчедән, ияру – Аллаһ Китабына булырга тиешле; икенчедән, ияру – Аллаһның расүле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлләмгә тиешле һәм иң әһәмиятлесе – дини гакыйдәбез (карашларыбыз) әһлес-сөннәт вәл җәмәгать мөселманнарына, ягъни иң әүвәл сәхабәләргә, аннан соң тәбигыйннәргә, аннары имам Әбү Хәнифә, имам Әбү Мансур Матуриди, имам Мөхәммәд (Аллаһ аларны үз рәхмәтеннән аермаса иде) кебек танылган галимнәребезгә туры килергә тиеш.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлләмнең сәхабәсе Ирбад бине Сария (Аллаһ аннан разый булсын) риваять иткән: «Бер көнне Аллаһ

илчесе салләллаһу галәйһи вәсәлләм безне бик нык вәгазьләде, аны тыңлаганда күңелләребез тетрәнде һәм күзләребездән яшьләр акты. Без: «Син безнең белән саубуллашасың кебек, ий Аллаһ илчесе, безгә васыять-киңәшләреңне бирсәң иде», – дидек. Расүл Әкрам салләллаһу галәйһи вәсәлләм болай диде: «Аллаһтан чын курку белән куркыгыз, сезнең өчен куелган (мөселман патшаларына, әмирләргә, голәмәләргә, мөфтигә, казыйларга) итагатьле булыгыз, дип васыять итәм. Хәтта, сезнең өчен патша буларак, бер мескен хәбәшә колы (Эфиопиянең кара тәнле колы) куелса, аңа да итагатьле булыгыз. Дөреслектә, кем миннән соң яши, ул күп низаглар, ихтиләфләр күрер һәм шул вакытка туры килгән кешегә минем сөннәтемә һәм тугры хәлифәләрнең (сәхабәләремнең) сөннәтенә ябышу тиеш булыр. Шушы сөннәткә тешләрегез белән ябышыгыз һәм бидгать гамәлләрдән ерак булыгыз, чөнки бидгатьләр – адашу ул»[1].

Әгәр хизбиләрнең юлына карасак, алар югарыда әйтелгән аятькә, хәдискә тулысынча хилафлык китерә, чөнки ияруү мәсьәләсендә мәзһәбкә карамыйлар һәм динне әһлес-сөннәт вәл җәмәгать аңлаганча аңламыйлар, хөрмәтле сәләфләребез (беренче гасыр галимнәре, танылган мөхәддисләр) әсәрләренә игътибар итмичә, динне үз белдеклелекләре белән аңлыйлар.

Алар, сахих (дөрес) хәдисләрне шикле дип, шәргый чыганакларны кабул итми. Хизбиләр хәлифәлек төзергә омтыла, бу ашкыну наданлыктан килеп чыга. Алар фикеренчә, хәлифәлек булмаганда шәригатьнең шактый өлеше тормышта үтәлмәсә дә ярый. Моңа рөхсәт барлыгын искәртәләр, шуңа күрә аларның ирләре җәмәгать белән намаз укымый, алар тәмәке тартырга, җенси мөнәсәбәт, якынлык турында фильмнар карарга (ул хәрам гамәлләрдән санала) рөхсәт итә. Хатыннарына кысан, тар, гаурәтләре күренеп торган киемнәр киеп йөрергә рөхсәт итәләр, Аллаһ сакласын!

---

[1] Имамнар Әбү Давыт, Тирмизи хәдис җыентыкларыннан

Мөхтәрәм җәмәгать! Данлыклы галимнәребез хәлифәлек мәсьәләсе турында: «Ислам дәүләтен иң әүвәл күңелдә, калебтә торгызырга кирәк, калебтә торгызылган ислам дәүләте җирдә дә торгызылачак», – дип әйткән. Нинди тирән мәгънәле сүзләр! Чыннан да, хизбиләргә карасак, аларның ислам дәүләте телдә генә, калебләрендә исә ислам дәүләте юк.

Шулай ук, хизбиләр иман шартларының кайбер өлешләренә дә каршы килә. Алар кабер газабын инкяр итә, аңа ышанмый. Кабер газабы хакында хәдисләрне бер сәхабә генә риваять иткән дип әйтәләр, шуңа күрә андый хәдисләрдә ялган сүз, уйдырмалар, өстәмә сүзләр булырга мөмкин диләр. Имам Бохари җыентыгындагы шактый хәдисләрне кабул итмиләр, аны кабул итмәүләре бер хәл, хәтта Коръән аятьләренә дә шикләнеп карыйлар. Мисал өчен, Коръәндә болай дип әйтелә:

النَّارُ يُعْرَضُونَ عَلَيْهَا غُدُوًّا وَعَشِيًّا ۖ وَيَوْمَ تَقُومُ السَّاعَةُ أَدْخِلُوا آلَ فِرْعَوْنَ أَشَدَّ الْعَذَابِ ﴿٤٦﴾

«Алар (кәферләр, монафикълар) (каберләрендә) Кыямәткә хәтле иртә-кич ут газабына дучар булыр. Фиргавенгә һәм аның токымына җәзаның иң хәтәрен бирегез», дип Аллаһ фәрештәләргә әмер бирер».

«Мөәмин», 40:46

Ибне Кәсир, Ибне Җәрир, Муҗәһид, Зәйд бине Әсләм (аларга Аллаһның мәрхәмәте булсын) кебек мәшһүр мөфәссирләр бу аять кабер газабы хакында дип әйткәннәр. Хизбиләр исә бу аятьнең төп асыл мәгънәсен бозып, икенче мәгънәгә әйләндерә.

Кабер газабы турында сахих (дөрес) хәдисләр дә бик күп. Мәсәлән, имам Бохари җыентыгында Гайшәдән (Аллаһ аннан разый булсын) риваять ителә: «Бервакыт Гайшә янына бер яһүди хатын килеп, аңа болай дип әйткән: Аллаһ сине кабер газабыннан сакласын». Шуннан соң Гайшә бу

хакта, ягъни кабер газабы турында, Расүлүллаһтан сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлләм яһүди хатынның сүзен раслап, хәтта үзе дә кабер газабыннан Аллаһка сыенган»[1].

Икенче бер хәдисләрдә әйтелгәнчә, үлгән кешеләрнең тәннәре каберләргә җирләнгәч, җаннар үзләренең тәннәре янына – кабат җиргә әйләнеп кайта. Шуннан соң җан янына Мөнкир белән Нәкир исемле ике фәрештә килә. Алар мәеткә торып утырырга куша һәм: «Раббың кем? Динең нинди дин? Пәйгамбәрең кем?» – дигән өч сорау бирә. Иманлы кеше шушы сорауларга дөрес җавап бирә, ә имансызлар бөтенләй җавап бирә алмый, моннан соң мәрхүмнәр, нинди җавап бирүләренә һәм гомерләре буена нинди гамәлләр кылуларына карап, савапларга ирешә башлый яисә җәзаларга дучар була. Кабер газабы турында башка бер хәдистә болай дип әйтелгән: «Кабер ул – буш дөнья түгел. Иманлы бәндә өчен ул җәннәт бакчаларыннан бер бакча, имансыз кеше өчен җәһәннәм чокырларыннан бер чокыр булачак»[2].

Шулай ук, хизбиләр Мәсих Дәҗҗалның килүен инкяр итә. Мәсих Дәҗҗал хакындагы риваятьләрне кабул итмиләр. Дәҗҗалның барлыкка килүе Кыямәт көненең иң зур ун билгеләренең берсе булып санала. Аның барлыкка килүе кешелек өчен бөек сынау булачак, коткы һәм фетнә чыгарачак. Дәҗҗал гадәттән тыш көчкә ия кеше булачак һәм үзен илаһ дип белдерәчәк. Хәдисләрнең берсендә бу хакта болай дип әйтелгән: «...Адәм барлыкка китерелгәннән бирле җир йөзендә Дәҗҗал кебек башка коткы булмаган...».

Шулай ук, хизбиләр Гайсә галәйһис-сәләмнең кабат килүенә ышанмый. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлләмнең хәдисләрендә әйтелгәнчә, Дәҗҗалның җирдә булырга тиешле вакыты төгәлләнгәннән соң, Аллаһ, аны һәлак итү өчен, җиргә Гайсә галәйһис-сәләмне төшерәчәк. Гайсә галәиһиссәләм, җиргә иңгәннән соң,

[1] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

[2] Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан

Бәйтелмәкъдискә (Иерусалимга) юнәлеп, Дәҗҗалны эзәрлекли башлаячак. Куып җиткәч, аны Бәб Лүдд (Суриядәге тау) тирәсендә үтерәчәк. Мөселманнар, Гайсә галәйһис-сәләмгә ияреп, Дәҗҗалның гаскәрен җиңеп юк итәчәк. Хизбиләр моңа ышанмый.

Газиз дин кардәшләрем! Аллаһ Раббыбыз һәммәбезне дә төрле адашулардан сакласа иде. Хак динебезне өйрәнеп, изге гамәл-гыйбадәтләр кылып яшәргә насыйп итсә иде!

ТҖ МДН Дәгъват бүлеге

21 нче сентябрь вәгазе,

Мөхәррам аеның 11 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел

Вahhабилар – кемнәр алар?

Безләрне иман белән нигъмәтләндереп, мөселман кылган, Пәйгамбәребезнең юлыннан, сәхабәләр юлыннан, пәйгамбәрләр варислары, динебезнең сакчылары – ислам галимнәре юлынннан, сыйратальмустакыймнан, ягъни туры юлдан алып баручы Раббыбыз Аллаһка мактау-олуглауларыбыз булса иде.

Әһлес-сөннәт вәл-җәмәгать юлыннан аерылып, галимләребезгә каршы чыгып, динебезгә адаштыручы һәм аңа хас булмаган бидгать фикерләр, зарарлы яңалыклар кертә торган фиркаларның явызлыгыннан Раббыбыз Аллаһ өммәтебезне, милләтебезне сакласын. Чынлыкта, вahhабилык сыман чит, адашкан фиркаларның динебезгә керткән бидгате җәһәннәм утындадыр.

Әл-Һәди булган Раббыбыздан туры юлда булганнарны адаштырмавын, вahhабилар сыман аерылганнарны һәм адашканнарны һидәяткә кертүен сорыйбыз. Чынлыкта, Раббыбыз Аллаһ Әл-Һәдидер, бер Ул гына һидәят кылучыдыр.

Кадерле җәмәгать, сезне адашудан кисәтүебезгә Аллаһ Үзе һәм Аның фәрештәләре шаһит булсын. Сезнең өстегездәге вазифа – җәмәгать белән булып, дини гыйлем алып, иманыгызны шайтан тозакларыннан, адаштыра торган фиркаларның зарарыннан саклаудыр. Раббыбыз Аллаһ бу фетнәләрне җиңеп чыгуда ярдәмчебез булсын.

Вahhабилык адашкан һәм адаштыра торган, бозык һәм ялгышкан бер фиркадыр. Ул унсигезенче гасырның уртасында Гарәбстан ярымутравында, Нәҗдә өлкәсендә барлыкка килгән. Бу фиркага нигез салучы булып Мөхәммәд бине Габделваһһаб тора. Бу шәхес Ибне Тәймиянең

фикерләре белән тәгъсирләнеп, аның бозык уйлары һәм карашларын таратуда баш роль уйнады. Бу фиркага бәйле булганнарга һәм иярүчеләргә ислам галимнәре тарафынан вәһһабилар исеме бирелде. Сүзләренә ышандыру өчен сәләфи салихин (хөрмәтле сәхабәләр ва тәбигыйннар) юлында булганнарын сөйләп, бу сәләфиләр үзләренә әһлес-сөннәт исемен бирделәр. Игътикадта (гакыйдәдә) сәләфи гамәлләрендә иң башта хәнбәли мәзһәбендә булуларын дәгъва кылдылар, бүгенге көндә исә бишенче мәзһәб төземәкче булалар.

Алар дүрт шәргый дәлилләрдән иҗмагъ вә кыясны кабул итмиләр. Вәһһабилар дүрт хак сөнни мәзһәбләрне танымыйлар, аларның берәрсенә багламуны һәм иярүне кире кагалар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең чапанын вә мөбарәк сакалын зиярәт итүләрне ширеккә саныйлар. Коръән Кәримнең кайбер аятьләренә һәм кайбер хәдисләргә үзләренең игътикадларына туры китереп ялгыш мәгънә бирәләр, шул сәбәптән бөек Аллаһы Тәгаләне мәхлукатларга охшаталар. Бөек Аллаһы Тәгаләнең тәне булуы турында сөйлиләр, Аның күктә булуын һәм гарешнең өстендә утыруына ышаналар.

Шулай ук алар:

– Коръән укып, сәвапларын әрвахларга тапшыруны тыялар;

– мәүлид үткәрүне бидгать дип әйтәләр, мәүлид үткәрүгә каршы чыгалар;

– намаз кылмаган мөселманнарны диннән чыга һәм имансыз була, дип әйтәләр.

Туры юлда – чын әһлес-сөннәттә булган матурудилеләрне, ягъни безне һәм әби-бабайларыбызны, бөек татар галимнәрен адашуда, батыл, ялган юлда, дип мыскыллап сөйлиләр. Башкача әйткәндә, үзләрен алар сәләфи дип атыйлар, әмма мантыйк ягыннан да аларның сәләфи булулары мөмкин түгел. Сәләф дип сәхабәләрне, тәбигыйннәрне һәм алар-

ны күргән нәселне атыйлар. Шуңа күрә безнең заманыбызда сәләфләр рәтеннән булырга инде мөмкин түгел.

Вahhабилык йогынтысы җирлегебезгә егерменче гасыр башында ук үтеп кергән. Шуңа күрә «Дин вә мәгыйшәт» журналының 1911 елгы саннарын алып карасагыз, аның һәр санында «Вahhабилар кем була?» дигән тема астында басылган дини-гыйльми язмаларны күрергә мөмкин. Инкыйлаб булып, совет хакимияте урнашкач, ниндидер дини агымнарга гына түгел, исламга, дин әһелләренә бөтенләй диярлек капкалар ябыла. Тимер пәрдәләр Горбачев хакимияткә килеп, үзгәртеп кору сәясәте башлангач кына, ачыла. Динне өйрәнергә, җәелдерергә мөмкинлек бирелә.

Ләкин акрынлап безнең фикһи һәм игътикадый мәзһәбебезгә каршы булган агымнар үтеп керде. Ни кызганыч, бу йогынты әле дә дәвам итә. Татарстанда гына түгел, вahhабчылык барча республика-өлкәләрдәге мәчет-мәдрәсәләргә, нәзарәтләргә үтеп керде. Галимнәребез йөз ел элек үк матбугатыбызда әлеге агымның милләтебезгә, динебезгә, мәдәниятебезгә китергән зыяны турында яздылар. Әмма бер гасыр элек булган кисәтү-искәртүләрне онытканбыз.

Мәчетләрдән вahhабилар чыгарылсалар да, алар үзләренә интернетта зур мәйдан тапты. «ВКонтакте» челтәрендә генә Казанга, Татарстанга бәйле 188 вahhабчы төркем бар. Ватсап, фейсбук, инстаграм, телеграммда тагын күпмедер?! Бу – үзе бер зур дөнья! Анда – яшьләр! Алар чит илдә белем алдылар, күпме китаплар тараттылар һәм бүген дә алар үз китапларын саталар, тараталар. Милләттәшләребез шушы рәвештә акрын гына андагы идеяләр белән агулана.

Мондый агым-хәрәкәт булганлыгын танырга кирәк, күрмәмешкә салышырга ярамый. Хаклыкны белеп тә эндәшми торган кеше – сакау, телсез, ихтыярсыз бәндә ул. Мин бу милләтнең баласы икән, аңа хезмәт итәргә, аны якларга, сакларга тиеш. Мәчетләргә татар телен ныклап кертә башлагач, җомга вәгазьләрен татарча сөйләү мәҗбүри дип куелгач, соци-

аль челтәрләрдә иң беренче булып тавыш куптаручылар вahhабилар булды. Телебезгә шундый нәфрәт кайдан киләдер?! Югыйсә татар телендәге сүзлек составының биштән бере – Коръән теленнән. Иман, ислам, мәсҗид, мәдрәсә, хикмәт, тәрбия, әдәп, әхлак һәм башкалар…

Фетнә ул – йоклый торган нәрсәдер. Аны уяткан кешене Аллаһы Тәгалә ләгънәт кыла. Күптән түгел генә ватсапта бер мөслимә кардәшебезнең Казан базарында ит сатып торуын күрсәттеләр. Узып баручы бер авылдашы моңа аңлатма бирә: «Яулык бәйләгән әлеге кешене мин беләм. Ул бит биш вакыт намаз укымый. Ул – имансыз. Аңардан ит сатып алучы хәрам ашаган була». Йә Аллаһ! Ул бит үз авылдашын тәкфир кылды, ягъни имансыз дип игълан итте. Татар авылында асралган, «бисмилләһ» әйтеп чалынган малны хәрамга чыгарды. Ул, юньле кеше булса, авылдашы янына килеп сәлам бирергә, хәлен сорашырга тиеш иде. Аны кичке ашка чакырып, гаиләсе белән таныштырырга; кунарга урыны булмаса, кундырып чыгарырга; аның аша авылдагы кардәшләренә бүләкләр биреп җибәрергә тиеш, ләбаса. Әле бит мосафир хакы бар. Хәзер бит кайбер төбәкләрдә атасы бер, улы – икенче мәчеткә йөри торганнар бар. Болай аерылган, бер-берсенә дошман күзе белән караган, бер-берсен имансыз санаган милләтнең киләчәге юк.

Кайбер имамнар бу фирка хакында сүз әйтергә куркалар. Проблема килеп чыгар, дип шикләнәләр. Кайбер имамнар алардан акча да ала. Берәр төрле кичә-бәйрәм уздырганда, алар мәчет чыгымнарын каплаучы иганәче буларак ярдәм итәләр. Кайберләре – яшерен вahhабчылар. Үзләрен Әбү Хәнифә мәзһәбендә дип йөрсәләр дә, башкача гамәл кылалар. Кайсы мәдрәсәдә укыган, бүген нинди дәреслекләрдән сабак бирә, янәшәсендә кемнәр бөтерелә – нәтиҗәне шуннан да белеп була.

Вahhабчыларга ялгышканлыкларын, милләтебезгә зарар китерүләрен аңлатырга кирәк. Өммәтебез, динебез мәнфәгате иң югары, иң кыйммәтле. Шуны саклыйк, кадерлик, хыянәт итмик. Хыянәт

итүчеләрне туктатыйк. Саташтырмасыннар! Адаштырмасыннар! Безгә нәфрәт кирәкми, мәхәббәт кирәк. Милләттәшләребезне тупларга, дуслаштырырга иде. Алдыбызда торган катлаулы проблемаларны хәл итү, чишү өчен дуслык, бердәмлек, куәт кирәк. Куәт-егәр булмаса, аларны хәл итә алмыйча, тарих чүплегендә калуыбыз бар.

Йә Раббым, безне Үзең туры юлга бастырганнар арасында туры юлдан алып бар, Үзең тәрбияләгәннәр арасында безне тәрбиялә. Вahhабият юлыннан китеп, адашкан мөселман кардәшләребезне ярлыка, аларга Үзеңнең мәрхәмәтеңне күрсәтеп, туры юлга бастыр. Өммәтебезне, милләтебезне вahhабчылык сыман чит, адашкан фиркаларның зарарыннан сакла вә шайтанның корган тозакларыннан безләрне имин кыл.

Габдрауф хәзрәт Зәбиров,

«Миргазыян» мәчете имам-хатыйбы

28 нче сентябрь вәгазе,

Мөхәррам аеның 18 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел

Хариҗиләр һәм аларның дәвамчылары

Барча дөньяларның Раббысы булган Аллаһы Сөбхәнә вә Тәгаләгә чиксез мактаулар булсын, Ул безгә ихлас мөселманнар булырлык иман шәфәгатьләрен бирүче, тәрбия-тормыш ихтыяҗларын тәэмин итүче. Аллаһның яраткан Расүле һәм Пәйгамбәре Мөхәммәдкә һәм аның изге гаиләсенә, сәхабәләргә хәер-рәхмәтләр насыйп әйләсә иде.

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) алдан белеп әйткәнчә, аңардан соң һәм аның сәхабәләреннән соң, шулай ук Гомәр бине Хаттаб үлеменнән соң, Ислам дөньясында фетнәчеләр барлыкка килде, һәм алар, торган саен көчәеп, бүгенге көнгә кадәр җәмгыятьне куркыныч астында тоталар. Мондый адашкан фирка-агымнар иң рәхимсез, мәрхәмәтсез каты фетнәләрнең, кирәксезгә чыккан сугышларның сәбәбе булып тора. Искәртеп китик, мөселманнарның зәгыйфьлеге һәм каршылыкларга, авырлыкларга чыдамаулары тышкы дошманнар-фетнәләрдән тормый, ә эчке ризасызлыклар, җәмгыятьтәге эчке фикер каршылыклары аркасында килеп чыгалар.

Хариҗиләр бөтенләй гөнаһ булмаган гамәлләрне көферлек итеп, диннән чыгарырдай зур гөнаһка этәрүче нәрсә дип саныйлар, ягъни болар кешеләрне урынсызга кәфергә чыгаралар да, бер мәгънәсезгә хаксыз көферлектә гаепләп, шул гаеп өчен җәзалыйлар. Безнең илебездә федератив закон тарафыннан дәүләт диннәреннән кала, теләсә нинди дини агымнарның эшчәнлеге тыелган. Шулай булса да, җиребездә әледән-

әле Ислам турында аерым фикерле мөселманнар чыккалап тора. Без бу җәмәгатьнең мондый фикерләренең килеп чыгышын тикшереп карыйк.

Хариҗиләрнең «Җәмәгат-уль-Һиҗрә вәт-тәкфир» дигән башка исеме дә билгеле, шуннан аларны тагын «тәкфирчеләр» дип тә йөртәләр. Алар мөселманнарны динсезлектә булганнардан аерылып, башка җирләргә китеп яшәргә чакыручылардан булып торалар. Бу фиркага 1928 елда Хәсән Әл-Бәннә исемле кеше нигез сала, хариҗиләрнең өстәл китабы булып Мисырдагы сәяси җинаятьче, төрмәләрдә утырган Сәйид Кутбның «Мөселман-кардәшләр» («Ихвәнә-мөслимүн») исемле китабы тора. 1960 елларда төрмәләргә ябылу һәм 1966 елда Сәйид Кутбның җәзалануы яшь мөселманнарны, Кутб идеологиясен башкача тануга илтә, тагын да зәһәрләтә, 1971 елны алар баштанаяк коралланалар һәм законсыз көч куллана башлыйлар. 1978 елның мартында бу фирканың 5 лидерын җәзалыйлар.

Илебездә 20 нче гасыр азагында гына барлыкка килсә дә, мөселманнарны тулаем гел көферлектә гаепләп, җәмәгатьне мөшрик-кәфер дип, төрле группаларга бүлүче борынгы дини агымнар белән бәйләнгән бу фирка мөселманнар дөньясының олы проблемасы булып тора. Расүлүллаһ (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) аларның бу агымының зур куркыныч булуы турында кисәтеп куйган, узенең берничә хәдисләрендә хариҗиләр киләсен сөйләгән, аларның мөселманнарны нигезсез көферлектә гаепләвен, үзләре белән риза булмаганнарны каты җәберләвен, җәмәгатьне төрле төркемнәргә бүлүе турында әйтеп киткән, аларның куркынычлыгы турында искәртеп киткән.

Әгәр тарих битләренә күз салсак, без бу төркемнең беренче күренешен инде Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) вакытында ук урын алганын күрәбез. Бервакыт Расүлүллаһ мөселманнар арасында зәкәтне бүлгән вакытта, бер кеше чыгып, Аллаһ Илчесенә (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) мөрәҗәгать иткән:

«Йә Мөхәммәд, Аллаһтан курык, гадел бул», – дип ризасызлык белдергән. Димәк, ул үзенең гаделлек өчен көрәшүен Пәйгамбәргә караганда да күбрәк тырышып кылган итеп санаган. Ул үзен бик гадел итеп күргән, ә Расүлүллаһны, янәсе, гаделсезлектә фаш иткән: «Аллаһтан курык, әй, Мөхәммәт, гаделлек өстә», – дип әйтергә җөрьәт иткән. «Гадел бул, ягъни син эшләгән эш гаделсез, хаксыз», – дигән кебек кешеләр арасында иң бөек кешене, Аллаһның Расүлен (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) гаделсезлектә, хаксызлыкта гаепләгән. Шунда Расүлүллаһ: «Сиңа үкенеч булсын! Мин гаделсез булсам, монда миннән дә гаделлерәк кем бар соң?!» – дигән. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) аңа бу сүзләрен ачуланып әйткән.

Имам Мөслим хәдисләрендә Расүлүллаһ (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) хариҗиләрне «шәрруль-хальк» – иң начар, иң куркыныч кешеләр итеп билгели, бик хәтәр, мәкерле халык итеп тасвирлый. «Хариҗ» сүзен гарәп теленнән тәрҗемә итсәк, «хараҗә» – خَرَجَ – «чыгарга», «кайдандыр чыгарга» мәгънәсен белдерә, шәригать термины «үзләре белән риза булмаган мөселманнарны көферлектә урынсыз гаепләүчеләр төркеме» итеп билгели. Әлеге төркем халыкны мөселманнар хакимиятенә буйсынмаска өнди.

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) безне ялгышлардан сакланып калуыбыз өчен, аларны танып белерлек кайбер сыйфатларын күрсәткән. Әгәр без Расүлүллаһның хәдисләренә күз салсак, без аларны түбәндәге билгеләр буенча таный алабыз: «Алар Аллаһ Китабына чакырырлар, Аллаһ Китабына юнәлерләр, бик күп итеп укырлар, күп гыйбадәт кылырлар»[1]. Расүлүллаһ үзенең сәхабәләренә хариҗиләр турында: «Хариҗиләрнең Коръән укуы белән чагыштырганда, сезнең Коръән укуыгыз берни дә түгел. Намазларыгызның саны аларның намаз саны белән чагыштырганда күпкә ким», – дип әйткән[2].

[1] Имамнар Әхмәд һәм Әбү Давыт хәдис җыентыкларыннан

[2] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

Башка хәдистә болай диелә: «Хариҗиләрнең дога-намазлары янында сез үзегезнең дога-намазларыгызны бик кечкенә, әһәмиятсез итеп кенә күрерсез. Һәм сез аларның уразалары янында үзегезнекен күрмәссез дә». Ягъни, читтән караганда, алар бик тәкъва, Аллаһтан куркучылар, бер дә читкә тайпылмыйча, фәкать Коръән буенча гына яшиләр. Алар бик күп гыйбадәт кылалар, Корьәнне күп укыйлар. Алар авызында – һәрвакыт Расүлүллаһның хәдисләре һәм Коръән аятьләре. Алар Коръәнгә чакыралар, тәкъвалыкка өндиләр: «Сөбханаллаһ! Мин сезгә Расүлүллаһның сүзләрен, Коръән аятьләрен китерәм, ә сез монда бу әйтте, теге әйтте, Әбү Хәнифә әйтте, фәлән әйтте, дип утырасыз! Мин куркамын: сезнең башларыгызга таш явар – ничек итеп сез Аллаһ һәм Расүлүллаһ сүзләрен инкяр итәсез дә, Әбү Хәнифә артыннан барасыз?!» – дип галимнәрнең сүзләрен кире кага.

Әмма Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Алар Коръән укырлар һәм Аллаһның Китабына юнәлдерерләр. Расүлүллаһ сүзләре белән Коръән аятьләрен китереп, алар үзләрен хаклыйлар, дөрес эшлибез диләр, моның зур дәлил булуына ышаналар. Ләкин бу хәдисләр дә, бу аятьләр аларның үзләренә каршы дәлил булып торачаклар», – дип безне кисәтеп куйды. Шуңа күрә тышкы яктан гыйбадәтендә тәкъва булган һәрбер кеше турында, күп итеп Коръән укучы, аять-хәдисләр китерүче турында: «Бу дөрес юлдан баручы», – дип уйлау ялгыш булырга мөмкин. Менә шундый итеп, тыштан тәкъва, искиткеч белемле, әдәпле, ә чынлыкта исә мөселманнар арасында ризасызлык, аерымлык, аннан фетнә чыгаручы мәкерле кешеләр итеп сыйфатлый хариҗиләрне Расүлүллаһ.

Имам Бохари китергән хәдистә: «Аларның күпчелеге яшь булыр, күкрәкләрендә ут янып торыр, дингә омтылып-ашкынып торырлар, дин турында кайгыртучан булырлар, ләкин Аллаһы Тәгалә аларны ялгышуларында калдырган», – диелә, ягъни аларның уй-фикер йөртүләре дөрес түгел, гомерләре яшь булса да, уйлары түбән торыр.

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) хариҗиләрнең тагын бер сыйфатларын китерә: «Алар мөселманнарның канын түгәрләр, мөселманнарга каршы сугыш ачарлар, ә дин дошманнарын ташлап торырлар», – диелә хәдистә. Димәк, мөселманнар белән талашып ятырлар, ә дин дошманнары алардан бернинди дә зыян күрмәячәкләр. Аларның кулларыннан, сүзләреннән фәкать мөселманнар гына зур җәбер-золым күрер. Кызганыч, бүгенге көндә бу сыйфатларны без яшьләрнең кайбер төркемнәрендә күрәбез. Әгәр Пәйгамбәребез хәдисләрен җентекләп карасак, хариҗиләрнең төп билгеләре – үзләре белән ризалашмаган мөселманнарны урынсыз, сәбәпсез көферлектә гаепләү, гомумән, үзләреннән кала, барысын да ялгышларда гаепләү.

Безнең әһлес-сөннәт вә җәмәгать галимнәре, әгәр кеше шәригатьтән кала башка законнарны куллана икән, аларны өстен куймый, шәригать белән янәшә дә куймый икән, ул гөнаһлы булырга мөмкин, ләкин диннән чыкмый, кәфер булмый, дип саныйлар. Әмма кайбер яшьләр, шушы адашкан агымнарга ияреп, безнең хакимиятебезне һәм халкыбызны көферлектә гаеплиләр. Янә хакимияткә буйсынырга өндәгән имамнарны да көферлектә гаеплиләр. Шуңа күрә без белергә тиешбез: илебездә тәкфир проблемасы шул агымнардан килә, без бу белемнәрдән килгән куркынычны танып белергә тиеш.

Хариҗиләрнең янә бер сыйфаты булып үзләре белән килешмәгән мөселманнарның канын түгүне хәләл итеп билгеләү тора. Мондый хәлне хариҗиләр Аллаһка ныграк якынаю ысулы дип кабул иткәннәр. Ягъни аларның төп шөгыле булып кешене шунда ук хаксызга гаепләү тора. Расүлүллаһ әйтүе буенча: «Алар мөселманнарның канын түгәрләр, һәм бу аларның төп сыйфаты булып тора».

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә безне, илебезне тәкфирчылык афәтеннән сакласын, безгә файдалы гыйлемнәр бирсен.

ТҖ МДН Дәгъват бүлеге

5 нче октябрь вәгазе,

Мөхәррам аеның 25 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел

«Сез иң галим кеше икәнсез»

Барлык галәмнәрне, җәннәт белән җәһәннәмне вә алар өчен үз әһелләрен барлыкка китергән Аллаһ Сөбхәнә вә Тәгаләгә хәмед-сәнәләребез булса иде. Барча галәмнәргә рәхмәт өчен, күркәм әхлак үрнәге буларак, мөәминнәрне җәннәт белән сөендергән, имансызларны җәһәннәм белән кисәткән пәйгамбәребез Мөхәммәдкә дә салават шәрифләребез булса иде.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

وَأَنزَلَ اللَّهُ عَلَيْكَ الْكِتَابَ وَالْحِكْمَةَ وَعَلَّمَكَ مَا لَمْ تَكُن تَعْلَمُ

«Аллаһ сиңа Коръән һәм хикмәт иңдерде вә белмәгәнеңне белдерде».

«Нисә / Хатыннар», 4:113

Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләмгә башка беркемгә дә бирелмәгән гыйлемнәрне бирде. Ул аны күк вә җирнең серләренә төшендерде, аңа җәннәт белән җәһәннәмне күрсәтте, тарихи вакыйгалар һәм киләчәк турында да хәбәр бирде, иҗтимагый фәннәрне өйрәтте. Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребезне шәригать хөкемнәренә өйрәтте. Шушы шәригать Кыямәт көненә кадәр һәрбер кеше өчен җитәрлек гыйлем булып тора. Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребезгә Үзе турында өйрәтте һәм Коръәннең бик күп серләрен ачып бирде. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Сезнең арагыздан иң тәкъва һәм Аллаһы Тәгаләне иң яхшы белгән кеше – ул мин», – дип әйткән[1].

[1] Имамнар Бохари һәм Мөслим хәдис җыентыкларыннан

Шулай итеп, Пәйгамбәребез гыйлемле кеше булган. Әмма ул алган гыйлемен калганнарга да аңлатты. Шуңа да ул галәйһис-сәләм: «Галим бул (гыйлемгә өйрәтүче), йә гыйлемне өйрәнүче бул, йә гыйлемне тыңлаучы, йә гыйлемне яратучы бул, әмма бишенчесе булма, һәлак булырсың», – дип әйткән.

Пәйгамбәребез башта ук гыйлемне яратыгыз дип әйтә ала иде. Әмма ул беренче урынга иң бөек дәрәҗәне – гыйлем иясе булуны куя. Бөтен кеше дә галим була аламы? Аладыр, әмма моның өчен күп укудан тыш, яхшы зиһен иясе дә, тырышу һәм Аллаһтан шуны сорау да кирәк. Икенче урында шул гыйлемнәрне алучы кеше, ягъни укучы тора. Әмма Пәйгамбәребез: «Ислам дине галиме булыгыз», – димәде. Һәм, әлбәттә, Исламда шушы фәннәрне генә укыгыз да дигән сүзе булмады. Ни өчен? Әбү Дәрда разыйаллаһу ганһү: «Пәйгамбәребез безгә барлык фәннәр турында да сөйләде һәм кошларның һавада ничек очуларына кадәр аңлатып бирде», – дип әйткән. Һавада кошның ни рәвешле очуы белән, намазны ни рәвешле уку арасында аерма күп тә соң. Берсе дини, берсе дөньяви гыйлем булып санала. Әмма бу әйбергә Пәйгамбәребез дә басым ясаган.

Кадерле җәмәгать! Без проблемалар, ниндидер вакыйгалар, бәйрәмнәр, төрле мәшәкатьләр шуның кадәр күп булган заманда яшибез. Дөнья артыннан куып җитә алмасак та, ашыга-ашыга ни кылганыбызны уйлап та бетермичә, ә кайчакларда, гомумән, уйлап тормыйча да яши бирәбез. Әмма бу тормыш читтән нинди генә сәер һәм хаос эчендә булган кебек тоелса да, ул барыбер ниндидер системаларга, законнарга корылган. Нәкъ шулай ук бу галәм дә закон-кануннарга корылган. Кояш бер яктан чыгып, икенче якка бата, океандагы сулар пар булып күккә күтәрелә, алардан болытлар хасил булып, җил белән төрле җирләргә таралалар. Һәм су күләме болытта «эленеп» тора алмый торган дәрәҗәгә җиткәч, алар яңгыр булып җиргә ява.

Җир шары. Галәм белән чагыштырганда бер нокта гына булса да, үз масштабларында ул гаять зур планета. Анда нинди генә процесслар бармый, нинди генә кагыйдәләр үтәлми. Таулар, вулканнар, завод-фабрикалар, сәүдә эшләре, больницалар, ашханәләр, хайваннар-кошлар дөньясы, планетаның яртысын биләп торган океаннар, утраулар һәм башка берберсеннән аерылып тора торган «дөньялар» бар монда.

Һәр җирдә үз тәртип бар, дип кабат кабатлыйсы килә. Һәм аларны өйрәнеп бетерү дә мөмкин түгел. Әмма аларның һәркайсында да Аллаһы Тәгаләнең хикмәтен күреп була. Моның өчен күп итеп гыйлем алырга һәм бу дөньяга шул гыйлем күзлеге аша карарга өйрәнергә кирәк. Аллаһы Тәгалә кояшны уртада кылып, Җир аның тирәли әйләнсә дә, безнең өчен киресенчә тоела. Чыкканда ул кызыл, уртада ул үз төсендә, батканда шулай ук кызыл була. Һәм бу процессны гади кеше аңлатып та бирә алмый. Монда инде төсләрнең дулкынсыман булулары, кызыл төс дулкынының амплитудасы үзенчәлекләре һәм башкаларны белергә кирәк. Ә бу өлкә белән безнең физика фәне шөгыльләнә.

Кеше – дөньяда иң катлаулы зат. Аның баш мие генә дә дистәләгән еллар вакытында тикшерелсә дә, ахырына кадәр өйрәнелеп бетә алмый. Монда биологлар да, химиклар да баш вата. Һәм алар өйрәнгән саен, моның кадәр катлаулы зат (кеше булмасын, хайваннар, кошлар) табигать тарафыннан гына ясалмаганлыгын аңлыйлар.

Кадерле җәмәгать, икътисадта, сәясәт өлкәсендә диндә алган фикһ гыйлемнәрен куллану, үзенең дөньяга карашларын гакыйдә фәне аша дәресләү, үзенең кешеләр белән (менеджмент) аралашуны корганда мәдрәсәдә әдәп-әхлак дәресләрендә алган гыйлемнәрне эшкә җигү – болар барысы да бер гыйлемнең икенчесеннән аерым түгеллеген күрсәтеп тора.

Шулай итеп, гыйлемнең нинди генә өлкәгә карамаса да аның файдалы булуы турында аңлаштык кебек. Кабаттан Пәйгамбәребезнең

хәдисенә әйләнеп кайтыйк: гыйлемне өйрәтүче галим бул. Ә укытучы булу җиңелме? Алган гыйлемнәрне бүтән кеше аңларлык итеп аңлата белү һәр кешегә дә бирелгәнме соң? Бүген илебез укытучылар көнен билгеләп үтә. Бу мәктәп, урта һөнәри техникумнар, университет, мәчет-мәдрәсәдәге укытучыларның барысына да кагыла торган бәйрәм. Әйе, без барыбыз да укытучылар: әти-әни, олы апалар сеңелләрен укыта, үзебез дә берәр хәдис ишетүгә аны икенче кешегә җиткерәбез. Әмма дәүләт бу көнне профессиональ рәвештә бу һөнәрне үзләштереп, үзләренең гомерләрен шушы гамәлгә багышлаган кешеләр өчен бәйрәм итеп билгеләгән. Аның нинди датага туры килүе дә артык мөһим түгел, бу әниләр көнен бер көнгә билгеләп куйган кебек: без бит әниләребезне һәркөнне кадерләргә тиеш. Шуның кебек, остазларыбыз да безнең өчен көн саен тырышып көч куя, без дә аларны көн саен хөрмәт итәргә тиешбез.

Бүгенге көндә мәктәптә укыган балаларыбызга: «Укытучыңны тыңла, аны ихтирам ит», – дип көн саен әйтсәк тә аз. Без өйдә ике-өч баланы көч-хәл белән генә тыңлата алабыз. Ә мәктәп укытучысы таныш булмаган 10 нан алып 20, 30 баланы бер сыйныфта үзенә каратып утырта ала. Аларга үзендә булган гыйлемне бирә, әдәп-әхлак серләренә төшендерә.

Кадерле мөселман кардәшләр, без үзебезнең балабызны мәдрәсәгә биргәндә, анда укыячак бөтен бала да дини гаиләдә тәрбияләнгән икәнен аңлап киләбез. Ә мәктәптә төрле бала була. Алар төрлечә тәрбияләнгән, шуңа күрә класста үз-үзләрен тотышлары да аерылып торачак. Моннан чыгып, мәктәп укытучысына дәрестә белем бирүдән тыш, тагын бик күп төрле проблемаларны чишәргә туры килә.

Әгәр безнең балаларыбыз үзләренең укытучыларын хөрмәтләргә өйрәнсәләр (мәктәп, мәдрәсә һ.б. уку йортындагы), аларның белем алу процессы да җиңеләер иде һәм Аллаһы Тәгалә ул гыйлемнең бәрәкәтен дә бирер иде. Укучы үзенең укытучысын авыру кеше табибны тыңлаган кебек тыңларга тиеш. Пәйгамбәребез Мөхәммәд: «Олы кешеләрне

хөрмәтләмәгән, кече яшьтәгеләргә мәрхәмәтле булмаган һәм гыйлем ияләренә аларның хакларын бирмәгән кеше безнең өммәттән түгел», – дип әйткән.

Имам Гали разыйаллаһу ганһү укучыларга укытучыларга карата нинди булырга кирәклеген түбәндәге киңәш рәвешендә әйтә: Сиңа иң башта бөтен кешеләрне сәламләп, аннан соң укытучының үзенә аерым сәлам әйтү кирәк. Син аның серләрен сөйләмәскә, дәрестә кулларыңны селкеп утырмаска, аңа күз кысмаска, аңа күп сораулар бирмәскә, ул җавап кайтарганда аның сөйләменә кушылмаска тиеш, ... әгәр аңа берәр нәрсә кирәк булса, калганнар аны эшләгәнче, аны үзеңә эшләргә ашыгырга кирәк».

Шулай ук укучы үзенең укытучысы өчен хәерле догалар кылырга, аның хәлен белеп торырга онытмаска тиеш. Мәктәптә 11 ел, югары уку йортларында, мәдрәсәләрдә 4 ел буе укытучылар безгә әти-әниләребезне алыштыралар. Алар бирә алмаган, яисә биреп бетермәгән белемне, тәрбияне бирәләр, җәмгыятьтә үзебезнең урыныбызны табарга булышалар. Имам Шәфигый рахмәтуллаһи галәйһи: «Мин имам Мәлик каршында китап укыганда, аның битләрен имамга ишетелмәслек итеп тавышсыз ача идем», – дип әйткән. Укытучыга карата хөрмәт күрсәтү безнең әдәп-әхлагыбызны күрсәтә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәләм: «Беркем дә әдәп-әхлаксыз югары дәрәҗәгә күтәрелә алмады, ә әдәп-әхлакны калдырган кешеләр аска таба тәгәрәделәр», – дип әйткән. Безнең җирлегебездә Әбү Хәнифә нигез салган мәзһәб кулланыла. Әбү Хәнифә дигәч, зур галим күз алдына баса. Әмма Әбү Хәнифә гыйлем алган остазларын онытмаган. Ул берсендә: «Мин аягымны бу якка сузып йоклый алмыйм. Ул якта минем укытучым Хәммад яши», – дип әйткән.

Бервакыт Габдуллаһ бине Әл-Мөбарәктән: «Әгәр Аллаһы Тәгалә сиңа вәхи иңдереп бүген үләчәгеңне хәбәр итсә, ни эшләр идең?» – дип сорыйлар . Ул: «Мин гыйлем алу белән шөгыльләнер идем, чөнки Аллаһы Тәгалә

Пәйгамбәребезгә дөнья нигъмәтләрен бирде, әмма аны арттырырга кушмады. Шулай ук Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребезгә гыйлем бирде һәм аны арттырып торырга кушты. Аллаһы Тәгалә аны Коръәндә боерды:

وَقُل رَّبِّ زِدْنِي عِلْمًا ﴿١١٤﴾

«Дәхи, Раббым белемемне арттыр, диген!»

«Та Һа», 20:114

– дип җавап кайтарды.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд: «Аллаһы Тәгалә гыйлемне киметми, Ул башка нәрсәләрне киметә. Әмма Ул гыйлемне галимнәрне бетереп юкка чыгара», – дип әйткән.

Шулай ук ул: «Гыйлем бирүчене кимсеткән кешене Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә түбәнсетер», – дип әйтте.

Габдуллаһ бине Гомәр болай дип әйткән: «Бөтен кешеләр дә авыру. Әмма галимнәр – дәвалаучылар. Савыгырга теләгән кеше аларга якын булсын. Аларга карау – гыйбадәт, алар белән бергә йөрү – дәрәҗә, алар белән бер өстәл артына утырып ашау – дәвалану, чөнки алар белән бергә булган кешеләр беркайчан да кайгы-хәсрәткә бирелмәсләр. Аларны яклаган кеше үзе яклау астында булыр. Аларга каршы чыккан кеше үзе бәхетсез булыр».

Кадерле җәмәгать! Аллаһы Тәгалә кешеләрне тән ягыннан, дәрәҗә ягыннан, акыл яыннан, байлык ягыннан төрле итеп яраткан. Кемгәдер гыйлемне күбрәк, кемгәдер азрак биргән. Балаларга гыйлем алуны җиңел кылган, чөнки аларның башларында кирәкмәгән мәгълүмат әлегә юк. Ә кем үзен аз беләм дип саный, алар һәрвакыт белгән кешеләрдән сорый алалар:

فَاسْأَلُوا أَهْلَ الذِّكْرِ إِن كُنتُمْ لَا تَعْلَمُونَ ﴿٤٣﴾

«Белмәгән һәрнәрсәгезне белгән кешеләрдән сорагыз!»

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:43

Ә шул белгән кешеләр турында Аллаһы Тәгалә икенче аятьтә әйтә:

قُلْ هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ

«Әйт: «Белүчеләр белән белмәүчеләр бер дәрәҗәдә булырлармы?»

«Зүмәра / Халык Төркеме», 39:9

Ягъни гыйлем ияләре белән гыйлемсезләр Аллаһ каршында төрле дәрәҗәдәге кешеләр. Шулай булгач, укучы үзенең остазы белән ихтирам күрсәтеп аралашырга тиеш.

Кадерле җәмәгать, бүген без гыйлем, аның дөньяви һәм дини булуына карамастан, бер үк әйбер – Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен ысул икәнен, укытучылар, аларның авыр вазифалары турында, үзеңнең остазыңа карата ихтирамлы булырга кирәклеге турында бик кыска гына сөйләшеп алдык. Аллаһы Тәгалә безне галим, я аны өйрәнүче, я аны тыңлаучы, я гыйлемне һәм гыйлем өйрәтүчеләрне, галимнәрне яратучылардан кылса иде. Барча укытучыларны аларның бәйрәмнәре белән котларга рөхсәт итегез. Без һәрвакыт аларга догада булыйк, исәннәренең кадерен белеп, аларның хәл-әхвәлләрен белешеп торыйк. Аллаһы Тәгалә барчаларыбызга да хәерле гомер, сәламәтлек насыйп әйләсен. Вәссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

«Хозур редакциясе»

Сорау – җавап

Әҗәтле үлмәсме?

Безнең бер танышыбыз берничә ел элек бездән шактый зур суммада акча алып торды. Кайтарыр дип ышанып бирдек, ләкин килешенгән вакыт чыккач, ул башта «иртәгә»ләр, «киләсе атна»лар белән тынычландырып йөрсә, соңрак бөтенләй күзгә күренмәүне, качып йөрүне өстен күрде. Кыскасы, әҗәтне кайтарырга теләми. Динебездә бу мәсьәлә ничегрәк каралган икән?

Шәригать буенча кыен матди хәлгә тарыган кешегә әҗәткә акча биреп аның хәлен җиңеләйтү, булдыра алганча ярдәм итү саваплы гамәлләрдән санала. Әмма акча сорап мөрәҗәгать иткән кешенең мохтаҗлык дәрәҗәсен белү, шул акчаны ул нинди максатларга тотарга ниятләгәнен ачыклау да шарт булып тора. Әгәр кеше чыннан да ярдәмгә мохтаҗ икән, аңа әҗәткә бирү – сөннәт, ягъни саваплы гамәлдер. Әгәр өсте өстенә әйбер алырга, ниндидер мөһим булмаган максатларга дип сорый икән, андый кешегә акча бирү мәкрүһ (шелтәле гамәл), ә инде аракыга, отышлы уенга һ. б. шундый максатларга акча биреп тору – хәрам, ягъни тыелган гамәл булып санала.

Мөселман кешесенә әҗәткә алу рөхсәт ителсә дә, ул бу адымга бик мәҗбүр ителгән хәлдә генә барырга тиеш. Хәдисләрнең берсендә: «Бурычтан сакланыгыз! Дөрестән дә, бурыч ул – төннәрен кайгыру, көндезен исә кимсенү сәбәбедер». Нәрсә дә булса әҗәткә алганда, шул әҗәтне вакытында кайтаруны ныклап ниятләргә кирәк. Бу бик мөһим, чөнки әҗәтен кайтарырга ниятләгән кешегә Аллаһы Тәгалә Үзе ярдәм итә. Мөбарәк хәдисләрдән билгеле булганча, кире кайтару нияте белән алучыга Аллаһ ярдәм итә, ә кем кайтармау нияте белән алса, карак хөкемендә булыр һәм аны Аллаһы Тәгалә һәлак итәчәк... Әҗәтле булуын онытмыйча, моңа җаваплы карап борчылган кешегә Аллаһы Тәгалә хәтта махсус сак куя:

саклаучы фәрештәләр бу кешене бәла-казалардан саклый, имин булуын кайгырта... Шуңа күрә халыкта «әҗәтле үлмәс» дигән әйтем дә йөридер.

Бурычка алу белән бәйле тагын берничә мәсьәләгә игътибар итәргә кирәктер. Әгәр кеше бурычка кергән икән, аның башкаларга садака бирергә, мал белән бәйле изгелек кылырга, мәсәлән, хаҗга барырга хакы юк. Әҗәтле кеше әҗәтен кайтаруны үзенең иң беренчел максаты итеп куярга тиеш. Галимнәр билгеләп үткәнчә, хәтта ашауда да бу кешегә артыклык күрсәтмәскә, әйтик, җиләк-җимешләрдән, башка кыйммәтле ризыклардан баш тартырга кирәк.

Дөрестән дә, бүген шактый кешене «кайда гына әҗәткә алыйм икән» дигән мәсьәлә борчый, ләкин «алынган акчаны ничек кайтарырмын?» дигән уй аларның башына килми һәм бу кешеләр «әйдә, ярар»га өметләнеп, йә таныш-белешләреннән, йә банктан зур суммада акча алып торуны әллә ни зур проблема итеп күрми. Шунысы да бар: кайберәүләр әҗәтләрен чыннан да кайтара алмаганга кайтармый, әмма башка берәүләр мөмкинлекләре була торып та, кеше акчасын кайтаруны мөһим эшкә санамый. Шундыйлар, әҗәтләре булуга карамастан, яңадан-яңа кием ала, машиналарын яңарта, фатирларында ремонт ясый, ягъни үзенә кирәклегә акча таба, ә әҗәтне кайтарырга – юк. Исләренә төшерә башласаң, шундыйлар әрсезләнеп, аралашудан баш тарта, шалтыратсаң телефонны сүндерә, килсәң – ишекне ачмый. Бу, әлбәттә, бернинди әдәп кысаларына сыймый. Мөселман галимнәре белдергәнчә, ислам дине буенча мондый кешеләр катгый шелтәләүгә лаек. Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) хәдисләренең берсендә бу хакта болай диелә: «Әгәр әҗәтен кайтарырга мөмкинлеге була торып та, әҗәтле кеше моны эшләмәсә, ул башкаларны кыерсытучы залим кебек булыр һәм аңа бу гөнаһка тиң җәза бирелер». Башкаларны шулай борчып, әҗәтен кайтармыйча йөргән кешегә Аллаһ ачу күзе белән карар һәм ул тормышындагы бәрәкәтен югалтыр. Мәгълүм мәкальдә «әҗәтле үлмәс» дип әйтелсә дә,

чынлыкта беркем дә бу дөньяда мәңгегә калмый. Ә инде кеше бурычлы килеш бакыйлыкка күчә икән, ахирәттә, Кыямәт көнендә, Аллаһы Тәгалә аңа әйтер: «Кемнеңдер хакларын Мин шулай синең өстә калдырырмым дип уйладыңмы әллә?!» Шуннан соң бурычын кайтармаган кешенең барлык яхшы гамәлләрен теге акча биреп торган кешегә тапшырыр. Әгәр бурычлы килеш вафат булган кешенең яхшы гамәлләре булмаса, акча биреп торган кешенең гөнаһлары аңа язылып куелыр, ди...

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) мөселманнарны эшләргә, кәсеп итәргә чакырып, матди авырлыкларны әҗәткә кермичә хәл итәргә тырышыгыз, дип өйрәтеп калдырды. Инде башка чара юк икән, әҗәткә алу мөмкин, әмма зур сумма турында сүз барганда, килешү төзеп, расписка язып әҗәткә бирергә яки бурычка акча сораучының ниндидер әйберсен яки документын залогка калдыруын сорарга кирәк. Мөселманнар нәтиҗәле кәсеп, бәрәкәтле тормыш теләп, Аллаһы Тәгаләдән: «Йә Раббым! Мине имансызлыктан һәм әҗәттән сакла...» – дип һәрдаим дога кылырга һәм ихлас иман белән чиста намуска таянып гамәл кылырга тиеш. Бу – безнең дөньядагы һәм ахирәттәге бәхетебезнең нигезе.

Җавапны Кукмара мәдрәсәсе мөдире

Ришат хәзрәт Курамшин әзерләде

Гайбәт кайсы очракларда рөхсәт ителә?

Сүз йөртү, гайбәт сөйләү, яла ягу, башкалар хакында начар сүзләр әйтү Ислам динендә олуг гөнаһ булып санала. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) сәхабәләреннән: «Сез гайбәтнең нәрсә икәнен беләсезме?» – дип сорый. Алар: «Аллаһ һәм Аның илчесе бу хакта яхшырак белүчеләр», – дип җавап бирәләр. Һәм Пәйгамбәр: «Әгәр бер кеше турында аның күңеленә хуш килми торган сүзләрне ул югында сөйлибез икән, ул гайбәт була», – дип аңлата. Сәхабәләр: «Йә Расүлүллаһ! Ә әгәр ул кимчелек кешедә чыннан да булса?» – дип әйтәләр. Аллаһның илчесе: «Әгәр ул кимчелек бу кешедә чыннан да булса, син ул югында аның артында гайбәт сөйләгән буласың, әгәр ул кимчелек бу кешедә булмаса, аңа яла яккан буласың», – дип әйтә.

Башка бер хәдистә: «Әгәр бер мөселман икенче мөселман хакында гайбәт сөйләгән вакытта, тыңлап торучы гайбәт сөйләнгән дин кардәшен якларга мөмкинлеге булып та, аны якламаса, Аллаһы Тәгалә аны бу дөньяда да, ахирәттә дә түбәнсетер», – дип әйтелә.

Шулай да алда санап кителәчәк 5 очракта шәригать гайбәт сөйләүне рөхсәт итә:

1. Кешегә золым кылынган вакытта: бер мөселман бер кешегә золым кылса, кыерсытса, түбәнсетсә, моны барып берәрсенә хәбәр итү дөрес, чөнки тиешле статусы булган кеше бу очракта золым кылынган кешегә ярдәм күрсәтә ала.

2. Гаделлек урнаштыру өчен. Дәрәҗәсе һәм көче булган кешегә, ул хәлне үзгәртә алсын өчен, ярдәм сорап мөрәҗәгать итү очрагында гайбәт сөйләү рөхсәт ителә. Мәсәлән: «Фәлән кеше фәлән явызлык кылды, чарасын күрегез», – дип әйтү. Бу вакытта сез гаделсезлеккә каршы көрәшкән буласыз.

3. Фәтва сораганда. Мәсәлән, мөфтигә сорау биргәндә: «Минем әти фәлән эш эшләде, ирем фәлән гамәл кылды, мин бу очракта нәрсә эшләргә тиеш?» – дип сөйләү рөхсәт ителә, чөнки моның мәсьәләне хәл итәргә ярдәм итүе мөмкин. Дин хезмәткәренә киңәш сорап мөрәҗәгать итү дөрес.

4. Кешеләрне кисәтү һәм аларны афәттән саклау өчен. Бер кеше башка бер кешеләргә зыян китерергә теләгәндә, ул кешене туктатып булмаган очракта, һәм бу зур афәткә китерәчәге билгеле булганда, мөселман кешесенә шул кешенең золымы хакында хәбәр итү фарыз була.

5. Ачыктан-ачык ярамаган эш эшләүчене туктату өчен. Мәсәлән, берәр каракның әйбер урлавы хакында җәмгыятькә хәбәр итәргә кирәк. Кеше үзе үзгәртә ала торган кимчелекләр хакында кешенең шәхсән үзенә хәбәр ителә.

Үрнәк затлар

Икенче тугры хәлифә – Гомәр разыйаллаһу ганһү

Тулы исеме: Гомәр бине Хаттаб бине Нуфәйл бине Габделгөззә бине Риях бине Габлуллаһ бине Кәгъб.

Әтисе: Хаттаб бине Нуфәйл.

Әнисе: Хәнтама бинт Һишам (Әбү Җаһилнең әтисе белән бертуган кыз кардәше).

Кушаматлары:

1) «Әбү Хафс» – Хафсаның әтисе.

2) «Фәрукъ» – аеручы; Мөхәммәд галәйһис-сәләм аңа бу исемне ислам динен кабул иткәннән соң биргән. Ул: «Син хаклыкны батылдан аера алдың», – дип әйткән булган.

Яшәгән еллары: Гомәр разыйаллаһу ганһү Пәйгамбәребез Мөхәммәдтән (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) 13 яшькә кечерәк булып, якынча 584 елда туган. 644 елда вафат була.

Хәлифәлек еллары: 634-644 (10 ел дәвамында хәлифә булып торган).

Балалары: уллары – Зәйд (олысы), Зәйд (кечесе), Гасыйм, Габдуллаһ, Габдеррахман (олысы), Габдеррахман (уртанчысы), Габдеррахман (кечесе), Гобәйдуллаһ, Гияд; кызлары – Хафса, Рокыя, Зәйнәб, Фатыйма.

Ислам динен кабул итүе

Билгеле булганча, Гомәр разыйаллаһу ганһү ислам динен беренче кабул итүчеләрдән булмый. Җаһилият вакытында ул ислам диненең дошманы була. Ислам динен кабул итүчеләрне газаплап, мөселманнарга аңардан бик күп зарар ирешә.

Шулай бервакыт, ул ислам динен кабул иткән колларыннан булган бер хатынны баганага бәйләп куеп, бик озак кына камчы белән суктыра.

Җитмәсә өстәп: «Әгәр арымаган булсам, мин бу эшемне туктатмаган булыр идем», – дип әйткән.

Мөселманнар аның кайчан да булса бер ислам динен кабул итәчәгенә ышанмыйлар, хәтта үзара: «Гомәр ислам динен кабул иткәнче, аның ишәге беренчерәк ислам динен кабул итәчәк», – дип сүз йөртәләр.

Бары тик Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) кенә аннан өметен өзми, бәлки шундый гайрәтле затның Исламга килеп, мөселманнар файдасына хезмәт итүен өмет итеп: «Йә Раббым! Исламны Гомәр белән өстен һәм куәтле ит», – дип аны күргән саен Аллаһы Тәгаләгә дога белән мөрәҗәгать итә торган булган.

Бервакыт ул хәтта Пәйгамбәребез Мөхәммәдне гарәпләрне ата-бабалар диненнән читләштереп, ислам диненә чакырганы өчен үтерергә тели. Мөселманнарга ачуланып барганда, каршысына Нөгәйм бине Габдуллаһ очрый. Гомәр аны кыйнарга дип кулын күтәрә, Нөгәйм аңа: «Гомәр, сиңа бозыклык таратып йөрү җитте инде, тынычлан. Апаң Фатыйма кебек ислам динен кабул ит, үзеңне җәһәннәм утыннан коткар», – ди. Гомәргә бу сүзләрне ишетү бик авыр була, чөнки аңа үрнәк итеп хатын-кызны куялар.

Гомәр апасы Фатыйма йортына китә. Бу вакытта Фатыйма ире Сәгыйть белән Хәббәб бине Мунзирдән Коръән аятьләре өйрәнеп утыра торган булалар. Ачулы Гомәрнең килеп ишек кагуыннан алар куркуга калалар. Хәббәб тизрәк кереп кача. Ишекне ачмауларын күргәч, Гомәр өйгә бәреп үк керә. Кергән чакта: «Мин сезнең ислам динен кабул иткәнегезне ишеттем», – дип Сәгыйтьне сугып ега. Ирен якларга теләгән апасына да өлеш чыга.

Канга буялып, җирдә яткан Фатыйманы һәм Сәгыйтьне күреп, ул уйга кала: «Бу кешеләрне күрче, диннәре өчен ничек нык торалар. Безнең арабызда потлар өчен бер тамчы кан түккән кеше дә юк». Ул кылган гамәлләре өчен бик нык үкенә һәм апасыннан: «Сез нәрсә укыдыгыз? Бир

әле, мин дә укып карыйм», – дип сорый. Фатыйма аңа: «Юк, бу – Коръән. Аңа чиста килеш кенә тотыналар», – ди һәм аңа тәһарәт яки госел алырга киңәш итә.

Гомәр госел алып керә. Апасы кулындагы төргәкне бирә һәм ул андагы «Та Һа» сүрәсен укый. Шулчак ул: «Бу нинди гаҗәеп, матур сүзләр. Кешеләр бу сүзләрне әйткән кешедән кала беркемгә дә гыйбадәт кылырга тиеш түгелләр! Мине Мөхәммәд янына алып барыгыз!» – ди.

Бу сүзләрне ишетеп торган Хәббәб качкан урыныннан чыгып, «Аллаһы Тәгалә Расүлүллаһның догасын кабул итсен. Гомәр, ислам динен кабул ит! Үзеңне җәһәннәм утыннан коткар!» – ди.

Гомәр Мөхәммәд галәйһис-сәләмнең кайда торганын сорашып, шул тарафка юнәлә.

Бу вакытта Мөхәммәд (аңа Аллаһының сәламе һәм рәхмәте булсын) өендә сәхабәләренә дәрес бирә торган була. Гомәрнең килеп ишек шакуы аларны шулай ук куркуга сала. Хәмзә: «Керсен. Күңелендә яхшылык булса – сөйләшербез. Күңелендә яманлык булса – үзенә үпкәләсен», – ди. Гомәр өйгә керә һәм Мөхәммәд галәйһис-сәләмнең каршысына килеп, шәһадәт кәлимәсен әйтә. Сәхабәләр сөенеп, шатланып тәкбирләр әйтәләр. Гомәр хәбәр таратучыны чакырып, бөтен кешегә үзенең ислам динен кабул итүе хакында җиткерергә куша.

Гомәрнең ислам динен кабул итүе кечкенә бер җиңүгә тиң вакыйга була. Ул көченнән килгәнчә бар тырышлыгын күрсәтә. Гомәр иманга килгәнче, мөселманнар Мәккәнең бер читендә яшеренеп кенә гыйбадәт кыла торган булсалар, хәзер инде алар Ислам динен ачыктан-ачык тота башлыйлар, курыкмыйча Кәгъбәтулла янында намаз укыйлар. Шул рәвешле, Аллаһы Тәгалә ислам динен Гомәр белән куәтли.

Гомәр разыйаллаһу ганһү ислам динен кабул иткәннән соң иң күп гыйбадәт кылучылардан санала. Төннәрен намазда, көннәрен уразада үткәрә, иң күп сәҗдә һәм рөкүгъ кылучылардан була. Ястү намазыннан соң

иртәнге намазга кадәр төнге намазлар укый. Аның янында һәрвакытта да савыт белән салкын су тора. Йоклыйсы килгән чакларында, ул шул салкын су белән юына торган була. Коръән укып, ул кешелекнең асылына төшенә. Беренче тапкыр ул үз гамәлләре һәм сүзләре өчен Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә каршында җавап бирергә кирәк булачагын аңлый. Көннән-көн ул үзе өчен Коръәннән яңа хәзинәләр таба. Ул чын мәгънәсендә Аллаһы Тәгаләне һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәдне (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) ярата.

Гомәр разыйаллаһу ганһүнең дөнья малыннан баш тартуы

Гомәр разыйаллаһу ганһү ислам динен кабул иткәннән соң үзен төрлечә дөньялыктан чикләргә тырыша. Аның заһидлеге ашаган ризыгында, кигән киемнәрендә дә чагылыш таба. Хәлифә булса да, ул дәрвишләрчә гомер сөрә: кайвакыт хәтта өстендәге киемнәре дә ямаулы була. Дөнья малына кызыкмый, аз нәрсә белән канәгать була, җыелган малларны Ислам файдасына, фәкыйрь һәм мохтаҗларга сарыф итә.

Габдулла бине Мәсгуд: «Дөньяның Гомәрне үзенеке итәр өчен бөтен мөмкинчелекләре бар иде, ләкин Гомәр дөньяны теләмәде. Ахирәтне беренче урынга куйды», – дип әйткән була.

Талхә разыйаллаһу ганһү болай дип әйткән: «Гомәр ислам динен беренчеләрдән булып кабул итүчеләрдән булмады, ләкин ул беренчеләрдән булып (дөнья малыннан) баш тартты».

Гомәр разыйаллаһу ганһүнең тыйнаклыгы

Югары дәрәҗәдә булуына карамастан, Гомәр разыйаллаһу ганһү сәхабәләр арасында үзенең тыйнаклыгы белән аерылып тора.

Ул кораешлеләрнең илче вазифасын үти, ләкин тәкәбберләнеп, масаеп йөрми, киресенчә, үзен һәрвакытта да кулда тота. Гомумән, ул тәкәбберлекне сөйми. Моның ачык мисалын без түбәндәге вакыйгада да күрәбез.

Бервакыт, хәлифә булган хәлендә мәчеткә килеп кергәч, җыелган барча халык аны аягүрә басып каршы алалар, юл бирәләр. Гомәр разыйаллаһу ганһү үзендә тәкәбберлек хисен сизә. Минбәргә баскач, ул үзенең көтү көткән вакытларында булган хәлләрен, көннәр буе ач йөргәнен сөйли. Халык гаҗәпләнеп: «Әй, Гомәр, үзеңне нигә кимсетәсең?» – дип сорыйлар. Гомәр аларга: «Мин сезнең каршыгызга килгәч үземдә тәкәбберлек сиздем һәм мин аңа үз урынын күрсәтергә теләдем», – дип җавап кайтара.

Гомәр разыйаллаһу ганһү хәлифә булгач та үз нәфесе өстендә эшли. Аты булмаган вакытында ул җәяү йөри. Ә инде атка утырырга туры килгәндә, хуҗасын уңайсыз хәлдә калдырмау өчен, аның артына (уңайсыз җиренә) үзе утыра торган булган. Урамда берәр мохтаҗны күрсә дә, аңарга ризыкны үзе пешереп ашаткан.

Гомәр разыйаллаһу ганһүнең Аллаһы Тәгаләдән куркуы

Гомәр разыйаллаһу ганһү сәхабәләр арасында булган дәрәҗәсенә карамастан, иң тәкъвалылардан санала. Ул хәләлне генә кулланып, хәрамнан ерак тора, шикле нәрсәләрдән читләшә. Һәр гамәлен дә Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) түбәндәге хәдисенә нигезләнеп башкара:

«Кем шиккә төшә, хәрамга төшкән кебек булыр. Кем шиктән ерагая, ул үзенең динен һәм намусын саклап калган кебек булыр».

Бервакыт Гомәр разыйаллаһу ганһүгә сөт китереләр. Ул сөтнең тәмлелегенә сокланып: «Бу тәмле сөтне кайдан алдыгыз?» – дип сорый. Ярдәмчеләре аңа бу сөтнең зәкәткә китерелгән дөяләрдән савып алын-

ганлыгын әйтәләр. Гомәр үзенең зәкәт әһеле булмавыннан куркып, сөтне косып чыгарырга ашыга. Шул рәвешле, Гомәр разыйаллаһу ганһү үзен хәрамнан гына түгел, ә шикле нәрсәләрдән дә саклый.

Шулай бервакыт Гомәр разыйаллаһу ганһү сәхабәләре белән кырдан барганда ял итәргә туктыйлар. Шулчак Гомәр җирдән салам кисәген алып: «Мин шушы салам кисәге булсам иде, бернәрсә өчен дә җавап бирмәсәм иде. Сезнең күбегез җәннәткә керер, кайберләрегездән кала. Мин үземнең соңгыларыннан булуымнан куркам. Кайберләрегездән кала, сезнең кайберләрегез утка керер. Мин Аллаһы Тәгаләдән уттан котылучылардан булуымны сорыйм», – дип әйтә.

Гомәр разыйаллаһу ганһүнең батырлыгы

Гомәр разыйаллаһу ганһү сәхабәләр арасында иң батырларыннан санала. Ислам динен кабул иткән беренче көннән алып, соңгы сулышына кадәр ислам динен алга этәрүчеләрдән була. Үзенең гайрәте белән мөселманнарга зур таяныч һәм калкан була, аларны үз яклавы астына алып, мөшрикләрнең зарарыннан саклый. Гомәр разыйаллаһу ганһүнең батырлыгына мисал итеп түбәндәгеләрне әйтергә була:

1) Гомәр разыйаллаһу ганһү ислам динен кабул иткәннән соң, башкалардан аермалы буларак, ул үзенең ислам динен кабул итүен ачык рәвештә игълан итә. Алай гына да түгел, хәбәр таратучыны чакырып, бөтен кешегә бу хакта хәбәр таратырга боера;

2) Мөхәммәд галәйһис-сәләм мөселманнарга Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылырга боергач, күпчелек мөселман яшерен рәвештә качып һиҗрәт кыла. Гомәр разыйаллаһу ганһү исә кулына кылыч, җәя, уклар алып, атын иярләп, атка утырган хәлендә башта Кәгъбәтуллаһ янына бара һәм ашыкмыйча гына, җиренә җиткереп, ике рәкәгать намаз укый; соңыннан, Кәгъбәтуллаһ тирәли тәваф кылгач, шунда җыелган мөшрикләргә борылып: «Мин хәзер һиҗрәт кылам. Әгәр кем үзенең ба-

лаларын ятим, хатынын тол калдырырга, ата-анасын елатырга теләсә, артымнан чыксын һәм шул чокырның артында миңа юлыксын», – дип кычкыра һәм Мәккәдән чыгып китә. Аның артыннан барырга батырчылык кылган кеше табылмый;

3) Гомәр разыйаллаһу ганһү Мөхәммәд галәйһис-сәләм катнашкан барлык сугышларда да катнаша, үзенең батырлыгын, тырышлыгын күрсәтә. Пәйгамбәребез галәйһис-сәләмнең вафатыннан соң да ул күп сугышларда катнаша, байтак җирләрне ислам дәүләтенә куша.

Гомәр разыйаллаһу ганһүнең юмартлыгы

Гомәр разыйаллаһу ганһү Мәккә шәһәрендә зур сәүдәгәрләрдән санала. Шул ук вакытта ул үзенең юмартлыгы белән дә аерылып тора. Ислам диненә килгәннән соң Әбү Бәкер радыйалллаһу ганһү белән бергә алар изгелек эшләүдә бер-берсе белән ярышалар.

9 нчы һиҗри елда, Табук сугышына мал җыйганда, Гомәр разыйаллаһу ганһү, Әбү Бәкерне узарга теләп, ярты малы белән килә. Әбү Бәкер разыйаллаһу ганһүнең исә бөтен байлыгы белән килгәнен күргәч: «Мин сине беркайчан да изгелектә уза алмам», – дип әйтә.

Гомәр разыйаллаһу ганһү киң күңелле булып, авыр хәлләрдә калучыларга ярдәм итәргә тырыша. Мөселманнар Мәдинәгә һиҗрәт кылгач, күп авырлыклар кичерәләр, чөнки аларның бөтен байлыклары, маллары Мәккәдә кала. Гомәр разыйаллаһу ганһү исә үзенең бөтен байлыкларын да алып чыга. Мәдинәгә һиҗрәт кылгач, ул башка мөселманнарга ярдәм итә, аларга яңа җирдә тернәкләнергә булыша.

Гомәр разыйаллаһу ганһүнең дәрәҗәсе

Гомәр разыйаллаһу ганһү сәхабәләр арасында иң югары дәрәҗәдә була. Аның дәрәҗәсен түбәндәге мисаллардан күрәбез:

1) Икенче тугры хәлифә.

2) «Мөәминнәрнең әмире» исеменә лаек булган беренче кеше.

3) Исән чагында җәннәт белән шатландырылган ун сәхабәнең берсе.

4) Мөхәммәд галәйһис-сәләмнең Әбү Бәкердән соң иң яраткан кешесе.

5) Мөхәммәд галәйһис-сәләм күп кенә хәдисләрендә Гомәр разыйаллаһу ганһүнең дәрәҗәсе хакында телгә ала:

«Гомәрнең теле бары тик дөресен сөйли һәм йөрәге хаклык белән тибә».

«Гомәр атлап барган юлдан шайтан атлап бармас».

Мөхәммәд галәйһис-сәләм Әбү Бәкер һәм Гомәр разыйаллаһу ганһүмнәр хакында: алар минем күзләрем һәм колакларым», – дип әйткән. Шулай ук ул: «Минем җирдә һәм күктә икешәр ярдәмчем бар. Күктә – Җәбраил белән Микаил, җирдә – Әбү Бәкер белән Гомәр», – дип әйтә торган булган.

Гомәр разыйаллаһу ганһүнең игътибарлыгы

Гомәр разыйаллаһу ганһү хәлифә булып билгеләнгәннән соң үз өстендә зур җаваплылык тоя. «Мин ничек итеп бар халыкка да гадел булырмын икән, ничек кенә барысы өчен дә җавап биреп бетермен икән?» – дип борчыла. Ислам дошманнарының, монафикъларның эшләрен һәрвакыт тикшереп, күзәтеп тора. Кирәк булганда, һичкемнең хәтерен калдырмыйча, үз фикерен әйтә, тиешле җәзасын бирә, һәр яктан Ислам дине өчен гаять зур эшләр башкара торган була. Үзе сәүдә белән шөгыльләнгәнгә байлыгы да күп була һәм малы белән дә бик күп ярдәм итә. Ул беренчеләрдән булып, кичен гади халык арасына чыгып, аларның хәлләрен белешеп йөри.

Шулай беркөнне урамда йөргәндә ераккта гына янган бер ут шәүләсен күреп ала һәм шул тарафка юнәлә. Ул якынрак килеп сәлам бирә, хәлләрен

белешә. «Нәрсә пешерәсез, балаларың нигә елый?» – дип сорый ул хатыннан. Бу хатынның ире сугышта һәлак булган. Ризык җитмәгәнлектән балалары берничә көн буена инде ашамаганнар. «Балаларым мине аш пешерә дип уйласыннар һәм тыныч лансыннар өчен, казанда хәзер таш кайнатам», – ди. Гомәр аңа: «Сез нигә хәлифәгә бармыйсыз?» – ди. Теге хатын: «Без аны хәлифә итеп сайладык та, ул бездән ерагайды», – дип җавап бирә. Гомәр үзен акламакчы булып: «Ул сезне кайдан белсен соң?» – дип сорый. Хатын: «Без аны безгә якын булганы өчен сайладык. Ул хәлифә булды да, бездән ерагайды», – дип җавап кайтара. Гомәр башка үзен акларга сүз таба алмагач, тиз-тиз атлап китеп бара. Казнага барып, аннан бер капчык он, май алып чыга һәм теге хатынга алып бара. Үзе ризык әзерли. Тамаклары тук булгач, балалар да тыныч лап йоклап китәләр. Хатын аңа рәхмәтләрен белдерә: «Син хәлифәдән дә күбрәк эшләдең», – ди. Гомәр исә аңа хәлифә янына барырга киңәш итә һәм барган очракта үзеннән аңа сәлам җиткерергә куша.

Тагын бервакыт шулай урамда йөргәндә Гомәр елаган бала тавышын ишетә. Анасыннан баланың нигә елавын сорый. Теге хатын: «Күкрәгемнән алган саен балам елый. Ашарга ризык булмагач, күкрәгемдә сөт тә юк», – ди. Бу хатынның да ире сугышта вафат булган. Гомәр аңа баласын 2 яшенә җиткәнче имезергә боерып, китеп бара.

Соңыннан Гомәр разыйаллаһу ганһү читкә китеп, озак кына елап тора һәм үз-үзенә: «Әй, Гомәр, син шулай күпме кешенең башына җиттең, күпме баланы ачтан үтердең», – ди. Бу хәлләрдән соң Гомәр разыйаллаһу ганһү яңа туган балаларга 2 яшьләренә җиткәнче компенсация түләү хакында фәрман чыгара һәм ирләре сугышта вафат булган кешеләргә дә түләүләр бирелә башлый.

Гомәр разыйаллаһу ганһүнең казна малына игътибарлыгы

Гомәр разыйаллаһу ганһү хәлифәлек иткән чорда Ислам дәүләтендә кешеләрнең матди хәле яхшыра, казнада мал арта. Ул казна малына зур игътибар бирә. Хаксыз кергән малларны кире казнага җыя. Түбәндәге мисалларда бу бигрәк тә ачык күренә.

Бер көнне Гомәр янына туганы килеп, аннан акча сорый. Гомәр үзендә аңа бирергә җитәрлек акча булмавын әйтә. Туганы аңа казна малыннан алып бирергә тәкъдим итә. Гомәр аңа ачуланып: «Син мине Кыямәт көнендә сатлыкҗаннардан күрәсең киләме?» – дип куып чыгара.

Башка бер вакытны казна сакчысы Әбү Муса Әл-Әшгари казна идәненнән 1 дирһәм акча табып, Гомәрнең малаена бирә. Гомәр бу хакта белгәч, аны ныклап орыша: «Минем улымнан башка бала таба алмадыңмыни?» – дип биргән дирһәмен кире казнага кайтарырга ашыга.

Гомәр разыйаллаһу ганһү хөкүмәт эшләреннән туктап, ял иткәндә, шәхси эшләре белән шөгыльләнгәндә һәрвакыт хөкүмәт шәмен сүндереп, шәхси шәмен кабыза торган булган.

Гомәр разыйаллаһу ганһүнең сүзләре Коръән аятьләренә туры килү

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) Гомәр разыйаллаһу ганһү хакында болай әйтә торган булган: «Фәрештәләр Гомәрнең теле белән сөйли», чөнки Гомәр разыйаллаһу ганһү берәр мәсьәлә хакында әйтсә, шуны исбатлап Аллаһы Тәгалә Коръән аятьләрен иңдерә.

1) Бәдер сугышыннан соң әсирләр хакында киңәшләшкәч, Әбү Бәкер разыйаллаһу ганһү алар өчен мал алып, аларны азат итәргә тәкъдим итә. «Бәлкем Аллаһы Тәгалә аларны туры юлга бастырыр, алар безгә

ярдәм итәрләр», – ди. Гомәр разыйаллаһу ганһү исә аның белән килешми, аларны кылыч аша үткәрергә дигән тәкъдим белән чыга. Мөхәммәд галәйһис-сәләм Әбү Бәкер разыйаллаһу ганһүнең сүзен хуплый. Озакламый Коръәннән аятьләр иңә:

«Кулга төшкән әсирләрне мал алып азат итәргә пәйгамбәргә һич дөрес булмый, хәтта кәферләрне күп үтергәннәренә кадәр. Сез мөселманнар дөнья малын телисез, Аллаһ сезнең өчен ахирәтне тели, Аллаһ көчле вә хикмәт белән эш кылучы. Әгәр хата кылучылар гафу ителәләр дигән сүз Аллаһтан булмаса, әлбәттә, әсир өчен алган малыгыз өчен сезгә олуг газап ирешкән булыр иде».

«Әнфәл / Табыш», 8:67-68

Бу аятьләрдә Гомәрнең сүзләрен исбатлау һәм әсирләр өчен мал алуның дөрес түгеллеге раслана.

2) Монафикъларның башлыгы Габдулла бине Гобәй вафат булгач, аның абыйлары Мөхәммәд галәйһис-сәләм янына килеп, аннан җәназа намазы укуын сорыйлар. Пәйгамбәрез (аңа Аллаһының сәламе һәм рәхмәте булсын) Габдулла бине Гобәйне гафу итә һәм аңа җәназа намазы укый.

Гомәр разыйаллаһу ганһү Мөхәммәд галәйһис-сәләмгә монафикъларга җәназа намазы укуы һич дөрес түгел дип каршы чыга. Озакламый Гомәр разыйаллаһу ганһүнең сүзләрен куәтләп түбәндәге аять иңдерелә:

«Әгәр алардан берсе үлсә, мәңге җәназа намазын укыма һәм каберенә дә барып басма, ягъни монафикълар мәетенең бер эшенә дә катнашма, чөнки алар каршылык күрсәтеп Аллаһка һәм Аның Расүленә кәфер булдылар һәм тәүбә итмичә, фәсикъ хәлләрендә үлделәр».

«Тәүбә», 9:84

3) Гомәр разыйаллаһу ганһү Ислам динен кабул иткәннән соң хәмергә бик каршы була. Ул хәмернең кешеләр акылын томалавын күреп, Аллаһы Тәгаләдән һәрвакытта да дога кылып, хәмерне тыюын сорый. Аллаһы Тәгалә аның догасын җаваплы итеп, хәмерене тыя һәм әлеге аятьне иңдерә:

«Ий мөәминнәр! Исертә торган эчемлекләр, отыш уеннары, сыннарга гыйбадәт итү – Аллаһтан башка мәхлукларга табыну эшләре, шулай ук ырым-багучылык эшләре хәрамдыр, шайтан эшләреннән булган пычрак эшләрдер. Бу эшләрдән читләшсәгез, шаять, Аллаһ газабыннан котылырсыз».

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:90

Гомәр разыйаллаһу ганһүнең гаделлеге

Гомәр разыйаллаһу ганһү сәхабәләр арасында иң гаделләреннән саналган. Халык арасында ул «гадел Гомәр», «тугры Гомәр» исеме астында билгеле булган. Гомәр разыйаллаһу ганһү хәлифә булганнан соң да гадел, тугры хәлифә буларак тарихта эз калдыра. Үзе хәлифәлек иткән дәвердә ул залим әмирләрне алыштыра, һәрнәрсәдә гадел булып, һәр кешегә хакын бирергә тырыша. Ул хәлифәлек иткән вакытта Мисыр әмире Гамру бине Гас үзендә спорт ярышлары үткәрә. Йөгерү буенча узышта әмир малаен бер яһүди малае узып китә. Шул вакыт әмир бу яһүди егетне чакыртып: «Син ничек әмир малаен уза алдың?» – дип аны камчы белән суктырырга әмер итә. Бу яһүди егете Гомәр разыйаллаһу ганһүнең гаделлеген белеп һәм ишетеп, хаклык эзләп аның янына килә. Хәлне аңа сөйләп биргәннән соң Гомәр хәлифә Мисыр әмире малаен үз янына чакырта. Соңыннан яһүди егетенә камчы тоттырып: «Мә, үзен һәм үз баласын тәрбияли алмаган кешегә сук!» – ди. Яһүди егете аңа җавап итеп: «Мин бер кешегә дә

сугарга теләмим, мин бары тик хаклыкны, гаделлекне генә торгызырга теләдем», – ди.

Гомәр разыйаллаһу ганһү үзенә һәм гаилә әһелләренә карата да гадел була. Улы Габдеррахманның хәмер эчкәнен белгәч, ул аны камчы белән суктыра.

Гомәр разыйаллаһу ганһүнең шәһид булып китүе

Гомәр разыйаллаһу ганһү ислам динен кабул иткәннән алып шәһид булып китәргә тели һәм моның өчен барлык тырышлыгын куя. Барлык сугышларда катнашып, гел алгы сафларда була, үзен аямыйча көрәшә. Сугышлар тәмамланып, шәһид булып китмәгәч кайгырып елый, «мин шәһид булып китәргә лаек түгелмендер», – ди.

Бер көнне Гомәр разыйаллаһу ганһү төшендә башын кызыл әтәч чукыганын күрә. Төш юраучылар аңа: «Сине гарәп булмаган кеше үтерәчәк», – диләр. Гомәр разыйаллаһу ганһү моңа тыныч карый. Гадәттәгечә, иртәнге намазда сафларны тигезләп йөргәндә кайберәүләр аның «эт үтерде мине» дигән сүзләрен ишетеп калалар.

Гомәр разыйаллаһу ганһү тәкбир әйтеп, намазга кереп киткәч, имам артына баскан Әбү Лөэлә Әл-Мәҗүси Әл-Фәриси сафтан чыгып, Гомәрнең аркасына хәнҗәр белән берничә тапкыр кадый. Соңыннан мәчеттән качып чыгып киткәндә, сигез ирне, биш хатынны яралый. Аларның җидесе шәһид булып китәләр. Кайбер сәхабәләр Әбү Лөэлә качып китмәсен дип, аның өстенә чапаннарын ыргыталар. Ул шуларга абынып егылып, хәнҗәренә кадалып үлә.

Гомәр разыйаллаһу ганһү намазны дәвам иттерә алмый. Имам итеп Габдеррахман бине Гауфны куя. Намаз тәмам булганнан соң Гомәр разыйаллаһу ганһүне өенә алып керәләр. Аңа сөт, җимеш сулары биреп карыйлар, ләкин эчкән суы ярасыннан агып чыга. Үзенә хәнҗәр белән

кадаучының мәҗүси икәнлеген белгәч ул: «Әлхәмдулилләһ, мөселман кулыннан китмим», – дип әйткән.

Гомәр разыйаллаһу ганһү үзенең вафат булачагын сизенеп, васыятьләр әйтеп калдырган:

Гайшә разыйаллаһу ганһәдән үзен Мөхәммәд галәйһис-сәләм янына күмүләрен сорый. Моңарчы мондый тәкъдим белән килүчеләрне кире борып җибәргән, ризалашмаган Гайшә разыйаллаһу ганһү: «Мин бу урынны үзем өчен алып калган идем, ләкин аны сиңа бирәм», – ди.

Гомәр разыйаллаһу ганһү үзеннән соң төрле фетнәләр килеп чыкмасын өчен хәлифә буларак алты кешене тәкъдим итә һәм алар арасыннан хәлифә сайларсыз, дип васыять итеп калдыра. Алар түбәндәгеләр:

Гали бине Талиб

Госман бине Гаффан

Габдеррахман бине Гауф

Зөбәер бине Гаввам

Сәгыйд бине Әбү Вәккас

Талхә бине Гобәйдуллаһ

Гомәр разыйаллаһу ганһү 23 нче һиҗри елда (644 ел) сишәмбе көнне, җөмәдәл-ахыр аеның 22 нче көнендә, 63 яшендә шәһид булып китә. Вафат булганда җиде улы, өч кызы кала. Җеназа намазын аңа Сөхәйб бине Синан укый.

Гомәр разыйаллаһу ганһүнең эшләп калдырган эшләре

Гомәр разыйаллаһу ганһү хәлифәлеге вакытында ислам дәүләте үзенең чәчәк ату чорын кичерә. Ул ун ел дәвамында хәлифәлек итә. Бу вакытта үзенең бөтен барлыгын Ислам дине файдасына корбан итә һәм мөселманнарның һәр яктан алга китүләре, күтәрелүләре өчен күп тырышлык күрсәтә. Һәр җиргә эшлекле, тугры әмирләр билгеләп, идарә эшләрен

тәртипкә куя. Гомәр разыйаллаһу ганһүнең гайрәте, гаделлеге, кирәкле чаралар күрә белүе сәбәпле, мәмләкәтнең һәр почмагында тыныч-лык урнаша. Ислам дәүләте шул вакытта дөньяның иң олуг бер дәүләтенә әверелә.

Гомәр разыйаллаһу ганһү төрле шәһәрләргә һәм авылларга дин өйрәтер өчен мөгаллимнәр җибәреп, өйрәнгәннәрне имтихан кылу өчен махсус кешеләр җибәрә. Халык арасында гыйлем таратырга, укый-яза белүчеләрне күбәйтергә тырыша, укучы балаларга җомга көннәрендә ял итәргә әмер бирә. Гади халык өчен файдалы булган тәртипләр, кагыйдәләр кертелә:

1) беренче тапкыр ислам тарихы языла;

2) ел исәбен һиҗри календарь белән исәпли башлый;

3) хәмер эчүчеләргә 80 камчы суктыруны кертә;

4) Рамазан аенда мәчеткә җыелып, тәравих намазы укыла башлый;

5) Җомга көне ял көне буларак игълан ителә;

6) ашлык ташу өчен беренче тапкыр кораблар кулланыла башлый;

7) базарларда үлчәү тигез булсын өчен герләр коеп ясала;

8) почта хезмәте кертелә;

9) халык исәбе алына һәм хәлифәлек губерналарга (өлкәләргә) бүленә;

10) гаскәриләргә, ислам диненә хезмәт итүчеләргә, балалы хатын-нарга түләүләр (компенсацияләр) бирелә башлый.

Гомәр разыйаллаһу ганһүнең гайрәте, Исламга булган хезмәте, залимнәргә һәм дин дошманнарына карата каты куллы булуы, тугрылык өчен бөтен дөньяны корбан итү дәрәҗәсендәге ихласлыгы, гаделлеге һәм болардан тыш бик күп күркәм сыйфатлары киләчәк буыннарга мисал һәм үрнәк булып, Ислам тарихында калдылар.

Бервакыт ул, шәһәрдән читтә йөргәндә, бер көтүчегә очрап: «Фәләнурында азык күбрәк, хайваннарыңны шунда алып барып ашатырга кирәк.

Көтүче булган кеше хайваннар файдасын кайгыртырга тиеш, Кыямәт көнендә һәр көтүчедән көтүе хакында сорау булачак», – дигән.

Гомәр разыйаллаһу ганһү мөселманнар арасында кәсеп-һөнәрнең таралуын сөйгән; эшләмичә, башка кешеләр өстендә йөк булып торуны, бигрәк тә теләнчелекне сөймәгән, мөмкин кадәр теләнчелекне бетерергә тырышкан.

Бервакыт Гомәр разыйаллаһу ганһү бер кешенең агач утыртканын күргәч: «Бик яхшы эшкә керешкәнсең! Бу сиңа динеңне саклар өчен дә, дәрәҗәңне саклар өчен дә файда итәр», – дип бакча хезмәтенә кызыктырган.

Бер адәмнән: «Күпме малың бар?» – дип сорагач, әлеге кеше: «Ике меңә биш йөз дирһәм», – дигән. Гомәр: «Аңа гына канәгатьләнеп торма, кәсеп ит, хайваннарны да тәрбия ит», – дип, кәсеп итәргә өндәгән.

Гәүдәсе сау-сәламәт, таза егетләрне күргәндә: «Ни белән кәсеп итәсең?» – дип сораштырган. Әгәр берәрсенең һөнәре, кәсебе булмавын белсә, аның каршында ул кешенең дәрәҗәсе төшкән, игътибары калмаган. Әгәр берәр төрле кәсеп белән мәшгуль булганын белсә, аның ул кешегә карата илтифаты һәм игътибары арткан.

Бер кешенең күп вакытларда мәчеттә гыйбадәт белән мәшгуль булганын күреп: «Намаздан тыш вакытларда мәчет почмакларында утырга караганда, гаиләң өчен ризык кәсеп итү – синең өчен яхшырактыр», – дигән.

Гомәр разыйаллаһу ганһү, бер урында эшсез торучыларны күреп, «Болар кемнәр?» – дип сораган. «Алар Аллаһка тәвәккәл итүчеләр», – дигәнгә каршы, Гомәр: «Ялган сөйлиләр. Тәвәккәл кылучылар дип болай эшсез, хәрәкәтсез торучыларга түгел, ә җирләрне сөреп, орлык чәчеп, соңыннан: «Без үзебезнең кулдан килгәнне эшләдек», – дип, нәтиҗәсен Аллаһка тапшырып, өмет итеп торучыларга әйтелер», – дигән.

Гомәр разыйаллаһу ганһү диндә урталыкны сөйгән. Динсезлеккә чын дошман булганы кебек, диндә чиктән чыгуга, артык суфилык, урынсыз тәкъвалык күрсәтүләргә дә каршы булган. Шуның өчен өстенә йөкләнгән хезмәтләрен ташлап, гыйбадәт белән генә вакыт үткәрүчеләрне шелтәли, хәтта, кайберләренә җәза да бирә торган булган. Бигрәк тә Мөхәммәд галәйһис-сәләм вакытында һич булмаган, яки савабы булуы аның тарафыннан бәян ителмәгән нәрсәләрдән савап эзләп йөрүчеләрне бер дә яратмаган; халыкны һәртөрле бидгатьләрдән һәм дин исеменнән берәр нәрсә боерудан тыйган. Һәр гамәлен Аллаһны һәм Аның хозурына баруны уйлап башкарган.

Һидәят һәм хикмәтнең Коръәндә булуын яхшы аңлап: «Безгә Аллаһның китабы җитә», – дип әйтә торган булган; кичләрен Коръән укып, мәгънәсен камил аңлап, гаять әсәрләнеп йөргән. Коръән өйрәнүгә гаять зур әһәмият биргән, хәтта әмирләрне эш урыннарына җибәргәндә: «Халыкка хәдисләрдән бигрәк Коръәнне өйрәтергә тырышыгыз», – дип боера торган булган.

Гомәр разыйаллаһу ганһү суфилар шикелле күренергә тырышып йөрүчеләрне бер дә сөймәгән. Башын бөгеп утырган бер егетне күреп: «Ий кардәш! Башыңны күтәр! Суфилык – башта түгел, бәлки калебтәдер. Сез – динне тергезүчеләр түгел, ә, киресенчә, динне үтерүчеләр», – дигән.

Гайшә разыйаллаһу ганһә, бер кешенең зәгыйфь кешеләр кебек бөгелеп, акрын гына йөргәнен, акрын гына сөйләшкәнен күреп: «Гомәр дә чын заһид иде, ләкин ул болай йөрми иде, әгәр сөйләсә – сүзен ишеттереп сөйли, йөрсә – ашыгып йөри, җәза бирсә – авырттырырлык итеп бирә иде», – дигән.

Хафса бинте Гомәр разыйаллаһу ганһү

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (аңа Аллаһының сәламе һәм рәхмәте булсын) дүртенче хатыны, якын дусты һәм ярдәмчесе Гомәр разыйаллаһу ганһүнең кызы, мөэминнәрнең анасы. Ул 60 хәдисне тапшырган, дип риваять ителә.

Исеме: Хафса бинте Гомәр Әл-Кураши.

Туган елы, урыны: 606 елда (пәйгамбәрлек килергә 5-7 ел кала) Мәккәдә туган.

Әтисе: Гомәр бине Хаттаб разыйаллаһу ганһү, Мөхәммәд галәйһиссәләмнең үлеменнән соң икенче хәлифә.

Әнисе: Зәйнәб бинте Мәзгүн.

Хәләл җефете: Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын).

Хафса кече яшьтән үк Исламга мәхәббәт белән тәрбияләнә һәм шуңа да Ислам динен бик яшьләй, әтисе белән бергә кабул итә. Яшьлеге Мәккәдә әтисенең кул астында үткән. Гомәр бине Хаттаб Корәеш кабиләсенең иң мөхтәрәм һәм кыю кешеләренең берсе булган.

Гомәрнең һәм Хәмзәнең Ислам динен кабул итүен ишеткәч, мөһаҗирләр яңадан Мәккәгә кайтырга ашыкканнар. Һәбәштән (Эфиопия) кире кайтучылар арасында Хүнәйс бине Хүзәфә дә була. Өенә кайткач, ул Хафсаның атасына яучылар җибәреп, аңа өйләнә.

Яшь тол хатын

Ике тапкыр һиҗрәт кылган күренекле сәхабә Хүнәйс бине Хүзәфә башта Бәдер сугышында, аннары Өхед сугышында катнашкан. Өхед сугышында яраланып, ярасы баштарак төзәлгән кебек булса да, тиздән ялкын-

сына. Хүнәйс Мәдинәдә шул ярадан вафат була. Аның яшь хатыны Хафса тол кала.

Гомәр разыйаллаһу ганһү кызының язмышы өчен бик нык борчылган. Шулай бик яшьләй (Хафсага ул вакытта бары тик унсигез яшь кенә булган) тол калган кызы өчен кайгыра һәм аны тизрәк яңадан кияүгә бирергә тели. Ул заманнарда тол калган, аерылган хатыннарны, тиешле булган вакытлары үткәннән соң (гыйддә вакыты) тизрәк кияүгә бирергә тырышканнар. Шуңа да, Гомәр разыйаллаһу ганһү, кайгыртучан әти буларак, кызын ышанычлы кулларга тапшырырга, кияүгә бирергә теләгән. Кызы өчен ул лаеклы сәхабәләрне исенә төшергән.

Ниһаять, озак кына уйлаганнан соң, ул кызын Госман разыйаллаһу ганһүгә бирергә карар кыла һәм шул фикере белән аның янына бара.

Госман күптән түгел генә, Бәдер сугышыннан соң вафат булган хатыны – Пәйгамбәр галәйһис-сәләмнең кызы Рокыяны – җирләгән булган. Гомәрнең тәкъдименә җавап итеп, Госман разыйаллаһу ганһү: «Миңа уйларга вакыт бир», – дип әйткән. Әмма берничә көннән алар яңадан күрешкәч: «Мин хәзер өйләнергә теләмим!» – дип җавап биргән.

Шуннан соң Гомәр разыйаллаһу ганһү Мөхәммәд галәйһис-сәләмнең якын дусты һәм кияве Әбү Бәкер янына барырга уйлый. «Әбү Бәкер Хафсаның миннән мирас итеп алган көнчелеген һәм туры холкын кулда тота алыр иде», – дип уйлап, Гомәр Әбү Бәкернең өенә юнәлә. Ул аңа да хәлне сөйләп биргән. Әмма Әбү Бәкер бер сүз дә әйтмәгән. Гомәрне бу хәл бик рәнҗеткән, чөнки ул Әбү Бәкер дустының яшь, тәкъва, чибәр кызына өйләнер, дип өмет иткән.

Ике якын дустыннан да уңай җавап ала алмагач, Гомәр разыйаллаһу ганһүнең кәефе кырылган. Үзенең кайгысын сөйләргә дип, ул Мөхәммәд галәйһис-сәләм янына юнәлә. Пәйгамбәргә үзенең зарларын сөйләгәннән соң, Мөхәммәд галәйһис-сәләм елмаеп: «Хафсага Госманнан яхшырак

кеше өйләнәчәк, ә Госман Хафсадан яхшырак хатын-кызга өйләнсен», – дип әйткән.

Гомәр разыйаллаһу ганһү уйга кала. Берничә көн буена ул бу турыда уйлап йөри. Шуннан соң Мөхәммәд галәйһис-сәләм аңа: «Хафсаны миңа хатынлыкка бир, ә мин үз кызым Өмме Көлсемне Госманга хатынлыкка бирәчәкмен», – дигән.

Гомәр разыйаллаһу ганһү кешеләргә әлеге шатлыклы хәбәрне җиткерергә ашыккан. Ул очраткан беренче кеше Әбү Бәкер булган. Котлау өчен кул сузгач, Әбү Бәкер аннан гафу үтенеп: «Миңа ачу тотма. Аллаһның Илчесе Хафсаны үзе өчен искә алды, әгәр дә ул аңа өйләнмәсә, мин һичшиксез өйләнер идем», – дигән.

3 нче һиҗри елда, шәгъбан аенда Пәйгамбәр галәйһис-сәләм Хафсага өйләнә. Хафсага бу вакытта 20 яшь, ә Пәйгамбәребез галәйһис-сәләмгә 55 яшь була.

Чишелгән сер

Шулай итеп, Аллаһның Илчесенең өенә Хафса аның хатыны булып керә. Бөтен хатын-кыз кебек, ул да ире өчен бердәнбер булырга тели, ләкин Пәйгамбәр галәйһис-сәләмнең йөрәге Гайшәгә ятуын аңлый. Гайшә иртәрәк Пәйгәмбәрнең хатыны булса да, алар икесе дә яшь һәм сәхабәләрнең кызлары булалар. Гомәр кызының күңелендә нинди хисләр бар икәнен тиз аңлый һәм һәрдаим диярлек аңа үз киңәшләрен биреп, үгетләп торган. Ул кызына: «Гайшә белән чагыштырганда син кем соң? Аның әтисе белән чагыштырганда синең әтиең нинди урын алып тора?» – дип әйтә.

Көннәрдән бер көнне Гомәр разыйаллаһу ганһү хатыныннан Хафсаның Пәйгамбәр галәйһис-сәләмне рәнҗеткәнен ишетә һәм тиз арада кызы янына килә. Булган хәлләр турында сораштыра. Хафса: «Чыннан да шулай булды», – дип раслый. Шунда Гомәр разыйаллаһу ганһү: «Мин

сине Аллаһның җәзасы һәм Пәйгамбәрнең ачуы турында кисәтәм. Кызым, матурлыгы Пәйгамбәрне сокландырган кыз һәм Пәйгамбәрнең аңа булган мәхәббәте сине сукырайтмасын. Аллаһның Илчесе үзеңне яратмавы турында белгәнсең. Әгәр дә мин булмасам, ул синең белән аерылышкан булыр иде», – дип әйткән. Гомәр разыйаллаһу ганһү Хафсага, көнчелеген басып, Гайшә белән дуслашырга тәкъдим иткән. Ул Мөхәммәд галәйһиссәләмнән гафу сораган, кызының яшьлек ялгышы җибәрүен таныган.

Әтисенең үгетләүләренә карамастан, Хафсаның яшьлеге һәм буйсынмас холкы һәрвакытта да үзен сиздереп торган. Хатын-кыз көнчелеге түбәндәге вакыйгаларга сәбәпче булган һәм Пәйгамбәр галәйһиссәләмнең ризасызлыгын тудырган.

Хафса белән Гайшә Пәйгамбәр галәйһис-сәләмгә каршы сүз куешканнар. Булган хәлләрне төрле хәдисләрдә төрлечә бәян итәләр.

1. Гайшәдән (Аллаһ аннан разый булсын) риваять ителә:

«Пәйгамбәр галәйһис-сәләм Зәйнәп бинте Җәһеш янында озаккарак тоткарланган һәм аның өендә бал эчкән. Мин һәм Хафса сүз куештык, әгәр Пәйгамбәр галәйһис-сәләм аннан кайтып, берәребез янына керсә, «Синнән мәгафир (яман исле сагыз) исе килә», – дип әйтәчәкбез. Пәйгамбәр галәйһис-сәләм өенә кайтып, аларның берсеннән шул сүзләрне ишеткән һәм җавап итеп: «Мин Зәйнәп бинт Җәһештә бал эчтем. Ант итәм, мин беркайчан да башка болай эшләмәм», – дип әйткән. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә Коръәннән әлеге аятьне иңдерә:

«Ий Пәйгамбәр! Ни өчен син хатыннарыңның яхшы мөнәсәбәтен теләп, үзеңә Аллаһ хәләл кылган нәрсәләрне хәрам кыласың? Аллаһ – Гафу итүче, Рәхмәтле».

«Тәхрим / Тыю», 66:1

Шулай ук хатыннарына мөрәҗәгать кебек:

«Ий Хафса һәм Гайшә, әгәр Аллаһка тәүбә итсәгез, әлбәттә, тәүбә итәрлек эшегез булды, сезнең күңелегез үзегезгә вәҗиб бул-

ган эштән авышты. Әгәр сез Расүл зарарына ярдәмләшсәгез, дөреслектә, Аллаһ – Ул Расүл галәйһис-сәләмнең хуҗасы һәм ярдәмчеседер, Җәбраил фәрештә аның ярдәмчеседер, мөэминнәрнең яхшылары аның ярдәмчеләредер һәм болардан башка фәрештәләр аңа ярдәмчеләрдер».

«Тәхрим / Тыю», 66:4

2. Әнәстән (Аллаһ аннан разый булсын) риваять ителгән хәдистә әйтелгән: Пәйгамбәр галәйһис-сәләм Хафсаның өендә Мәрьям исемле кәнизәге белән ялгыз калган. Бу аңа тагын күңелсезлек китергән. Моны белгәч, Хафса: «Әй Аллаһның Илчесе, ни өчен нәкъ минем өйдә?» – дип сораган. Пәйгамбәр галәйһис-сәләм: «Хафса, моннан соң мин үземә аңа кагылуны хәрам кылам. Үтенеп сорыйм, бу турыда беркемгә дә сөйләмә», – дигән. Әмма Хафса тыелып тора алмаган һәм бу турыда Гайшәгә сөйләгән. Шушы уңайдан «Тәхрим / Тыю» сүрәсенең беренче биш аяте иңдерелгән.

Булган хәлләр Пәйгамбәребез галәйһис-сәләмгә нык тәэсир итә һәм ул Гайшә белән Хафсаның янына бер ай дәвамында кермәскә ант итә. Бу вакыт аралыгы Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм һәм үз гамәлләрендә үкенгән хатыннары өчен дә бик авыр була. Ул бер ай дәвамында аларның өйләренә кермәү генә түгел, хәтта исемнәрен дә телгә алмый, сәхабәләренең берсе дә аларга бәйле булган нәрсәләр турында бер сүз дә әйтмиләр. Шуңа да халык арасында Аллаһның Илчесе хатыннары белән аерылган, дигән хәбәр тарала. Әмма беркем дә бу турыда аның белән сөйләшә башларга җөрьәт итмәгән.

Гомәр разыйаллаһу ганһү мондый билгесезлекне кичерә алмаган һәм Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм янына килгән. Ул вакытта Пәйгамбәр галәйһис-сәләм янында аның хезмәтчесе Рабәһ булган. Гомәр керергә рөхсәт сораган, ләкин Рабәһ эндәшмәгән. Гомәр үтенечен кабатлаган да: «Син мине Хафса өчен килгән дип уйлыйсыңдыр... ант итәм, әгәр дә Аллаһның Илчесе миңа аның башын чабарга боерса, мин һичшиксез

шулай эшләр идем», – дигән. Гомәрнең сүзләрен ишеткәч, Пәйгамбәр керергә рөхсәт биргән. Ул Гомәрдән: «Син ник елыйсың, Хаттаб улы?» – дип сораган. Тегесе: «Әгәр дә син хатыннарыңа талак биргән булсаң, Аллаһ синең белән, Аның фәрештәләре Җәбраил һәм Микаил, мин, Әбү Бәкер һәм мөәминнәр синең белән», – дип әйткән. Мөхәммәд галәйһис-сәләм елмайган, Гомәрне тынычландырып, хатыннары белән аерылмавын, бары тик аларны бер айга калдыруын хәбәр иткән.

Зур ышаныч

Әлеге кылган эше өчен Хафса бик тә үкенгән. Моннан соң ул беркайчан да хатын-кыз фетнәләрендә катнашмаган, иренең ачуын чыгарырлык гамәлләр кылмаган. Ул Мөхәммәд галәйһис-сәләмгә мәхәббәт һәм тугрылык хисләре белән бәйле булган. Берәр бүләк яки сый-хөрмәт кабул итеп алса, аны ашамаган, Пәйгамбәребез галәйһис-сәләмгә саклаган, аңа хөрмәт күрсәткән. Бервакыт аңа кечкенә мичкәдә бал бүләк итәләр, ул аңа кагылмый, Мөхәммәд галәйһис-сәләмгә калдыра һәм ул аның янына килгән саен баллы ширбәт әзерли торган булган.

Пәйгамбәребез галәйһис-сәләм 63 яшендә вафат була. Аның үлеменнән соң Хафса (Аллаһ аннан разый булсын) Мәдинәдә кала, Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кыла. Хаҗ һәм гомрә кылудан кала өеннән бик чыгып йөрми. Мөхәммәд галәйһис-сәләмнең вафатынан соң да ул мөселманнар тормышында мөһим роль уйный.

Әбү Бәкер разыйаллаһу ганһү хәлифәлек иткән дәвердә Изге Коръән бер китап булып җыела һәм бу бердәнбер нөсхә була. Әбү Бәкер разыйаллаһу ганһү үзе үк бу беренче кулъязманы саклаучы итеп билгеләнә һәм аны үлгәнчегә кадәр үзендә саклый. Аның вафатыннан соң бу нөсхә Гомәр разыйаллаһу ганһүгә бирелә һәм ул шәһид булып киткәнчегә кадәр анда саклана. Гомәр разыйаллаһу ганһү нык яралангач, Коръән кулъязмаларын сакларга кызы Хафсага тапшыра.

Бераз соңрак мөселманнар арасында Коръән уку буенча төрле каршылыклы сораулар туа. Бу хәбәр Хөзәйфә бине Әл-Йәмән исемле сәхабәгә барып җиткәч, ул куркуга кала һәм тизрәк Госман бине Гаффан янына ашыга. Шуннан соң Госман (Аллаһ аннан разый булсын) мөселманнар арасында төрле фикер каршылыклары, бидгать гамәлләр килеп чыкмасын өчен Коръән укуның бердәм формасын расларга карар кыла. Ул мөэминнәрнең анасы Хафсадан бер мосхафка туплар өчен Изге Коръәннең кулъязмасын алып тора. Бу мосхаф Зәйд бине Сәбит җитәкләгән Коръән-хафизлар төркеме ярдәмендә туплана. Госман бине Гаффан әзер мосхафның җиде күчермәсен ясап, җиде төбәккә тарата (Мәккә, Мәдинә, Куфа, Басра, Йәмән, Мисыр, Шам). Коръәннең төп нөсхәсе Хафсага (Аллаһ аннан разый булсын) кайтарып бирелә һәм үлеменә кадәр анда саклана. Шуннан соң, васыять итеп ул абыйсы Габдуллаһ бине Гомәргә тапшырыла.

Һиҗри белән унөченче елның җөмәдәл-ахыр аенда беренче хәлифә Әбү Бәкер Әс-Сыддыйк вафат була. Идарә Гомәр бине Хаттаб кулына күчә. Хафса әтисенең дан-шөһрәтенең, Шам, Гыйрак һәм Мисырның яулап алынуының шаһите була. Башкалар кебек үк, һиҗри белән егерме өченче елның зөлхиҗҗә аенда аның үтерелүеннән тетрәнә.

Гомеренең ахырын Хафса Мәдинәдә ялгызлыкта, гел ураза тотып, намазларын укып үткәрә. Могавия бине Әбү Суфьян идарә иткән чорда, 61 яшендә вафат була. Җеназа намазын аңа Мәрван бине Әл-Хәким укый. Хафсаны кабергә чаклы барлык Мәдинә халкы озатып бара. Күмүчеләр арасында Габдуллаһ һәм Гасыйм исемле абыйлары, бертуганнарының уллары – Сәлим, Габдеррахман, Хәмзә һәм Әбү Сәед Әл-Худри исемле сәхабә була. Хафса Пәйгамбәр галәйһис-сәләмнең башка хатыннары кебек үк, Җәннәт Әл-Бакый зиратына күмелә.

Әхмәтһади Максуди

Әхмәтһади Максуди – XX гасырның беренче чирегендәге татар дөньясында иң укымышлы зыялыларыбызның берсе. Аны үз заманында ук «иң-иңнәрнең», ягьни иң танылган шәхесләрнең беренче унлыгына керткәннәр. Ул – татар әлифбасына 6 хәреф кертеп, «имляда ишетелгәнчә язу тиешле» дип уку-укыту системасын яңача укыту юлына кертеп җибәрүчеләрнең берсе, – 1906 елдан башлап 1918 елга кадәр чыгып килгән иң күп тиражлы «Йолдыз» гәзитенең нәшир-редакторы, XX йөз башы татар милли хәрәкәтендә танылган җәмәгать эшлеклесе.

Һади Максуди – Әхмәтһади Низаметдин улы Максудов 1868 елның 28 сентябрендә Казан губернасы Ташсу авылы (хәзерге Биектау районына керә) мулласы гаиләсендә туган. Низаметдин мулла гаиләсе татар дөньясына ике олуг шәхес – Һади һәм Садри Максудиларны биргән.

Әхмәтһади башта үз авылындагы әтисе мәдрәсәсендә укый. 1881 елны ул Казанга килә, заманының мәшһүр мәдрәсәләренең берсе булган «Күл буе» яки «Галләмия» мәдрәсәсенә укырга керә һәм сигез ел дәвамында шунда белем ала. Укып бетергәч – 1890-92 елларда шунда ук мөгаллимлек итә. Мәдрәсәләрдәге укыту системасын үзгәртү кирәклеген иртә аңлаган яшь мөгаллим 1892 елда татар мәгарифендә чын мәгьнәсендә инкыйлаб ясаган, ягьни татар әлифбасына 6 хәреф кертеп, һәм «Имляда ишетелгәнчә язу тиешле» дигән кагыйдәсеннән файдаланып, үзенең «Мөгаллим әүвәл» әлифбасын бастырып чыгара. Әлеге дәреслек 1918 елга кадәр барлыгы 32 басма кичерә, татар балалары өчен генә түгел, ә казакъ, башкорт, кыргыз, үзбәк балаларының да уку китабы булуы белән уникаль күренешкә әйләнә.

Мәдрәсәләрдә яңача уку-укыту, тәрбия тәртипләрен кертү, Европа, рус югары уку йортлары дәрәҗәсендә белем бирү, мәктәп-мәдрәсәләргә яңача уку-укыту, тәрбия тәртипләрен кертү кирәклеген, ә моңа ирешү

бары тик яхшы һәм заман таләпләренә туры килә торган дәреслекләр язу һәм бастыру белән генә мөмкин булачагын аңлаган мөгаллим үзе дә барлыгы 30 дан артык исемдә дини һәм фәнни дәреслекләр, методик кулланмалар яза һәм аларның һәрберсе диярлек 2-3-6 басма кичерәләр. Соңрак олы галим Ж.Вәлиди аның «Төрки сарыф» (морфология), «Төрки нәхүе» (синтаксис), «Шифаһия» («Гарәп телен өйрәнү өчен 100 дәрес») кебек хезмәтләренә югары бәя биреп: «Бу китаплар туган телебезне өйрәнү өлкәсендә чын мәгьнәсендә фәнни хезмәтләр булды», диячәк. Аның «Мөгаллим әүвәл» һәм «Гыйбадәте исламия» дәреслекләре бөтен бер тарихи чорны алып торалар, алар хәтта, гарәп теленә тәрҗемә ителеп, Мисыр мәктәпләрендә дәреслек булып та кертеләләр.

Мәдрәсәләрдәге уку-укыту системасын үзгәртеп кору проблемасын, үзе остазы санаган И. Гаспринскийга ияреп, беренчеләрдән булып күтәреп чыккан Һ. Максуди үзенең барлык дәреслекләрен дә үзе тәкьдим иткән принципларга таянып язган, шуңа да аның дәреслекләре аңлаешлы телдә язылуы, югары дәрәҗәдә булуы белән аерылып торганнар. Ул чыгарган китап-дәреслекләрнең гомуми тиражы 1 200 000нән артып киткән.

«Ул үзенең әлифбалары белән ысул җәдид хәрәкәтен башлап җибәрүчеләрдән булды». Һәм «Һади әфәнде язган мәктәп дәреслекләре «чук гүзәлдер», дип язачак соңрак Г. Баттал-Таймас «Ике Максудилар» дигән хезмәтендә.

1

1893 елда ул Төркиягә китә һәм андагы яңа ысул белән укыту системасы белән таныша, татарча гәзит чыгару уе белән янып йөргән Һ. Максуди анда гәзитчелек серләренә дә өйрәнә. Монда ул төрек язучысы Ж. Мидхәт белән таныша, «Икьдам» гәзите редакторы белән дуслаша, хәтта бераз вакыт әлеге гәзиттә эшләп тә ала. Төркиядән кайтышлый ул, И.Гаспринский чакыруы буенча, Кырымда Бакчасарайда туктала, андагы Зынҗырлы

мәдрәсәсендә укыта, «Тәрҗеман» гәзитендә эшли. Һ. Максуди бу чорда И. Гаспринский белән еш очраша, алар яңача укыту, тел-имля мәсьәләләре, төрки бердәмлек хакында кызу бәхәсләр алып баралар. Тел мәсьәләсендә һәр икесе үз фикерен кайнар яклый. И. Гаспринский Россиядә яшәгән барлык төрки халыклар өчен уртак бер әдәби тел кирәклеге фикерендә калса, Һ. Максуди татар халкы өчен әдәби тел Казан арты сөйләме булырга тиеш дигән уеннан кайтмый. И. Гаспринский белән якыннан танышу Һ. Максудида бу милләтпәрвәргә карата тирән ихтирам хисләре уята һәм ул гомере буена И. Гаспринскийга карата олы хөрмәт хисләрен саклап яши. Һәм Һ. Максуди 1908 елның 21 мартында үзенең «Йолдыз» гәзитендә «Тәрҗеман» гәзитенең 25 еллыгы уңае белән: «Тәрҗеман» газетасы милли газеталарыбызның беренчесе, ә И. Гаспринский – татарда милли хисне тудырган, уяткан, үстергән бер кешедер», – дип язачак.

1896 елны Һ. Максуди Казанга кайта һәм Казан укытучылар мәктәбендә экстерн юлы белән имтиханнар тапшырып, укытучы дипломы ала. 1897 елда «Бертуган Юнысовлар» химаясындагы мөселман балалар приютында татар теле, тарихы һәм җәгърәфия фәннәрен укыта. Ул бу елларда яңача дәреслекләр язу һәм мөгаллимлек итү белән шөгыльләнә.

1892 елдан башлап татарча гәзит чыгаруны үзенә максат итеп куйган Һ. Максуди 1905 елга кадәр 4-5 мәртәбә «Йолдыз», «Көндез», «Казан» исемендәге гәзитләр һәм «Йолдыз» исемендәге журнал чыгарырга рөхсәт итүне сорап Матбугат эшләре буенча Баш идарәгә үтенеч хатлары яза, әмма рөхсәт ала алмый. Һәм, ниһаять, 1905 елгы рус революциясе биргән мөмкинлекләрдән файдаланып, ул үзенең күптәнге хыялына ирешә. 1906 елның 15 гыйнваренда өченче татар гәзите (Петербургта 1905 елның 2 сентябреннән чыгып килгән «Нур» һәм Казанда 1905 елның 29 октябреннән чыга башлаган «Казан мөхбир»еннән кала) «Йолдыз» гәзитенең беренче саны дөнья күрә. Шул көннән башлап 12 ел дәвамында беренче елларда атналык, аннан атнага 2 мәртәбә, тора-бара көндәлек булып чыга баш-

лаган гәзитнең тиражы да 5-6-8 меңгә җитә. Гәзит яхшы кәгазьдә, югары техникалы һәм җиңел укыла торган телдә басыла. «Йолдыз»ның таралу географиясе гаҗәп киң булуы аның үз укучысын тапкан, аны кызыксындырган, борчыган сорауларга җавап бирергә тырышкан, ягьни татар халкы тормышында зур урын алып торган гәзит икәнен раслаучы факт булуын да күрсәтә әле. «Йолдыз» гәзитен Казан, Оренбург, Уфа, Самара, Саратов, Вятка, Пермь, Новгород, Симбирск, Томск, Владимир, Тамбов, Смоленск, Екатеринслав, Петребург, Спасск, Әстерхан, Шуя, Ташкент, Тобольск, Петропавловск, Семиплатинск шәһәрләрендә, Тургай, Закаспийск, Сәмәрканд, Иркутск өлкәләрендә алдырганнар.

«Гәзит, төбендә, татарча әдәби телне идеал итеп ала, шуңа омтыла башлаган иде. Сәяси эшләрдә мәсләксезлекне үзенә мәсләк иткән «Йолдыз» бу турыда мәсләксез булмады. Тел мәсьәләсендә гамәли яктан да, назари яктан да ахыр гомеренә кадәр шуңа күбрәк игьтибар итүче «Йолдыз» булды. Бу – «Йолдыз»ның абруе күтәрелүгә, аның өчен язучы каләмнәр табылуга да бер сәбәп иде», дип яза Г. Сәгьди 1926 елда.

Һ. Максудиның татар мәгарифенә багышланган эшчәнлеген «Йолдыз» гәзитенең нәшер-редакторы эшчәнлегеннән аерып карап булмый. «Йолдыз» гәзите битләрендә 12 ел дәвамында уку-укыту һәм тәрбия проблемалары киң яктыртыла, чөнки анда төрле фикердә булган һәм төрле карашны яклаган татар зыялыларының мәкаләләре чыгып бара.

«Йолдыз» гәзитенең тоткан кыйбласы, теге яки бу проблемаларга булган мөнәсәбәте, патша хөкүмәтенең милли сәясәте, Русия Дәүләт думаларында күтәрелгән мәсьәләләр һәм аларның чишелеше мәсьәләләре, анда тикшерелгән закон проектларына булган карашны күрсәтүе аша аның редакторы Һ. Максудиның да заманының иң зыялы, киң эрудицияле сәясәтче икәнен күрергә, шулай ук аның үзе язган һәм С. Максудиның «Йолдыз» да басылып барган үткен, кыю мәкаләләренә карап, Һ. Максудиның да татар җәмәгатьчелеге дөньясында тоткан урынын билгеләргә була.

«Йолдыз» гәзитен совет чоры галимнәре «либерал-буржуаз газета» дип бәяләделәр. «Вакытлы татар матбугаты» исемле хезмәтендә И. Рәмиев, совет чынбарлыгы күзлегеннән чыгып, «Милли мәсьәләләрдә – чын милләтчелек, яңарак берәр мәсьәлә алдына килеп басса, безнең фикеребезчә, тегеләйрәк, ди. Сәяси мәсьәләләрдә имеш-мимеш белән күбрәк эш күреп, үзләренең чырайларын күрсәтмичә, яшереп калырга ярата иде. Кызыклырак мәкалә һәм хәбәрләрнең азагына. «Идарә бу мәсьәлә турында үз фикерен әйтми әле», дип куя иде. Беренче саннарында ук: «Бу еллар кебек мәсләкләр чуалган заманда бер мәсләкне билгеләп куюда кыенлык бар», ди. Шулай итеп, бу газета, юл-фәлән билгеләп тормастан, чыга башлый, һәм ахыр гомеренә кадәр, үзенә кискен бер юл алмыйча бара бирде», дип бәя бирә.

2

Революция елларында ачылган «Азат», «Азат халык», «Урал» кебек демократик газеталар озак яши алмыйлар – 15-30 сан чыгарырга гына өлгереп, бер-бер артлы ябылалар. Г. Камал, «Азат халык» гәзите ябылгач,1906 елның 16 сентяберендә «Йолдыз» гәзитенә эшкә килә һәм берничә ел анда җаваплы секретарь булып эшли. Һ. Максуди үзе дә аның «Йолдыз» гәзитенең тоткан юлын билгеләүдә төп роль уйнаганын таный. 1907 елдан башлап гәзиттә Г. Камалның фикердәшләре, каләмдәшләре Г. Тукай, Г. Ибраһимов, З. Камали, Г. Баттал, С.Рәмиев, К. Бәкер, Г. Атласый, С. Максуди языша башлыйлар.

1913 елның июнендә исә гәзиткә Г. Баттал эшкә килә һәм ул 1917 елның җәенә кадәр сәркәтиб булып эшли. Ул эшләгән чорда «Йолдыз» гәзитенең тиражы 6-7 меңгә җитә.

И. Рәмиев «юлсыз-фәләнсез» дип мөһер сукса да, Һ. Максуди үзе «мәсләксез» дип белдерсә дә, «Йолдыз» ның тоткан юлы, ныклы бер мәсләге булган, дип ышанып әйтергә кирәк. Аның төп мәсләге, тоткан

юлы – ярлыга-байга, наданга-укымышлыга, милләтчегә, социалистка аермыйча, бербөтен халыкка – татар милләтенә хезмәт итү булган.

Һ. Максуди журналист-нәшир буларак, татар җәмәгатьчелеге һәм аның вакытлы матбугатында барган кадимчелек һәм җәдидчелек фикерләре көрәшенең уртасында булган. Бар белемен, көчен яңарыш, үзгәртеп корулар, ягьни, татар халкының сәяси аңын үстерү, аны дөньяви белемле, мәдәниятле итү, икьтисади, сәяси хәлен Европа халыклары дәрәҗәсенә күтәрү максатына багышлаган Һ. Максуди төрле мәсләк тотып икегә бүленгән татар дөньясын берләштерүгә, һич югы бер-берсе белән фикер көрәшенә-сугышына кертмәү өчен дә зур тырышлык куйган. Шуңа күрә дә ул үз гәзите битләрендә: «Заманга яраклашып үзгәрүне хәйәт вә безнең милләт буларак яшәргә тиешлегебез таләп иткәнгә күрә, үзгәрмичә, яңармыйча калу һич мөмкин түгел», дип җәдидчеләрне һәм кадимчеләрне иске белән яңаны сугыштырып вакыт уздырмаска, ә бар көчне милләт тәрәккыятенә хезмәт итүгә юнәлдерергә чакыра. 12 ел буена патша хөкүмәтенең милли сәясәтенә каршы торып үз сәхифәләрендә татар дәньясынындагы барлык милли проблемаларны яктыртып бара алган һәм шул мәсьәләләрдә кызу бәхәсләр күтәргән дистәләгән, йөзләгән мәкаләләр биргән һәм күп гәзит-журналлар ябылуга дучар ителгәч тә, үз йөзен, меңләгән укучысын саклап Октябрь көннәренә кадәр килеп җитә алган бу гәзит, чыннан да, татар дөньясында якты йолдыз булып янган диярга кирәктер. «Йолдыз» гәзитенең төп мәсләге, тоткан юлы ул – ярлы-байга, надан-укымышлыга, милләтче-социалистка аермыйча, бербөтен халыкка – татар халкына хезмәт итү, аның бүгенгесе, киләчәк язмышы өчен борчылып, аны сәяси, милли һәм экономик яктан башка дөнья халыклары дәрәҗәсенә күтәрү, үстерү, дөнья мәйданына чыгару.

Көн кадагына суккан мәкаләләре белән – ил-көн, халык тормышын яктыртып, татар халкының теле, дине, әхлагы, мәгарифе, мәдәнияте мәсьәләләрен күтәреп – үзенең 10 еллык юбилеена килеп җитә алган

гәзит 1916 елнын 15 январь санында болай дип яза: «Бу 10 сәнәлек вакыт эчендә мәмләкәтебездә бер гасырлык үзгәрешләр булды, фикер һәм мәсләкләр төрлегә авышты. Милләткә гаид эшләрдә «Йолдыз» һич сулланмады, һаман милләт фикеренә тугры калып барды. Гаять тә болганчык сәясәт һәм фикер вә хәбәр диңгезендә бик зур осталык вә саклык белән, гаять нечкә сәясәт йөртеп булса да, исән-сау йөзеп чыгу шәрәфенә ирештек.» Бу юлларда «Йолдыз» гәзитенең генә түгел, ә инде аның редакторы булган Һ. Максудиның да сәяси йөзе һәм мәсләге – миллият фикеренә тугры калып – татар милләтенә хезмәт итүе ачык күренә.

Чыннан да, шундый болганчык һәм 10 елы бер гасырга торырлык бу елларда үз гәзитен 12 ел буена исән-имин килеш 1918 елга кадәр китереп җиткерә алган Һади Максуди үткен каләмле журналист, сабыр, акыллы редактор гына түгел, оста сәясәтче, дипломат та булган.

Берничә ел «Йолдыз» гәзитендә эшләгән Г. Батталның, еллар үткәч, Төркиядә эмиграциядә язган «Ике Максудилар» дигән хезмәтендә «Әхмәдһади Максуди – «Йолдызчы» бүлегендә: «Һади әфәнде, һичшиксез, акыллы, дәрәҗәле, күп белемле кеше булса да, аңа тәвәкәллек җитми, ул артык сак кеше иде», дигән юллар да бар.

Әгәр Һ. Максуди сак һәм һәр адымын уйлап эшләүче нәшир-редактор булмаса, ул 12 ел буена «Йолдыз» гәзитен чыгара алыр идеме икән.

1906 елның 15 гыйнваренда 1 саны чыккан «Йолдыз» гәзите кара реакция елларын да уза, Беренче Бөтендөнья сугышы елларында да үз йөзен саклап кала ала, Февраль революциясеннән соң да яшәвен дәвам итә. Башка татар зыялылары шикелле үк Һ. Максуди да Февраль революциясен халыкның зур жиңүе итеп шатланып каршы ала. Ул хөрриятка зур өметләр баглый һәм милләт үсешенә киң юллар ачылыр дип ышана. Әмма бу өметләр акланмый, татар зыялылары зур ашкыну белән көткән хөррият тормышка ашмый, чөнки Октябрь инкыйлабы дөньяны башка якка борып алып китә. Октябрь инкыйлабына, Совет властена һәм аның

сәясәтенә, илдәге үзгәрешләргә бик сак караган, дөресрәге, аларны кабул итә алмаган Һ. Максуди үзе дә һәм аның «Йолдыз» гәзите дә яңа власть-ка мәдхия җырлый алмаган. 1918 елның 21 июнендә 12 ел татар халкына хезмәт иткән «Йолдыз» гәзитенең соңгы – 1900 саны чыга.

Һ. Максуди әле күп санлы дәреслекләр авторы, «Йолдыз» гәзите редакторы булуы өстенә үз заманының танылган җәмәгать эшлеклесе дә була. Ул – Казанда беренче татар китаханәсен – «Китапханәи исламия» оештыручыларның берсе– китапханә 1906 елның 2 гыйнваренда ачыла – һәм шул көннән башлап 1923 елга кадәр аның мөдире була. (Китапханә Кәримовлар йортында (хәзерге Г. Тукай исемендәге урам, 37 йорт) урнаша). Китапханәнең матди ягы «Ярлы мөселманнарга ярдәм» жәмгыяте рәисе М. Б. Апанаев ярдәме белән шәһәр думасы аша хәл ителә, ел саен китапханәгә 1000 сумлап субсидия бирелеп барыла. Китапханә атнага ике көн бары тик хатын-кызлар өчен генә эшли.

Һ. Максуди – «Иттифак әл-мөслимин» партиясен оештыручыларның берсе һәм аның барлык съездларының да эшендә катнашкан вәкил. Ул әлеге партиянең мәктәп-мәдрәсә эшләре комиссиясе секретаре буларак та шактый гына эшләр башкарган, ә Казан шәһәр думасы әгъзасы – гласный буларак, шушы проблемалар каралганда, дума жыелышларында чыгышлар ясаган. И. Рәмиев һәм аның кайбер замандашлары аны мәсләксезлектә гаепләсәләр дә, мөһим мәсьәләләр хәл ителгәндә ул принципиаль булган. Мәсәлән, 1914 елның 22 маенда думада ял көннәрен билгеләү мәсьәләсе тикшерелгәндә, мөселманнар өчен җомга көнне ял көне итү турындагы мәсьәлә каралмауга протест йөзеннән мөселман гласныйлары белән берлектә ул дума җыелышын ташлап чыга.

I Бөтендөнья сугышын халык өстенә килгән олы афәт итеп кабул иткән Һ. Максуди 1914 елның август аенда Казанда, Петроградтан кала икенче булып, сугышта һәлак булганнарның туганнарына һәм яралы солдатларга ярдәм итү өчен Мөселман комитеты төзүдә башлап йөрүчеләрнең

берсе була. Мулла С. Иманколый белән берлектә оештырылган әлеге комитет бу елларда яралы мөселман солдатларының хәлләрен жиңеләйтү йөзеннән шактый гына эшләр дә башкара.

Әмма Октябрь инкыйлабыннан соң 5-6 тел белгән, 30 елдан артык педагогик стажлы һәм 30лап дәреслек язып бастырган педагог-галимнең, 12 еллык журналистлык тәҗрибәсе булган татар дөньясында киң танылган шәхеснең – төрки халыклар арасында мәгариф һәм мәдәният өлкәсендә «хезмәтләре гаять бөек булган» Һ. Максудиның совет властена кирәге калмый. 1927 елда аңа Совет хөкүмәте тарафыннан «пожизненно» дип 50 сум күләмендә пенсия билгеләнелә. Һ. Максуди башта педагогия институтында гарәп теле укытырга, аннан чыгарылгач, китап төпләү артелендә эшләргә мәҗбүр була. Шушы шартларда да галим үзенең гыйльми эшчәнлеген туктатмый. 1927 елда ул 5000 тираж белән әле бүген дә үзенең фәнни кыйммәтен югалтмаган «Фәнни камус»ын – татарча беренче энциклопедик сүзлек бастырып чыгара.

Октябрь инкыйлабыннан соң башланган эзәрлекләүләр, татар зыялылары язмышы Һ. Максудины да читләтеп узмый. Һ. Максуди кулга беренче мәртәбә 1933 елның 16 гыйнваренда алына. Ул ВСФП-Бөтенсоюз социал-фашист партиясен оештыруда һәм Казан тирәсендәге районнарда совет властена каршы эш алып баруда, Төркия файдасына шпионлык итүдә, эмиграциядәге С. Максуди, Г. Исхакый, Ф. Туктаровлар белән элемтәдә торуда гаепләнә. 4232 нче номерлы әлеге эшне оештыручылар – НКВД органнары Казан һәм Казан тирәсендәге районнарның элеккеге мулла-мөдәррисләрен, мөгаллимнәрен җыеп алганнар һәм аларны контрреволюцион эш алып баруда гаепләп, төрлесен-төрле срокка хөкем иткәннәр. Һ. Максуди исә алар тарафыннан әлеге оешманың җитәкчесе итеп билгеләнелә һәм 3 елга Вятка шәһәренә сөргенгә җибәрелә.

Һ. Максуди сөргендә үзенең гыйльми эшчәнлеген ташламый. Көнчыгыш фәлсәфәсен яхшы белгән галим монда көнчыгыш фәлсәфәсенә

багышланган хезмәтен – «Восточная логика»ны – яза һәм аны русчага тәрҗемә итү белән шөгыльләнә. Бу – фәлсәфә буенча татарча язылган беренче хезмәт. Әлеге хезмәт Көнчыгыш һәм Европа галимнәренең фәлсәфи хезмәтләрен берләштереп язылган, ягьни «яңа диалектик логика» буларак та кызыклы әле.

Сөрген срогы тулганнан соң, 1936 елның ахырында Һ. Максуди Казанга кайта. Ләкин ул иректә озак яши алмый. 1937 елның гыйнваренда тагын шул ук контрреволюцион эшчәнлектә гаепләп аны кабат кулга алалар. Төрмәдә җәбер-золымнар күрүенә дә карамастан, Һ. Максуди кулга алынган татар зыялылары – үзенең фикердәшләре өстеннән язылган яларга кул куймый, күрсәтмәләр бирми, үзенең намусына каршы бармый. Үзе гомере буе хезмәт иткән идеалларына, намусына хыянәт итмәгән Һ. Максуди соңгы көннәренә кадәр шуңа куанып яши.

1938 елның 10 гыйнваренда Һ. Максудига ачылган «Эш», сәламәтлеге бик начарлану сәбәпле, туктатыла һәм 1939 елның 2 февраленда ябыла. Аңа, шулай итеп, хөкем карары чыгарылмыйча кала. Төрмәдән чыккач, Һ. Максуди инде озак яши алмый, ул 1941 елның 28 июнендә вафат була. Кабере Яңа Бистә зиратында, Тукай кабере белән янәшә. Татар вакытлы матбугатында аның үлеме турында хәбәр булмый. Әмма 1941 елның көз башында Төркиянең Әнкара шәһәрендә чыга торган «Яңа сабах» гәзитендә Г. Баттал Таймасның (1941 ел 17 декабрь) Һ. Максудига багышланган мәкаләсе чыга. Анда: «Һ. Максуди төрки дөньяның танылган фикер адәмедер. Ул Әнкара хокук факультеты профессоры Садри Максуди Арсалның олы туганыдыр, һәм С. Максудиның бу дәрәҗәгә җитүендә олы туганының да роле, тәэсире зурдыр» дигән юллар да бар. «Җөмһүрият» гәзитенең октябрь ае санында исә М. Фәйзи-Тогайның Һ. Максудиның үлеменә багышланган мәкалә-некрологы чыга. Анда мәрхүмнең татар мәгарифе һәм мәдәнияте өлкәсендәге эшчәнлегенә зур бәя бирелә һәм: «Төрки телнең бөек хадимнәреннән булган галим Һ. Максудиның

эшчәнлеге төрки мохиттә, шөбһәсез, көчле бер тәэсир яндырмыштыр», диелә.

Октябрь инкыйлабына кадәрге чорда татар халкы тарихында иң күренекле, абруйлы шәхесләрдән булган һәм соңыннан халык дошманына әйләндерелгән, эшләгән эшләре генә түгел, исеме дә халык хәтереннән җуелдырылган олуг шәхес – Әхмәдһади Низаметдин улы Максудов 1995 елда РФның 18.10.91 елгы «Сәяси репрессия корбаннарын реаблитацияләү» турындагы законы нигезендә гаепсез дип табыла һәм аклана.

Фәридә Гаффарова,

тарих фәннәре кандидаты,

Чыганак: sombel.ru

Фән

Мәзһәбкә ияру кирәкме?

بسم الله الرحمن الرحيم

اَلْحَمْدُ للهِ الَّذِي هَدَينَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَينَا اللهُ لَقَدْ جَاءَتْ رُسُلُ رَبِّنَا بِالْحَقِّ

صَلُّوا عَلَي رَسُولِنَا مُحَمَّدٍ: اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَي سَيِّدِنَا وَنَبِيِّنَا مُحَمَّدٍ وَعَلَي آلِ سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ

صَلُّوا عَلَي شَفِيعِ ذُنُوبِنَا مُحَمَّدٍ: اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَي سَيِّدِنَا وَنَبِيِّنَا مُحَمَّدٍ وَعَلَي آلِ سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ

صَلُّوا عَلَي طَبِيبِ قُلُوبِنَا مُحَمَّدٍ: اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَي سَيِّدِنَا وَنَبِيِّنَا مُحَمَّدٍ وَعَلَي آلِ سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ

Дүрт сөнни мәзһәбнең берсенә ияру – мөҗтәһид-мотлак булмаган һәр мөселман өчен вәҗиб. Бар дүрт мәзһәб тә дөрес. Мәзһәбкә иягән кеше Коръән Кәрим һәм Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) сөннәтенә иягән була, һәм аларны ялгыш аңлаудан саклана, чөнки дүрт имам да гыйлемне турыдан-туры сәхабәләрдән, йә тәбигыйннәрдән, йә тәбга-тәбигыйннәрдән алган. Кеше кайсы гына мәзһәбкә иярсә дә, аны тулысы белән тотарга, ягъни аның бар хөкемнәрен үтәргә тиеш. Мәзһәбләрне катнаштырырга, буташтырырга, ягъни бер төрле хөкемнәрне – бер мәзһәбтән, башка мәсьәләләрдә икенче мәзһәб хөкемнәрен алырга ярамый. Шулай ук бер мәзһәб икенчесеннән яхшырак

яки начаррак дип уйларга кирәкми. Ә бер мәзһәбкә дә иярмәү – ислам шәригатенә янаган иң куркыныч бидгатьләрнең берсе.

أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا أَطِيعُوا اللَّهَ وَأَطِيعُوا الرَّسُولَ وَأُولِي الْأَمْرِ مِنكُمْ

«Ий мөэминнәр! Аллаһка итагать итегез һәм Расүлгә итагать итегез! Шулай ук үзегездән булган Коръән белән гамәл кылып, Коръән дәлилләре белән әмер итүче дини хуҗаларыгызга да итагать итегез!»

«Нисә / Хатыннар», 4:59

وَإِذَا جَاءَهُمْ أَمْرٌ مِّنَ الْأَمْنِ أَوِ الْخَوْفِ أَذَاعُوا بِهِ ۖ وَلَوْ رَدُّوهُ إِلَى الرَّسُولِ وَإِلَىٰ أُولِي الْأَمْرِ مِنْهُمْ لَعَلِمَهُ الَّذِينَ يَسْتَنبِطُونَهُ مِنْهُمْ

«Әгәр монафикъларга сугыш сәфәрендә булган мөселманнарның сугышка әзерләнмичә тыныч торулары, яки дошман гаскәреннән курыккан хәбәрләре килсә, ул хәбәрне шатланып, халык арасына фаш итәләр мөселманнар күңеленә курку салыр өчен. Әгәр ул хәбәрне расүлгә һәм мөселманнарның әмирләренә генә әйтсәләр иде, ул вакытта ул хәбәрне расүл һәм әмирләр генә белеп, тиешсез кешеләргә фаш булмас иде».

«Нисә / Хатыннар», 4:83

وَمَا كَانَ الْمُؤْمِنُونَ لِيَنفِرُوا كَافَّةً ۚ فَلَوْلَا نَفَرَ مِن كُلِّ فِرْقَةٍ مِّنْهُمْ طَائِفَةٌ لِّيَتَفَقَّهُوا فِي الدِّينِ وَلِيُنذِرُوا قَوْمَهُمْ إِذَا رَجَعُوا إِلَيْهِمْ لَعَلَّهُمْ يَحْذَرُونَ

«Мөэминнәрнең барчасының да сугышка чыгулары дөрес түгел. Һәрбер фиркадән бер таифә чыксын, (калганнары) дин белемен өйрәнү вә өйрәтү өчен, сугышка киткән кешеләр кайт-

кач аларга өйрәтү өчен. Шаять, сугышка киткән кешеләр дә вәгазьләнерләр иде».

«Тәүбә», 9:122

فَاسْأَلُوا أَهْلَ الذِّكْرِ إِن كُنتُمْ لَا تَعْلَمُونَ

«Белмәгән һәрнәрсәгезне белгән кешеләрдән сорагыз!»

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:43

عَنْ حَذَيْفَةَ، قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ: «اقْتَدُوا بِاللذِينَ مِنْ بَعْدِي أبي بَكْرٍ، وَعُمَرَ»

Хөзәйфә (Аллаһ аннан разый булсын) тапшыра: Расүлүллаһ (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Арагызда күпме булачагымны белмим, шуңа күрә миннән соң (булганнарга) иярегез: Әбү Бәкер һәм Гомәр», – дип әйткән.[1]

Коръән Кәрим һәм Сөннәттә шәригатьнең анык кануннары булып киткән әмерләр бар. Алар ышанычлы чыганаклар белән дәлилләнгән һәм аларга карата бернинди шик-шөбһә, фикер каршылыклары юк. Мисал өчен, зинаның тыелган булуы, биш вакыт фарыз намаз, ураза, зәкәт, хаҗ h. б. Һәр кеше бу әмерләрне Коръәннән һәм хәдисләрдән мөстәкыйль рәвештә белә ала, шул сәбәпле бу мәсьәләләрдә иҗтиһадка ихтыяҗ юк.

Әмма Коръән һәм Сөннәттә икенче төр әмерләр дә бар. Аларны аңлауда кыенлыклар туа, чөнки бер үк мәсьәләдә ике төрле күрсәтмә булырга мөмкин, һәм аларның икесе дә ышанычлы чыганаклар белән раслана – Коръән һәм хәдисләр. Мисал өчен, Аллаһы Тәгалә Коръәндә:

وَالْمُطَلَّقَاتُ يَتَرَبَّصْنَ بِأَنفُسِهِنَّ ثَلَاثَةَ قُرُوءٍ

[1] «Җәмигут-Тирмизи» № 3662

«Талак кылынган хатыннар икенче иргә барганчы, өч күрем үткәнче көтәрләр», – дип әйтә.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:228

Аятьтәге «куруъ» сүзе ике мәгънәгә ия. Беренчесе – күрем вакыты, ә икенчесе – аннан чистарыну. Без бу сүзнең кайсы мәгънәсен кулланырга тиешбез соң, дигән сорау туа.

Яки, бер хәдистә болай диелгән:

عَنْ عُبَادَةَ بْنِ الصَّامِتِ: أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ ﷺ قَالَ: «لاَ صَلاَةَ لِمَنْ لَمْ يَقْرَأْ بِفَاتِحَةِ الكِتَابِ».

Гобәдә бине Әс-Самиттән тапшырыла: Расүлүллаһ (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Фәтихә» сүрәсен укымаучының намазы юк», – дигән.[1]

Беренче карашка, бу хәдис «Фәтихә» сүрәсен уку имамга да, аңа оеп укучыларга да, аерым (ялгыз) укучыларга да фарыз икәнен аңлата. Шул ук вакытта башка хәдистә болай диелгән:

عَنْ جَابِرٍ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ: «مَنْ كَانَ لَهُ إِمَامٌ، فَقِرَاءَةُ الْإِمَامِ لَهُ قِرَاءَةٌ».

Җәбир Расүлүллаһның (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) болай дип әйтүен тапшыра: «Намазны имамга оеп укучының кыйраәте (Коръән укуы) булып имамның кыйраәте тора».[2]

Бу хәдистә имамга оеп укучыга үзенә берни укымаска күрсәтмә бар. Шушы хәдисләрдә фикер каршылыгы тудырмас өчен, ике юл бар.

Беренчесе – беренче хәдисне төп дип игълан итәргә, шул рәвешле, аңа таянып гамәл кылырга кирәк, чөнки икенче хәдистә Коръән уку

1 «Сахих Әл-Бохари» № 756

2 «Сүнәнү Ибне Мәҗәһ» № 850

дигәндә күз уңында «Фәтихә» сүрәсе түгел, ә «Фәтихә»дән соң укыла торган аятьләр тотыла.

Икенче юл – төп дип икенче хәдисне игълан итәргә, шул рәвешле, аңа таянып гамәл кылырга кирәк, чөнки беренче хәдистә «Фәтихә»не уку әмере имам һәм намазны аерым укучыга карый, ә имамга оеп укучыга карамый. Бу очракта безгә нишләргә?

Коръәнне һәм хәдисләрне тәфсирләгәндә шушындый күпсанлы сораулар туа. Бу очракта безнең ике юл бар: үзебезгә бер якны сайларга һәм үзебезнең гыйлем вә акылыбызга таянып гамәл кылырга; яки икенче вариант: безгә караганда күпкә гыйлемлерәк мөэминнәр элек бу очракта ни рәвешле гамәл кылганнарын карарга. Ә аннан соң үзебез күбрәк ышанган мөҗтәһид галим фикерен кулланырга. Соңгы вариант «тәкълид» («кемгәдер ияруү») дип атала.

Уйлап карасак, беренче юлның бик куркыныч, ялгышлыкларга китерергә мөмкин икәнлегендә шик юк. Надан кеше генә үзенең гыйлемен һәм тәкъвалыгын мәзһәб имамнарыныкына тиң дип саный ала. Беренчедән, мөҗтәһид имамнар Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) яшәгән вакытка якын дәвердә яшәгәннәр. Шул сәбәпле, безгә караганда, аларга Изге Коръәнне, ул иңдерелгәндәге вәзгыятьне һәм Сөннәтне аңлау җиңелрәк булган. Икенчедән, безнең белемнәребез һәм хәтер сәләтебезне Аллаһы Тәгалә ул кешеләргә биргән белем һәм хәтер сәләте белән һич чагыштырырга ярамый. Өченчедән, Аллаһы Тәгалә Коръәнне аңлауны һәм аның хакыйкатен теләсә кайсы вакытта гөнаһ кылырга сәләтле кешеләргә ачмый. Коръәннең һәм хәдисләрнең мәгънәсен дөрес аңлау өчен, гыйлемнән кала зур тәкъвалыкка ия булырга кирәк. Әгәр без үзебезнең тәкъвалыкны дүрт мәзһәб имамнары тәкъвалыгы белән чагыштырсак, җир белән күк арасындагы кебек аерманы күрербез.

Ислам шәригатенең принципларын билгеләгән галимнәр тәкълидне болай аңлата:

التَقْلِيدُ: عِبَارَةٌ عَنْ قَبُولِ قَوْلِ الغَيْرِ بِلَا حُجَّةٍ وَلاَ دَلِيلٍ

«Тәкълид – ул дәлилләр таләп итмичә, мөҗтәһид имам сүзләре буенча гамәл кылу».

Бу аңлатмага ишарәләп, кайбер надан кешеләр дәлилләрсез кемнеңдер сүзләренә ияру һәм аларны хакыйкать дип кабул итүне ширек дип атый башлады.

Әмма тәкълиднең китерелгән аңлатмасына күз салсаң, бу бәхәсләр үзләреннән үзе юкка чыга. Мөҗтәһидләр кануннар кабул итми һәм яңа шәригать алып килми, алар фәкать Расүлебез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) керткән шәригатьне аңлата. Моңа безнең Коръән һәм Сөннәттә анык әмерләр булган мәсьәләләрдә ниндидер имамга иярмәвебез дәлил булып тора. Без мөҗтәһидләргә Изге Коръән һәм хәдисләрне тәфсирләгәндә кыенлыклар һәм икеләнүләр туса, яки бер үк мәсьәләдә Коръән һәм хәдисләрдә төрле күрсәтмәләр булган очракларда гына мөрәҗәгать итәбез.

Тәкълиднең билгеләмәсендәге «дәлилләр таләп итмичә» дигән сүзләр безне ялгышлыкка төшерергә, мөҗтәһидкә баш иргә кирәк дигән фикерләр тудырырга тиеш түгел. Дөреслектә без, имамның үз сүзләренә Коръән һәм Сөннәттән алган көчле дәлилләре барлыгына ышануыбыз сәбәпле, аңа мөрәҗәгать итәбез. Аның дәлилләренең дөреслеген аңлар өчен җитәрлек мөмкинчелекләребез булмаганга күрә генә без аннан дәлилләр таләп итмибез. Шул рәвешле, мөҗтәһид сүзләре буенча фикер йөртү өчен, аларның аңлатмаларын белү мәҗбүри түгел, чөнки кайбер очракларда без аларны аңлыйбыз, ә күпчелек вакытта – юк.

Тәкълид ике төрле була. Тәкълиднең беренче төре – ул төрле сораларда, берсен генә аерып чыгармый, төрле мөҗтәһид имамнарга ияру. Тәкълиднең мондый төре «тәкълид мотлак» яки «тәкълид гайр шәхси» дип атала.

Тәкълиднең икенче төре – имамнардан берсен сайлап, бар мәсьәләләрдә дә аңа ияру. Тәкълиднең мондый төре «тәкълид шәхси» дип атала.

Ике төр тәкълиднең дә мәгънәсе – төп чыганаклардан Изге Коръән һәм Сөннәтнең әмерләрен мөстәкыйль рәвештә аңлый алмаган кешенең белеме һәм тәкъвалыгы аркасында ышанычлы дип саналган кешенең фикерләренә ияру.

Имамнарга ияру кирәклеге Коръән һәм хәдисләр белән дәлилләнә.

أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا أَطِيعُوا اللَّهَ وَأَطِيعُوا الرَّسُولَ وَأُولِي الْأَمْرِ مِنكُمْ

«Ий мөэминнәр! Аллаһка итагать итегез һәм Расүлгә итагать итегез! Шулай ук үзегездән булган Коръән белән гамәл кылып, Коръән дәлилләре белән әмер итүче дини хуҗаларыгызга да итагать итегез!»

«Нисә / Хатыннар», 4:59

Бу аятьтә «әмер итүче хуҗалар»га буйсынырга кушылган. Кайбер мөфәссирләр «әмер итүче хуҗалар» дип тәрҗемә иткән, әмма галимнәрнең күпчелеге сүз мөҗтәһид галимнәр хакында баруын әйтә. Шундый ук тәфсирне Габдуллаһ бине Габбас, Җәбир бине Габдуллаһ, Хәсән Әл-Басри, Гата бине Әби Рабаха, Гата бине Әс-Сайибә, Әбүл Галия һ.б. тапшыра. Шулай ук Ибн Җәрир һәм имам Рази тәфсирләрендә дә бу фикергә өстенлек бирелә. Бу аңлатма буенча, әлеге аять тәкълиднең ачык дәлиле булып тора, чөнки Аллаһка һәм Аның расүленә буйсынудан тыш, мөҗтәһид имамнарга да буйсынырга әмер ителгән. Димәк, аять шуны аңлата: Аллаһка һәм Аның расүленә буйсынырга телисең икән, галимнәргә буйсын.

وَإِذَا جَاءَهُمْ أَمْرٌ مِّنَ الْأَمْنِ أَوِ الْخَوْفِ أَذَاعُوا بِهِ ۖ وَلَوْ رَدُّوهُ إِلَى الرَّسُولِ وَإِلَىٰ أُولِي الْأَمْرِ مِنْهُمْ لَعَلِمَهُ الَّذِينَ يَسْتَنبِطُونَهُ مِنْهُمْ ۗ وَلَوْلَا فَضْلُ اللَّهِ عَلَيْكُمْ وَرَحْمَتُهُ لَاتَّبَعْتُمُ الشَّيْطَانَ إِلَّا قَلِيلًا

«Әгәр монафикъларга сугыш сәфәрендә булган мөселманнарның сугышка әзерләнмичә тыныч торулары, яки дошман гаскәреннән курыккан хәбәрләре килсә, ул хәбәрне шатланып, халык арасына фаш итәләр мөселманнар күңеленә курку салыр өчен. Әгәр ул хәбәрне расүлгә һәм мөселманнарның әмирләренә генә әйтсәләр иде, ул вакытта ул хәбәрне расүл һәм әмирләр генә белеп, тиешсез кешеләргә фаш булмас иде».

«Нисә / Хатыннар», 4:83

Бу аятьнең иңдерелү тарихы мондый: сугыш вакытында кайбер монафикълар төрле имеш-мимешләр тарата башлый, һәм кайбер мөселманнар аларга ышанып, башкаларга да сөйли. Шул рәвешле шәһәр буенча ялган хәбәр таралып, тәртипсезлекләр башлана. Изге Коръәндә Аллаһы Тәгалә мөселманнарга, шушындый сүзләрне таратыр алдыннан, хакыйкатьне белер һәм аның буенча гамәл кылыр өчен, галим сәхабәләргә мөрәҗәгать итәргә боера.

Бу аять аерым бер очракка караса да, Коръәнне тәфсирләүдә гомум кабул ителгән кагыйдә бар: игътибарга иңдерелүнең аерым сәбәбе генә түгел, ә гомуми мәгънә алына. Димәк, бу аятьтә тәкълидкә күрсәтмә бар. Шул сәбәпле, «Әл-Кәбир» тәфсирендә имам Рази, «Әхкәмүл-Коръән» тәфсирендә имам Әбү Бәкер бу аятьне шәригатьтә тәкълиднең рөхсәт ителүенә дәлил блуарак китерә.

وَمَا كَانَ الْمُؤْمِنُونَ لِيَنفِرُوا كَافَّةً ۚ فَلَوْلَا نَفَرَ مِن كُلِّ فِرْقَةٍ مِّنْهُمْ طَائِفَةٌ لِّيَتَفَقَّهُوا فِي الدِّينِ وَلِيُنذِرُوا قَوْمَهُمْ إِذَا رَجَعُوا إِلَيْهِمْ لَعَلَّهُمْ يَحْذَرُونَ

«Мөэминнәрнең барчасының да сугышка чыгулары дөрес түгел. Һәрбер фиркадән бер таифә чыксын, (калганнары) дин белемен өйрәнү вә өйрәтү өчен, сугышка киткән кешеләр кайткач аларга өйрәтү өчен. Шаять, сугышка киткән кешеләр дә вәгазьләнерләр иде».

«Тәүбә», 9:122

Бу аятьтә Аллаһы Тәгалә мөселманнарга барысына да бер үк вакытта бер эш белән шөгыльләнмәскә куша. Кайберәүләр Аллаһ юлында булсын, башкалар дини гыйлем эстәсен. Аннан соң, гыйлем алучылар белемнәрен Аллаһ юлында булучыларга тапшырсыннар. Бу очракта беренчеләр гыйлем алучыларны тыңларга һәм аларга иярергә тиеш, ә бу инде тәкълид булып тора.

فَاسْأَلُوا أَهْلَ الذِّكْرِ إِن كُنتُمْ لَا تَعْلَمُونَ

«Белмәгән һәрнәрсәгезне белгән кешеләрдән сорагыз!»

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:43

Бу аятьтә белмәүчеләрнең белүчеләрдән сорарга тиешлеге хәбәр ителә. Әүвәл бу аять Китап әһелләре (христиан һәм яһүдиләр) хакында иңдерелгән, әмма гомуми мәгънәне алу кагыйдәсе буенча, аятьтән белмәүченең галимгә мөрәҗәгать итәргә тиешлеге аңлашыла, ә бу тәкълид була.

«Җәмигут-Тирмизи», «Сүнәнү Ибне Мәҗәһ», «Мөснәд Әхмәд» хәдисләр җыентыкларында мондый хәдис китерелә:

عَنْ حُذَيْفَةَ، قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللهِ ﷺ: «اقْتَدُوا بِاللذِينَ مِنْ بَعْدِي أَبِي بَكْرٍ، وَعُمَرَ»

Хөзәйфә (Аллаһ аннан разый булсын) тапшыра: Расүлүллаһ (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Арагызда күпме булачагымны белмим, шуңа күрә миннән соң (булганнарга) иярегез: Әбү Бәкер һәм Гомәр», – дип әйткән.[1]

Бу хәдистә иярергә боерылган һәм бу ияру кемгәдер оештыру эшләрендә буйсынуны түгел, ә дини эшләрдә иярүне белдерә. «Әл-Бохари» хәдисләр җыентыгының намаз китабында кайбер сәхабәләрнең җәмәгать намазына соңлап килә башлаулары турында хәбәр ителә. Шуңа Расүлүллаһ аларга намазны беренче рәтләрдә укырга кушкан һәм: «Миңа иярегез, ә калганнар сезгә иярсен», – дип әйткән.

Бу хәдиснең мәгънәләренең берсе – беренче рәтләрдәге кешеләрнең, Пәйгамбәребезгә карап, аңа оюларында. Ә икенчесе – сәхабәләрнең намазны Пәйгамбәрдән яхшылап өйрәнеп калулары, чөнки киләчәк буыннар намазны алардан өйрәнәчәк. Хафиз бине Хәҗәр Әл-Гаскаләни үзенең «Фәтхүл-Бәри» китабында бу хәдиснең шәрехендә болай дип яза:

«Бу хәдис:

وَقِيلَ مَعْنَاهُ تَعَلَّمُوا مِنِّي أَحْكَامَ الشَّرِيعَةِ وَلْيَتَعَلَّمْ مِنْكُمُ التَّابِعُونَ بَعْدَكُمْ وَكَذَلِكَ أَتْبَاعُهُمْ إِلَى انْقِرَاضِ الدُّنْيَا

«Сез шәригать хөкемнәрен миннән өйрәнәсез, ә сездән соң килүчеләр сездән өйрәнсен, шул ук рәвешле алардан соң килүчеләр, һәм шул рәвешле Кыямәт көненәчә», – дигәнне аңлата».[2]

---

1 «Җәмигут-Тирмизи» № 3662

2 «Фәтхүл-Бәри», т.2, 250 б.

«Мишкатүл-мәсәбих»[1] китабының «Китабүл-гыйльм» дигән өченче бүлегендә имам Әл-Бәйһакыйдан «Әл-Мәдхәл» китабында болар тапшырыла: Ибраһим бине Габдрахман Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) болай дип әйткәнен тапшыра:

وَعَنْ إِبْرَاهِيمَ بْنِ عَبْدِ الرَّحْمَنِ الْعُذْرِيِّ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ: «يَحْمِلُ هَذَا الْعِلْمَ مِنْ كُلِّ خَلَفٍ عُدُولُهُ يَنْفُونَ عَنْهُ تَحْرِيفَ الْغَالِينَ وَانْتِحَالَ الْمُبْطِلِينَ وَتَأْوِيلَ الْجَاهِلِين»

«Бу гыйлемнәр (Изге Коръән һәм хәдис) киләчәк һәр буыннарның лаеклы вәкилләрендә булачак. Вә алар шул гыйлем белән кирәгеннән артыкны кертүчеләрнең өстәмәләрен, ялганчыларның уйдырмаларын һәм наданнарның аңлатмаларын юкка чыгарачак».[2]

Бу хәдистә надан кешеләрнең ялгыш аңлатмалары хөкем ителә һәм аларны кире кагу галимнәрнең бурычы икәне әйтелә.

Шул рәвешле, Коръән һәм хәдис мәсьәләләрендә мөҗтәһид дәрәҗәсенә ия булмаган кешеләр, үзләренчә аңлап, Коръән һәм хәдисләрне тәфсирләргә тиеш түгел. Дин мәсьәләләрен белер өчен, аларга галимнәргә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бу тәкълид була.

Монда шуңа да игътибар итәргә кирәк: Коръән һәм хәдисләрне бераз гыйлеме булган кеше дә аңлатырга тырышырга мөмкин, әмма бу хәдистә ул да надан дип аталган. Берникадәр гыйлемгә ия булуның Коръән һәм хәдисләрдән мөстәкыйль рәвештә хөкемнәр чыгарырга җитмәве аңлашыла.

Сәхабәләр вакытында иҗтиһад һәм тәкълидкә мисаллар күп очрый. Коръән һәм хәдисләрдән үзләре хөкемнәр чыгара алмаган сәхабәләр галим сәхабәләргә мөрәҗәгать иткән һәм алардан дини мәсьәләләрне өйрәнгән. Галим сәхабәләр кайвакыт дәлилләр белән, ә кайвакыт дәлилләрне китер-

1 «Мишкатүл-мәсәбих», т.1, 36 б.

2 «Мишкатүл-мәсәбих» № 248

ми җавап биргән. Әлбәттә, сәхабәләр заманында шәхси тәкълидкә генә иярү лазем булмаган, ә ике тәкълид тә кулланылган: шәхси һәм мотлак тәкълид. Ул вакытта мотлак тәкълидкә сансыз мисаллар табарга мөмкин. Һәрбер факиһ (галим сәхабә) фәтваны үзенең әйләнә-тирәсендәгеләр өчен биргән, һәм калганнар аңа иярген. Шуңа күрә «Әгъләмүл мүәффин» китабында: «Расүлүллаһның сәхабәләре арасында 130дан артык ир-ат һәм хатын-кыз фәтва бирүчеләр булган», – диелә.

Ул сәхабәләрнең бар фәтвалары да мотлак тәкълид үрнәге булып тора. Кешеләр аларның сүзләре буенча гамәл генә кылмый, ә хәтта аларның гамәлләрен дә кабатлаган, бу күпсанлы хәдисләрдән билгеле. Мисал өчен, «Әл-Мөвәттә лил-имам Мәлик» китабында мондый хәдис китерелә: Гомәр Талһәнең ихрам хәлендә буяуга манылган кием кигәнен күреп, аны шелтәли. Соңгысы: «Бу буяуда исле май (хушбуй) юк», – дип җавап бирә. Гомәр аңа:

فَقَالَ عُمَرُ: إِنَّكُمْ أَيُّهَا الرَّهْطُ أَئِمَّةٌ يَقْتَدِي بِكُمُ النَّاسُ. فَلَوْ أَنَّ رَجُلاً جَاهِلاً رَأَى هذَا الثَّوْبَ، لَقَالَ: إِنَّ طَلْحَةَ بْنَ عُبَيْدِ اللهِ قَدْ كَانَ يَلْبَسُ الثِّيَابَ الْمُصَبَّغَةَ فِي الْإِحْرَامِ. فَلاَ تَلْبَسُوا، أَيُّهَا الرَّهْطُ، شَيْئاً مِنْ هذِهِ الثِّيَابِ الْمُصَبَّغَةِ

«Сез имамнар булып торасыз, сезгә кешеләр иярә. Әгәр бер җаһил кеше бу киемне күрсә, һичшиксез, Талһә бине Габдуллаһны ихрам халәтендә буялы киемдә күргәнен сөйләячәк. Шуңа сезгә мондый киемне киергә кирәкми», – дип әйтә.[1]

Сәхабәләр чорында шәхси тәкълидкә мисаллар күп була. Аларның кайберләре түбәндә китерелер.

[1] «ӘлМүвәттә лил-имами Мәлик» № 1164

«Сахих Әл-Бохари»[1] җыентыгының «Китәбүл-хаҗ» бүлегендә Гыйкримадан китерелә:

عَنْ عِكْرِمَةَ، أَنَّ أَهْلَ المَدِينَةِ سَأَلُوا ابْنَ عَبَّاسٍ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُمَا، عَنِ امْرَأَةٍ طَافَتْ ثُمَّ حَاضَتْ، قَالَ لَهُمْ: تَنْفِرُ، قَالُوا: لاَ نَأْخُذُ بِقَوْلِكَ وَنَدَعُ قَوْلَ زَيْدٍ قَالَ: إِذَا قَدِمْتُمُ المَدِينَةَ فَسَلُوا، فَقَدِمُوا المَدِينَةَ، فَسَأَلُوا، فَكَانَ فِيمَنْ سَأَلُوا أُمُّ سُلَيْمٍ، فَذَكَرَتْ حَدِيثَ صَفِيَّةَ رَوَاهُ خَالِدٌ، وَقَتَادَةُ، عَنْ عِكْرِمَةَ

«Ибн Габбастан тәваф кылганнан соң күреме башланган хатын-кыз хакында сорыйлар. Ул: «Аңа китәргә кирәк», – дип җавап кайтара. Сораучылар: «Без синең фикереңне түгел, Зәйднекен кабул итәбез», – диләр».[2]

Шушы ук вакыйга «Мөгъҗим Исмәгыйли»дә Габделваһhаб Әс-Сәкафидән китерелә, монда Мәдинә кешеләренең сүзләре өстәлгән: «Син безгә фәтва бирәсеңме, юкмы – безгә аерма юк. Зәйд аңа китәргә кирәкми, диде».

Ә Әбү Давытның «Сүнән»ендә аларның сүзләре болай китерелә: «Йә Ибн Габбас, без сиңа иярмибез ,син Зәйдкә каршы киләсең».

Бу очрактан күренгәнчә, әлеге кешеләр Зәйдкә иярген (тәкълид шәхси), шуңа күрә хәтта ибн Габбас кебек сәхабәнең дә фәтвасын кабул итмәгәннәр. Һәм аның фәтвасыннан баш тарту өчен, алар, башка сәбәпләр атап тормыйча, аның Зәйднең фәтвасына туры килмәвен генә әйтә. Ибн Габбас та аларны шәхси тәкълид кылганнары өчен тәнкыйтьләми. Киресенчә, ул аларга бу сорауны Өмме Сүләймнән ачыкларга, аннан соң кабат Зәйдкә мөрәҗәгать итәргә киңәш итә. Кешеләр ул кушканча эшли. «Сахих Мөслим»дә китерелгәнчә, Зәйд, кабат хәдисләргә мөрәҗәгать

1 «Сахих Әл-Бохари» т. 1, 237 б., №1671

2 «Сахих Әл-Бохари» №1671

итеп, үзенең фәтвасын кире ала. Ничек кенә булмасын, бу мисалдан Мәдинәләләрнең Зәйдкә шәхси тәкълид кылулары аңлашыла.

«Сахих Бохари» хәдисләр җыентыгы «Китаб әл-фәраид»ының «Әл-Мирас» бүлегендә Хөзәйил бине Шәрабил кайбер кешеләрнең Әбү Муса Әшгаригә бер сорау бирүләрен тапшыра. Ул аларга җавап бирә, әмма: «Шулай ук бу хакта Габдуллаһ бине Мәсгудтән сорагыз», – дип өсти. Бу кешеләр шушы ук сорауны Габдуллаһ бине Мәсгудкә бирә һәм Әбү Муса Әшгаринең җавабын да әйтә. Габдуллаһ бине Мәсгуд биргән фәтва Әбү Муса Әшгаринең фәтвасына каршы була. Аңа моны хәбәр иткәннән соң, ул: «Арагызда бу бөек галим булганда, миннән сорамагыз», – дип әйтә. Әхмәднең «Мөснәд»ендә[1] бу хәдис: «Арагызда бу бөек галим булганда, миннән берни дә сорамагыз», – сүзләре белән китерелә. Монда Әбү Муса Әшгари кешеләргә бар сорау белән бары Габдуллаһ бине Мәсгудкә генә мөрәҗәгать итәргә киңәш итә. Бу шәхси тәкълид дип атала да.

«Әбү Давыт» һәм «Тирмизи» китапларында Мөгаз бине Җәбәл тарихы китерелә. Расүлүллаһ (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) Мөгазны шәригатьнең нигезләрен аңлатырга Йәмәнгә җибәрә. Мөгаз бине Җәбәл анда хәлифә буларак кына түгел, ә казый һәм мөфти буларак та билгеләнә. Йәмән халкының Мөгазгә иярүдән кала башка чаралары булмаганлыктан, алар шәхси тәкълид кылалар. Кайберәүләр Мөгаз мөфти булмаган, казый булган, диләр. Бу дөрес түгел. «Сахих Бохари»ның[2] «Китәбүл-фәраид» өлешенең «Әсвад» бүлегендә: «Мөгаз бине Җәбәл Йәмәнгә әмир яки остаз вазифасында килде. Кешеләр аннан бер адәмнең үлгәннән соң калган кызы һәм сеңлесе хакында сорыйлар. Ул мирасның ярты өлешен кызына бирергә куша», – диелә. Бу очракта ул фәтвасына дәлилләр китерми, һәм кешеләр аны фәкать тәкълид аркасында кабул итә.

Димәк, сәхабәләр заманында мотлак тәкълид һәм шәхси тәкълидкә мисаллар күп. Дәреслектә, ике төр тәкълид тә рөхсәт ителгән булган, һәм

1 «Мөснәдү Әхмәд» т. 1, 464 б.

2 «Сахих Бохари» т. 2, 297 б.

Исламның беренче чорында мөселманнар аларның икесен дә кабул иткән. Әмма соңрак, бер тәртип булдыру максатыннан, галимнәр тәкълиднең бер төрен генә – шәхси тәкълидне генә фарыз калдыра.

Бу карарның хикмәтен аңлар өчен, Изге Коръәндәге әйтелгәнчә, үзеңнең теләкләреңә ияруү куркыныч авыру икәнлеген истә тотарга кирәк. Әмма теләкләргә буйсынуның бер төре – ул гөнаһның гөнаһ икәнен танып кылу, ә икенче һәм иң куркыныч төре – ул гөнаһ кылып та, аның гөнаһ икәнлеген танымау. Соңгысы гөнаһ кылган кеше оялмаганга, хурланмаганга куркыныч булып тора.

Элек кешеләр намуслырак булган, үз теләкләренә буйсыну куркынычы булмаган. Соңрак кешеләр үзгәреп, намуслылык та кими. Мөселман факиһлары мотлак тәкълидкә рөхсәт булса, кешеләрнең, үз теләкләренә буйсынып, төрле имамнардан үзләре өчен җиңелрәк, уңайлырак булган әйберләрне сайлап алачакларын аңлый. Ә бу зур ялгышлык булып тора, һәм беркем дә моның Исламга каршы килүендә шикләнми.

Хәтта ялгыш агымнарның берсенең билгеле идеологы Ибне Тәймия дә, үзенең фәтваларында кешенең, үз теләкләреннән чыгып, кайвакыт бер имамга, ә кайвакыт икенчесенә ияруен тәнкыйтьли.

Әгәр кешеләргә теләсә кайсы мөҗтәһиднең үзеңә ошаган фикерен кулланырга рөхсәт ителсә, дөреслектә, дин уенчыкка әйләнәчәк, чөнки күп кенә мөҗтәһидләрдә нәфескә буйсынган аерым фикерләр очрый. Мисал өчен, Габдуллаһ бине Җәгъфәрнең музыканы рөхсәт итүе, Касыйм бине Мөхәммәднең сурәт төшерергә рөхсәт итүен хәбәр итәләр. Имам Әгъмәш фикеренчә, ураза кояш чыкканнан соң башлана. Ибн Хәзәмә фикеренчә, әгәр ир-атның хатын-кызга өйләнү нияте бар икән, аңа хатын-кызны хәтта ялангач хәлдә дә күрергә рөхсәт ителә. Гата бине Әби Рабәх гает җомга көненә туры килсә, бу көнне җомга һәм өйлә намазлары фарыз булудан туктый, дип әйткән.

Ягъни, кемдер шушындый фикерләрне эзләп утырса, аннан соң аларның барысын тормышта куллана башласа, шайтан барлыкка китергән дин килеп чыгачак.

Мотлак тәкълид булганда нәфескә ияруү куркычы көчле булганлыктан, Һиҗрәтнең IV гасырында галимнәр шәхси тәкълидне вәҗиб итә. Шах Вәлиуллаһ «Хүҗәтүллаһи бәлига» хезмәтендә галимнәрнең бу карарын искә алып: «Һәм ул заманада бу кирәк иде», – дип яза. Аны сәхабәләр заманында вәҗиб булмаган әйбер хәзер ничек вәҗиб була ала инде, дип тәнкыйтьли башлыйлар. Бу сорауга җавап итеп ул «Әл-Инсаф фи бәян сәбәбил-ихтиләф» китабында болай дип яза: «Вәҗибнең ике төре бар:

1. Вәҗиб лигайниһи – Расүлүллаһ (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) вакытында вәҗиб булган, аңа үзгәрешләр кертергә ярамый.

2. Вәҗиб лигайриһи – аңа өстәмәләр, үзгәртүләр кертергә ярый».

Әгәр кешенең максаты булып ниндидер вәҗибне үтәү торса, әмма аерым бер вакытта аны бер рәвешле башкарсалар, ә башкача башкару мөмкинчелеге булмаса, бу ысул да вәҗиб була. Мисал өчен, Пәйгамбәребез вакытында хәдисләрне саклау вәҗиб була, чөнки алар ятлау нәтиҗәсендә сакланып килә. Әмма соңрак, хафизләрнең хәтеренә генә ышану мөмкин булмагач, хәдисләрне саклауның бердәнбер ысулы – язма ысул гына кала. Шул сәбәпле хәдисләрне язу вәҗиб була. Шул ук рәвешле сәхабәләр һәм тәбигыйннәр заманында гади кеше өчен мотлак тәкълид вәҗиб була, әмма бу куркынычлыклар тудыра башлагач, шәхси тәкълидне генә вәҗиб итеп билгелиләр. Шуңа күрә галимнәр: «Шәхси тәкълид вәҗиб булып шәригать кушканга күрә тормый, ә тәртип өчен фәтва булып тора», – дип әйтәләр.

Тагын бер мисал китерик: Госманга кадәр Изге Коръән төрле язу төрләре белән язылган була. Фетнә булдырмау максаты белән, ул бар өммәт өчен бары бер генә язу төрен калдырып, Коръәнне башка язу төрләрендә язуны тыя. Моның белән бар өммәт килешә. Беркем дә Госманны вәҗиб

булмаган әйберне вәҗиб итүендә гаепли алмый. Нәкъ шулай ук, башка бер зур фетнәне булдырмау максаты белән, шәхси тәкълид вәҗиб була.

Тәкълиднең иң беренче дәрәҗәсе – халык тәкълиде. Халык астында өч төрле кешеләр аңлашыла: беренчедән, гарәп телен бөтенләй белмәүчеләр һәм дини гыйлемнәре булмаган кешеләр; икенчедән, гарәп телен яхшы белүчеләр, әмма тиешле дини белем алмаган кешеләр; өченчедән, даими рәвештә дини белем алучылар һәм рәсми рәвештә дини уку йортын тәмамлаучылар, әмма тәҗрибә дә, аңлау да, осталыгы да булмаган кешеләр. Бу өч төр кешегә дә тәкълид кылу вәҗиб булып тора. Аларга үзләренең мөфтиләре карарларына каршы килергә рөхсәт ителми, хәтта, алар күзлегеннән кайбер карарлар хәдисләргә каршы килә кебек тоелса да.

Кеше алдында хәдис була торып, аны калдырып, мөфти карарына буйсынырга кирәклек сәер тоелырга мөмкин. Әмма бу кешеләрнең башка чаралары юк, чөнки аларның мөстәкыйль рәвештә Коръән һәм хәдисләрдән дәлилләрне аңлап, дөрес карар кабул итәргә җитәрлек гыйлемнәре юк.

Еш кына Коръән һәм хәдисләрдә сүзләр бер туры мәгънәгә ия, әмма башка дәлилләрне истә тотканда, бөтенләй башканы белдерәләр. Бу очракта, әгәр гади халыкка имамның хәдискә каршы килгән сүзләрен кире кагарга рөхсәт ителсә, күпчелек очракта ялгышлыклар туачак. Шул рәвешле күп кешеләр ялгышкан. Мисал өчен, тарихта белемсез кешеләрнең намаз вакытында кыйбла тарафына юнәлергә баш тартулары билгеле. Моңа аңлатма итеп алар түбәндәге Коръән аятен китергән:

وَلِلَّهِ الْمَشْرِقُ وَالْمَغْرِبُ فَأَيْنَمَا تُوَلُّوا فَثَمَّ وَجْهُ اللَّهِ

«Мәшрикъ та, мәгъриб тә, әлбәттә, Аллаһы Тәгаләнекедер. Күңелегез Аллаһта булса, кайсы якка юнәлсәгез дә, Аллаһ ризасын табарсыз».

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:115

Имам Әбү Йосыф: «Әгәр кемдер «кан алдырган һәм кан алган кешеләрнең икесенең дә уразасы бозыла» хәдисен укып, уразадан чыкса, аңа уразасы өчен кәффарәт түләү вәҗибкә әйләнә. Әмма әгәр аңа мөфти бу сәбәпле ураза бозыла, дип әйтсә, һәм ул шуннан соң ашый-эчә башласа, бу очракта аңа кәффарәт түләү вәҗиб булмый», – дип әйтә. Сәбәбен болай аңлата: «Гади кеше өчен, үзе хәдисне аңлый алмау сәбәпле, галимгә ияру вәҗиб булып тора».

Мәзһәбкә ияруне тәнкыйтьләүче кайбер кешеләр тәкълидне түбәндәге аятькә бәйли:

وَإِذَا قِيلَ لَهُمُ اتَّبِعُوا مَا أَنزَلَ اللَّهُ قَالُوا بَلْ نَتَّبِعُ مَا أَلْفَيْنَا عَلَيْهِ آبَاءَنَا

«Вә аларга: «Аллаһ иңдергән Коръән хөкемнәренә иярегез», – дип әйтелсә, алар: «Ата-бабаларыбызны нинди юлда тапсак, шул юлга иярәбез, алар кылган гамәлләрне кылабыз, алар юлыннан чыкмыйбыз», – диләр».

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:170

Бу аятьне карап китик. Беренчедән, Коръән тыйган тәкълид иманга карый, ә алда әйтеп кителгәнчә, иман да, Коръән һәм хәдисләр белән дәлилләнгән әйберләр дә тәкълидкә карамый.

Икенчедән, аятьтә сүз Аллаһы Тәгалә кушканнарны кире кагып, моңа каршы дәлил итеп үз бабаларының гамәлләрен китергән кәферләр турында бара. Имамнарга ияруче кешеләр Аллаһ кушканнарны кире какмый, ә бары тик мөҗтәһидләрнең аңлатмаларына ышана.

Өченчедән, алга таба Коръәндә бу ата-бабаларга иярергә ярамауның сәбәбе дә аңлатыла:

أَوَلَوْ كَانَ آبَاؤُهُمْ لَا يَعْقِلُونَ شَيْئًا وَلَا يَهْتَدُونَ

«Аларның ата-бабалары ислам диненең хаклыгыннан һич нәрсә белмәүче һәм туры юлны тапмаучы иделәр түгелме?»

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:170

Аятьтән аңлашылганча, аларның ата-бабалары берни аңламаган һәм туры юлда булмаган, ә дүрт имамның хәтта ялгыш, адашкан агым вәкилләре дә гыйлемле һәм хак юлда булуларын таный.

Тирмизинең хәдисләр җыентыгында Гади бине Хәтимәдән тапшырыла: Расүлүллаһ (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) Коръәннең:

اتَّخَذُوا أَحْبَارَهُمْ وَرُهْبَانَهُمْ أَرْبَابًا مِّن دُونِ اللَّهِ وَالْمَسِيحَ ابْنَ مَرْيَمَ وَمَا أُمِرُوا إِلَّا لِيَعْبُدُوا إِلَٰهًا وَاحِدًا لَّا إِلَٰهَ إِلَّا هُوَ سُبْحَانَهُ عَمَّا يُشْرِكُونَ

«Алар Аллаһны ташлап, үзләренең галимнәрен яки заһидләрен раббылары итеп алдылар».

«Тәүбә», 9:31

аятен тәфсирләгәндә: «Кешеләр аларга табынмасалар да, әмма алар тарафыннан нәрсәдер рөхсәт ителсә, шуны үзләренә рөхсәт ителгән, тыйса – тыелган дип санаган», – дип әйтә. Ягъни Китап әһелләре үзләренең галимнәрен мөфәссирләр дип кенә түгел, ә һичшиксез дөрес кануннар кертүче дип санаган, үз шәригатьләренә яңа кануннар керткән. Исламда исә, киресенчә, мөҗтәһид имамнарны беркем дә һичшиксез хаклы дип тә, кануннар кертүче дип тә санамый.

Шулай ук кайбер надан кешеләр тәкълидне тәнкыйтьләп түбәндәге аятьне китерә:

وَلَقَدْ يَسَّرْنَا الْقُرْآنَ لِلذِّكْرِ فَهَلْ مِن مُّدَّكِرٍ

«Коръәнне укырга җиңел вә мәгънәсен аңларга ачык кылдык. Коръән белән вәгазьләнеп гамәл кылучы вә Коръән куркыткан газабтан куркучы бармы?»

«Камәр / Ай», 54:17

Бу аятьтән Коръәнне һәм андагы әмерләрне аңлавы бик җиңел, шуңа күрә нинди дә булса мөҗтәһидкә иярү кирәге юк, имеш, икәнлеге аңлашыла. Әмма Коръән аятьләре ике төрле була. Беренче төр үз эченә – шәригать хөкемнәрен, ә икенчесе нәсыйхәт һәм кисәтүләрне ала. Ислам динендә бар китаплар да бер китапны аңлар һәм тәфсир итү өчен язылган – ул да булса Изге Коръән. Ә Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) төп миссияләренең берсе булып Коръәнне аңлату, тәфсирләү торган. Шәригать кануннарының бар нечкәлекләрен азсанлы чын галимнәр генә аңлый ала. Ә икенче төр аятьләрне аңлау бик җиңел, һәм һәркем алардан нәсыйхәт һәм файда ала ала.

Ахырда Габделваһһаб Әш-Шәграни «Әл-Мизәнүл-кубра» китабында китерелгән имам Мәликнең сүзләрен искә төшерәсем килә: «Фикһка бәйле мәсьәләләрне хәл итүне имамнарга калдырыгыз һәм алар белән бәхәсләшмәгез. Әгәр без бер кешегә иярүне башка, бәхәстә остарак кешене очраткан саен калдырсак, берзаман Җәбраил аша иңдерелгәннәрдән баш тарту чигенә җитүебездән куркыр идек!»

Ә Аллаһка яхшырак мәгълүм.

Камил хәзрәт Сәмигуллин,

ТР мөфтие

Хәнәфи мәзһәбенең төп китаплары

(ахыры)

«Әл-Әсәр»

Әбү Хәнифәнең башка укучылары кебек үк, имам Мөхәммәд тә остазыннан ишеткән хәдис һәм әсәрләргә бик игътибарлы булган. Аларны ул, үзеннән риваять һәм шәрехләр өстәп, «Әл-Әсәр» китабында китерә. Китапның авторы булып имам Мөхәммәднең саналуы гадел: ул Әбү Хәнифәдән ишеткәннәре белән генә чикләнми, ә башка кешеләрдән ишетеп белгәннәрен һәм үзенең аңлатмаларын да китерә.

«Әл-Әсәр» китабында ул Гыйрак факиһларына билгеле булган һәм Әбү Хәнифә тапшырган бар хәдисләрне һәм риваятьләрне җыя. Китапка кергән тапшырылган әсәрләрнең күбесе Әбү Йосыфның «Китаб әл-әсәр»ендә китерелгәннәргә туры килә. Һәм алар икесе дә Әбү Хәнифәнең мөснәде булып санала. Бу ике әсәр дә Әбү Хәнифәнең хәдисләр һәм сәхабәләр белән тәбигыйннәрнең риваятьләрендә ни дәрәҗәдә хәбәрдар булуын ачыклауда зур әһәмияткә ия. Әлеге китаплар хәнәфи мәзһәбенең нәрсәгә нигезләнгәнен, Әбү Хәнифәнең хәдисләргә һәм риваятьләргә карата куйган таләпләрен күрсәтә.

«Әл-Әсәр»дә китерелгән күпчелек хәдисләрне Хәммәд бине Әбү Сөләйман исемле тәбигыйн Ән-Нәхагыйдан тапшырган. Шул рәвешле тапшырылган риваятьләрнең күпчелеге Ән-Нәхагыйның карашларын чагылдыра. Бу риваятьләрнең бер өлешен Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең хәдисләре тәшкил итә, бер өлеше – сәхабәләр яки тәбигыйннәр рияватьләре. Шул рәвешле, «Әл-Әсәр»нең нигездә Ән-Нәхагыйның карашларын чагылдыруы аңлашыла.

Бу китапта барлыга 916 риваять китерелә.

Ибне Хәҗәр Әл-Гаскаләни (һиҗри буенча 852 елда вафат) Ибне Кутлубуга (һиҗри буенча 879 елда вафат) үтенече буенча «Әл-Исар би

мәгърифәти рувәти Әл-Әсәр» дип аталган зур булмаган хезмәт яза. Бу хезмәтендә ул «Әл-Әсәр»дә кулланылган терминнарны аңлата. Соңрак Ибне Кутлубуга үзе дә шушы ук темага китап яза.

«Әл-Мүвәттә»

Имам Мәликнең «Мүвәттә»се безнең көннәргәчә сакланган сөннәткә бәйле һәм күп кенә бүлекләрдән төзелгән беренче әсәр булып тора. Шул ук вакытта, ул хәдисләр һәм фикһ мәсьәләләре бергә каралган беренче әсәр дә. Имам Мәлик анда Хиҗазлылар тапшырган иң ышанычлы хәдисләрне, шулай ук Мәдинәле сәхабә һәм тәбигыйннәрнең әйткән фикерләрен туплаган.

Мәһди хәлифәнең хакимлек иткән беренче елларында «Мүвәттә»нең даны бар тирә-якка тарала, кешеләр ераклардан, «Мүвәттә»не имам Мәликтән ишетергә дип, Мәдинәгә килә торган була. Шулар арасында имам Мөхәммәд тә була. Аннан соң бу кешеләр, туган җирләренә кайткач, әсәрне башкаларга сөйләгән. Аларның исемнәре әсәрне тапшыручылар исемнәре арасында аталган. Имам Мөхәммәд имам Мәликтә өч елдан артык торган.

Имам Мөхәммәд исеменнән бу әсәрне аның шәкерте Әбү Җәгъфәр Әхмәд бине Мөхәммәд бине Михран Ән-Нәсәви тапшыра.

Башка нөсхәләрдән аермалы буларак, имам Мөхәммәд тапшырган «Мүвәттә» имам Мәликтән алынган риваятьләр белән генә чикләнми. Аларга өстәмә рәвештә ул башкалардан, бигрәк тә Хиҗазлылардан һәм Гыйраклылардан ишеткән, риваятьләрне һәм үзенең фикерләрен китерә. Шул сәбәпле ул башка «Мүвәттә»ләр арасында аерым урын алып тора.

«Әл-Хуҗа галә әһлил-Мәдинә»

Имам Мөхәммәднең бу китабының исеме чыганакларда «Китаб әр-радд галә әһлил-Мәдинә» дип тә килә.

Алда әйтелгәнчә, имам Мәлик янында өч елдан артык торып, имам Мөхәммәд аннан һәм Мәдинәнең башка галимнәреннән хәдисләр өйрәнү белән беррәттән, галимнәрнең монакашаларында да катнаша, һәм аларның материалларын «Әл-Хуҗа» хезмәтендә чагылдыра. Аның Мәдинәдән Куфагә кайтуыннан соң, шәкертләре бу әсәрне тыңлый һәм тапшыра. Тапшырылган вариантлар арасында Гайсә бине Әбән тапшырганы аеруча билгеле. Бүгенге көндә бездә булган нөсхәнең тапшыручысы булып нәкъ ул тора.

«Әл-Мәхариҗ» фил-һиләл»

«Мәхариҗ»нең авторы имам Мөхәммәд булуы бәхәсле. Әс-Сәрахси Хаким Шәһид сөйләгән «Мәхариҗ»нең кыска вариантын шәрехләгән. Әмма ул бу әсәрнең авторы имам Мөхәммәд булуы бәхәсле икәнлегенә игътибар итә. Аның аңлатмаларына караганда, имам Мөхәммәднең шәкерте Әбү Хәфс бу әсәр имамныкы булуы белән килешкән, әмма аның башка шәкерте Әл-Жүзҗәни моны кире каккан. Әс-Сәрахси беренче фикерне дөресрәк дип санаган.

«Әр-Радәгъ»

«Әр-Радәгъ» – безнең көннәргә кадәр сакланып калмаган кечкенә китапчык. Безгә бары тик Әс-Сәрахсинең «Әл-Мәбсүт»енә кергән бу китапка шәрехләр генә килеп җитә. «Китаб Әр-Радәгъ»ның башында Әс-Сәрахси бу хезмәтнең имам Мөхәммәднеке яки аның шәкертләренеке

булуы турында бераз мәгълүмат бирә. Ул китапның авторы дип имам Мөхәммәдне саный.

«Ихтиләфү Әбү Хәнифә вә Ибне Әби Ләйлә»

Бу әсәрне имам Мөхәммәд Әбү Йосыфтан тапшыра. Анда Әбү Йосыфның беренче остазы Ибне Әбү Ләйлә белән Әбү Хәнифәнең карашларындагы аермалыклар күрсәтелә. Ике остазының да фикерен китергәч, ул еш кына үзенең карашларын да китерә һәм күпчелек очракта Әбү Хәнифәнең фикере белән килешә, ә кайвакыт Ибне Әбү Ләйләнекен сайлый. Кайбер мәсьәләләрдә Әбү Йосыф аларның икесе белән дә килешми һәм үз фикерен китерә.

«Әл-Умм» китабында Шәфигый үзенең фикерләре һәм өстәмәләре белән бу әсәргә дә урын бирә.

«Әл-Мәбсүт»тә Әс-Сәрахси «Ихтиләфү Әбү Хәнифә вә Ибне Әби Ләйлә» хакында болай дип әйтә: «Әбү Йосыф бу әсәрне Ибне Әбү Ләйләдән Әбү Хәнифәгә күчкәч яза. Ә имам Мөхәммәд аны башка кешеләрдән ишеткән мәгълүматларны да өстәп тапшыра».

Камил хәзрәт Сәмигуллинның

«Введение в ханафитский фикх» китабыннан тәрҗемә

Коръән турында гыйлем

(Дәвамы)

Фән буларак «Коръән тәфсире»: нигезләре һәм чыганаклары

Коръән фәннәре арасында бу фәнни өлкә иң әһәмиятлеләренең берсе булып санала. Аның дәрәҗә югарылыгы да «югары максат» дип атала.

Безнең бер мөхтәрәм остазыбыз[1] үзенең Коръән фәннәренә багышланган китабын «Коръән өйрәнүдә иң югары максат»[2] дип атады. «Коръән фәннәре» дип исемләүгә караганда – бу атама төгәлрәк була.

Коръән тәфсирләү эшенең нигезләрен өйрәнүгә багышланган хезмәтләр бик күп. Бу мәсьәлә буенча махсус китаплар да бар, шулар арасыннан: Мөхәммәд Хөсәен Әз-Зәхәби шәехнең «Коръән тәфсире һәм тәфсирчеләр».

«Тәфсир» төшенчәсе турында

«Тәфсир»нең лексик мәгънәсе.

«Тәфсир» сүзе «фә», «син» һәм «ра» авазларыннан барлыкка килә һәм «аңлату (төшендерү, ачыклау)» дигән мәгънәдә кулланыла. «Гарәпләрнең теле» дигән китапның «фә-син-ра» дигән бүлегендә әйтелгән: «Фәсер» дигән сүз «аңлату» (яшерен нәрсәне ачыклау) дигән мәгънәдә була; «тәфсир» – яшерелгән (капланган) сүзне ачу (аңлашылмаган сүзнең мәгънәсен ачу)».

---

1 Безнең мөхтәрәм остазыбыз – шәех Мөхәммәд Әбү Шәхбә (Аллаһы Тәгалә аннан разый булсын).

2 «Әл-мәдхәл илә дирасәти-л-Коръән» («Коръән өйрәнүдә иң югары максат»).

«Тәфсир»нең шәргый мәгънәсе.

Коръән тәфсире ул – Аллаһы Тәгаләнең Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) иңдерелгән Китабының мәгънәләрен аңларга һәм аннан хөкемнәр чыгарырга һәм хикмәтләр табарга ярдәм итә торган махсус фән һәм Коръән фәннәренең бер тармагыдыр.

Шулай ук галимнәр «тәфсир» дигән сүз урынына «тәэвил» дигән сүзне дә кулланалар.

Телдә «тәэвил» («әүвәл» сүзеннән) «(әүвәлгә, башлангычка, чыганакка) кайту» дигәнне аңлата.

Коръән белән бәйләп караганда, «тәэвил»нең шәригатьтәге мәгънәсе ул – махсус кагыйдәләргә һәм тирән эзләнүләргә нигезләнеп, Коръән сүзләрененең иң әүвәлге мәгънәләренә кайтудыр.[1]

Кайбер галимнәр «тәэвил» төшенчәсе «тәфсир» төшенчәсенә керә, диләр (бер хосусый нәрсәнең гомуминең өлеше булган кебек). Мәсәлән, Мөхәммәд бине Җәрир Әт-Тәбари имам үзенең Коръән тәфсирендә «тәэвил»не «тәфсир» белән менә ничек бәйләп куллана: ул аятьне тәфсирләгәндә «Аллаһы Тәгаләнең ошбу сүзләренең тәэвиле...» дигән сүзләр белән башлый торган була (ягъни ул гомуми төшенчәне тирәнтен (беренчел) мәгънәсенә төшеп аңлата).

Төрле катлаулылыктагы Коръән тәфсирләре

Коръән тәфсирләре үзләренең катлаулылык дәрәҗәләре буенча берничә төргә бүленәләр.

Бу мәсьәләне тәфсир өлкәсенең беренче имамы, иң күренекле тәфсирче Габдулла бине Габбас (Аллаһ аннан разый булсын) аңлаткан: «Тәфсир дүрт төргә бүленә: гарәп телендә язылган һәм гарәпләргә генә

[1] «Әл-Иткан»ның «Тәэвил белән тәфсирнең аермасын тикшерү» дигән бүлеген кара (2/173), һәм шулай ук, «Әт-Тәфсир вә-л-Муфассирун»не (1/19-22).

(шул исәптән, гарәп телен белүчеләргә дә) аңлашыла торган тәфсир; барча кешеләргә (шул исәптән, гыйлемсезләргә дә) аңлашыла торган тәфсир; галимнәр генә аңлый торган тәфсир; беркемнең дә аңына сыймый торган (фәкать Аллаһы Тәгалә генә белгән) тәфсир».

Тәфсирләрне болай итеп бүлеп карау – бик төгәл һәм бик дөрес була.

Тәфсирнең беренче төре гарәп теле фәне (аның грамматикасы һәм башка махсус өлкәләре) белән бәйле.

Тәфсирнең икенче төре (Коръәннең мәгънәләре барча кешеләргә дә аңлаешлы булганы) бернинди дә сораулар тудырмый.

Галимнәр генә аңлый торган тәфсир ул – Коръәннең төрле нечкәлекләрен, яшерен һәм катлаулы мәгънәләрен, күпкырлы гүзәллелеген h. б. иҗтиһад кылып һәм бик тә игътибарлы булып җентекләп тикшерә һәм өйрәнә торган фәнни эштер. Һәрбер галимнең үзенә хас булган фәнни-эзләнү өлкәсе бар, әйтик, фикһ өлкәсе яисә «Коръән теленең гүзәллеге» өлкәсе.

Тәфсирнең дүртенче төре – Коръәндә Ахирәт белән бәйле булган һәм аңга сыймый торган гаиб (яшерен) нәрсәләр турында тупланган гыйлемнәр. Болары фәкать Аллаһы Тәгаләгә генә билгеле булган рух (җан), фәрештәләр турындагы гыйлемнәр. Аларны без аңлый алмыйбыз – аларны фәкать ышану нигезендә генә кабул итеп була.

Аңлатма юллары (ысуллары, чыганаклары) һәм Коръән тәфсирләренең төрләре

Коръән тәфсирләре үзләренең аңлатма юллары (ысуллары, чыганаклары) белән ике төргә бүленәләр:

1. «Тәфсир би-л-мәәсүр» – تفسير بالمأثور («тапшырылган тәфсир»гә нигезләнгән Коръән тәфсире). Бу хәдис аша яисә сәхабәләрдән һәм

аларның иярченнәреннән килгән хәбәрләр һәм мәгълүматлар аша Коръәнгә аңлатма бирү.

2. «Тәфсир би-р-райи» – التفسير بالرأي («Коръәнне үзеңчә фикерләп тәфсирләү»). Бу Коръәнгә аңлатканда тәфсирченең фәкать үз фикереннән генә чыгып, үзенчә генә аңлап-фикерләп эш итүе.

Нуретдин Гыйтырның

«Коръән турындагы фәннәр» китабыннан

Тарих

Пәйгамбәрләр тарихы

Мөхәммәд Әл-Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәсәб шәрифе

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм гарәп кавеменнән, Кораеш кабиләсеннән иде. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Габдуллаһ углы, Габдуллаһ Габдел-Моталлиб углы, Габдел-Моталлиб Һашим углы, Һашим Габдемәнәф углы, Габдемәнәф Кусайи углы, Кусайи Киләб углы, Киләб Мурра углы, Мурра Кәгъб углы, Кәгъб Лөәйи углы, Лөәйи Галиб углы, Галиб Фәһер углы, Фәһер Мәлик углы, Мәлик Нәдр углы, Нәдр Кинәнә углы, Кинәнә Хузәймә углы, Хузәймә Мудрикә углы, Мудрикә Ильяс углы, Ильяс Мудар углы, Мудар Низар углы, Низар Могадди углы, Могадди Гаднән углы, Гаднәннән соң Адәм галәйһис-сәләмгә кадәрле бик ачык билгеле түгелдер.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең анасының нәсәб шәрифе

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең анасы Вәһеб кызы, Вәһеб Габдемәнәф углы, Габдемәнәф Зөһрә углы.

Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дөньяга килеше вә тәрбия рәвеше

Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккә шәһәрендә рабигыль-әүвәл аеның уникенче көнендә дүшәмбе көн таң вакытында туды, милади тарих елы биш йөз алтмыш тугызынчы ел, апрель аенда иде. Атасы Габдуллаһ Шам кәрваны берлә Мәдинәгә барганда Расүлүллаһ

салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тууыннан ике ай элек Мәдинәдә вафат булган иде. Бабасы Габдел-Моталлиб Мөхәммәд дип атады вә һәм тәрбиясенә шөруг кылды[1]. Мәккә халкы яшь балаларны Мәккәдә тотмыенча, имезмәк вә тәрбия кылмак өчен сөт анасына биреп, яхшы һавалы кырга вә авылларга җибәрерләр иде. Шул гадәт үзрә Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне дәхи Бәнү Сәгыйд кабиләсеннән Харис исемле кешенең хатыны Хәлимәгә биреп җибәрделәр. Хәлимә Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне имезде вә сөт анасы булды. Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм биш яшендә вакытында анасы вафат булды. Сигез яшендә чагында бабасы Габдел-Моталлиб вафат булды, бабасыннан соң Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне Әбү Талиб тәрбия итте. Әбү Талиб Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең атасы Габдуллаһ берлә бертуган иде, Габдел-Моталлибның углы иде. Унике яшендә чагында Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне Әбү Талиб Шам шәһәренә алып бармак булып, сәфәргә чыкты. Шам вилаятендә Бусра дигән шәһәрдә Бахира исемле мәшһүр раһибнең[2] саумәгасы[3] янында кундылар. Бахира Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне һәрвакыт күләгәләп йөри торган болытны күргәч, Әбү Талибка: «Бу баланы Шамга алып бармагыл, яһүдиләрдән зыян тияр. Бу бала ахырзаман пәйгамбәре булса кирәк», – дип аңлатты. Әбү Талиб Бахирадан ул сүзләрне ишеткәч Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне Мәккәгә кайтарды.

Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм егерме биш яшендә вакытында хәзрәти Хәдичә бинт Хөвәйлид малы берлә сәүдә өчен янә Шамга сәфәр кылды. Хәзрәти Хәдичәнең сәүдә вәкиле Мәйсәрә дәхи бергә иде. Бу сәфәрләре дә бәрәкәтле булды вә күп файда хасил булды. Мәйсәрә юлда Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән гаҗәеп эшләр күрде. Кайткач Хәдичәгә сөйләде. Бу Мөхәммәд Әл-Әмин тикмә адәм булмас,

1 Тәрбиясенә шөруг кылды – тәрбияли башлады.

2 Раһиб – монах.

3 Саумәга – хөҗрә, монах бүлмәсе.

гадәттән тыш галәмәтләре бар, дип аңлатты. Хәзрәти Хәдичә әүвәлдә бер төш күреп, бик белекле булган якын карендәше Вәрака бине Нәүфәлдән юратмыш иде: «Син ахырзаман пәйгамбәренең хатыны булырсың», – дип юрамыш иде. Шул сәбәптән хәзрәти Хәдичә зур өметтә торадыр иде. Ошбу сәфәрдән кайткач, хәзрәти Хәдичә Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә барырга булды. Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әбү Талиб вә башка ир углары берлә киңәш соңында хәзрәти Хәдичәгә никахланды. Ул вакыт хәзрәти Хәдичә кырык яшендә тол хатын иде. Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең иң сөекле хатыны ошбу (Хәдичә әл-кубра) разыйаллаһу ганһә иде. Аның өстенә Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм хатын алмады. Касыйм, Габдуллаһ исемле ике углы, Зәйнәп, Рөкаййә, Өмме Көлсем, Фатыйма исемле дүрт кызы ошбу Хәдичә разыйаллаһу ганһәдән булды.

Гарәпләрнең иске хәлләре

Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманына кадәр Мәккә гарәпләре мөшрикләр иде, потларга табынучылар иде. Араларында нәсрани, яһүди юк хөкемендә иде. Шигырь вә нәсәб галименнән башка галимнәре юк иде. Араларында язу укыган, язу таныган кеше бик аз иде. Аталары Ибраһим пәйгамбәр галәйһис-сәләмнән калган Кәгъбә шәрифәне олуг тотсалар да, эченә вә тарафына потлар куймышлар иде. Ибраһим галәйһис-сәләмнән калган динне бозганнар иде. Латт, Гоззә, Мәнат, Һәбәл, Йәгус исемле мәшһүр потлары бар иде. Араларында потка табынудан бик аз кеше сәламәт иде. Вә ләкин үзләре зирәк йөрәкле, юмарт, сүзгә оста, оятлы вә намуслы, тугры сүзле, кунакны бик хөрмәт итүчән, карендәш вә туганга ярдәм кылучан халык иде. Араларында Корәеш кабиләсе артыграк вә кадерлерәк кабилә иде. Вә һәм Корәеш ыруглары арасында Һашим ыругы хөрмәтлерәк ыруг иде.

Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең пәйгамбәрлегенә кадәрле булган кыскача әхвәле

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм яшьлегеннән күркәм холыклы иде, фәкыйрьләргә ярдәмле вә гаҗизләргә шәфкатьле, раст сүзле, вә һәм аз сүзле, бик әдәпле вә һәр эшендә бик тугры иде. Мәккә халкы арасында бик тугры вә һәр эшендә ышанычлы булганнан «Мөхәммәд Әл-Әмин» дип аталган иде. Язу язмады вә һәм язу укымады, һичкемнән гыйлем өйрәнмәде, хәтта ул вакытта Мәккә тирәсендә гыйлем өйрәтердәй укымышлы кеше юк иде. Мәккә халкы арасында потка табыну гадәт булган исә дә, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм ул эштән пакь иде. Һич вакытта потка хөрмәт итмәде вә аңа сәҗдә кылмады, вә кылуны сөймәс иде. Аллаһы Тәгалә күңеленә салу берлә Мәккә янындагы Хира тавында аулакта Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт берлә үткәрер иде. Кырык яшенә кадәрле ошбу рәвештә тереклек итте.

Пәйгамбәрлек килеше

Расүлүлаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм кырык яшенә ирешкәч, Аллаһы Тәгалә тарафыннан хәзрәти Җәбраил галәйһис-сәләм аркылы вәхи килде. Әүвәл اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ сүрәсен хәзрәти Җәбраил Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә укыды. Әүвәлге вәхи вә һәм әүвәл иңгән сүрә ошбу сүрә булды. Аллаһы Тәгаләдән халыкны Ислам диненә өндәргә, потларга гыйбадәт кылудан тыярга боерык килде. Шул вакытта Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең пәйгамбәрлеге заһир булды. Вә һәм шул вакыттан ук Мәккә халкын дингә өнди башлады.

(Дәвамы бар)

Галимҗан Баруди, 1899 ел

Алтынчы мөфти – Сафа Баязидов

Духовное собрание мәхкәмәсендә Мөхәммәдъяр мөфти вафат булгач, Император Александр Николаевич III нең 1915 ел 28 нче июлендә бирелгән фәрманы илә Әхмәдсафа Гатаулла ахунд улы Баязидов мөфти була. Шул вакытта яше 37 дә иде, дини гыйлемне Казанда «Мөхәммәдия»дә алды. Аннан соң Петроградта Гурьева гимназиясендә укыды. 1911 елда Петербургтагы икенче мәхәллә мөселманнары үзен имам итеп, приговор төзүләренә күрә Уфада мәхкәмәи-шәргыя хозурында имтихан кылынып, 17 нче сентябрьдә имам-хатыйб мөдәррислек мәнсабына тәсдыйк кылынды. 1915 елның 28 нче июлендә мөфтилек креслосына килеп утырды. Бәгъзе бер аумакайлар мөфтиебез зөл-җәнәхайни (ике канатлы) дисәләр дә, күпчелек мөселманнар, имамнар, зыялылар Сафа мөфтине бик салкын каршы алдылар. Хәтта аның мөфти булуына каршы протест телеграммалары бирделәр. Сафа мөфти собраниядәге нәүбәт хезмәткәрләренә генә түгел, шул заманның сугыш сафындагы гәскәргә бер хыйтаб яздырып таратты. Ләкин аның бу хыйтабы әһәмиятсез калды, чөнки гаскәр сугышып арган, падишаһ хөкүмәтенә риза түгел һәм һәр җирдә тылда һәм фронтта да мәйдан алган иде. 1917 елның февралендә Сафа мөфти Яубаш мулласы Гариф Биктимиров белән берлектә чакырылып, Петроградка барганнар иде. Февральдә купкан революция көннәрендә Петроградта иделәр. Урамда каты атыш барганда, фатирларыннан чыгып мең бәла үтеп, вокзалга җитеп, Казанский тимер юлы белән Себергә качтылар. Россия мәмләкәтендә февраль революциясе көннәре үтте. Ил тынды, болар бер ай вакыт Себер калаларында йөреп, берсе Уфага, берсе Яубашка кайтты. Кайтканның икенче көнендә Уфадагы революционный комиссия исеменнән Гомәр Талынгулов һәм Әбуссогуд Әхмәдовлар килеп, Сафа мөфтигә домашний арест бирделәр, һәм 22 мартта аның мөфтилек мәнсабыннан төшерелүе хакында хәбәр килде. 30 нчы мартта Министер-

стводан вакытлыча мөфтилек хезмәтене Духовное Собрание әгъзасы Нурмөхәммәд Мамаевка тапшырдым, дип телеграмма килде.

Сафа Баязидов мөфтилек эшендә 19 ай 24 көн торды. Югарыда язылган алты мөфтинең рухани булып хезмәт дәүрендә хөкүмәтнең рөхсәте илә һәр елны шәһәр, вә авылларда бик күп мәчетләр салынды. Ләкин бу мәчетләрнең һичберсендә фасад ягыннан сәнәгать нәфислеге юктыр. Рус чиркәүләре кебек мәһабәт архитектуралы булмады. Хәлбүки гыйбадәт йорты булган мәчетләр бинасы тыныч лык һәм рухани истирахәт урыны булгач, мөмкин кадәр солтанәтле булу тиеш иде. Һәм матур агачлар, хуш исле чәчәкләр булу кирәк иде. Янә дә һәр мәчетнең мөнбәр өстендә кечкенә генә булса да тартма булып, шул мәхәлләнең тарихы язылып бару; ул тарих шул тартмада саклану беренче дәрәҗәдә кирәк иде. Болар берсе дә эшләнмәде. Шул сәбәпле мәчетләр тарихы караңгыдыр. Кем салдырган, кемнәр имамәтчелек кылган, нинди хезмәт күрсәткәнлеге мәгълүм түгел. Бу эшләр әле дә эшләнми (Габделхак Саматов 1997 ел.)

Мөхәммәдәнский закон мәхкәмәсендә казыйлар

Беренче нәүбәт

1789 ел 4 нче декабрь кенне Духовное Собрание Мөхәммәдәнский закон мәхкәмәсе ачылган вакытта, Әби патша фәрманы белән Казан муллаларыннан

1. Әбүбәкер Ибраһим углы.
2. Бикчәнтәй Ибраһим углы.
3. Габделхалик Әгзам углы казый булып хезмәт итә башладылар.

Бу затлар башта бик иҗтиһад белән эшләсәләр дә, соңыннан рагбәтләре сүнде. 5 нче ел эшләүләре вакытта берсе артыннан берсе казыйлык мәнсабын ташлап кайтып киттеләр. Моның сәбәбе түбәндәгеләр иде. Беренчедән, ул вакытта Уфада даими торучы Ислам гаиләсе юк

дәрәҗәдә иде. Икенчедән, Уфада мәчет булмау сәбәбле җәмәгать, җомга, һәм гает намазлары укылмый иде. Өченчедән, мәхкәмәдә бөтен эшләр дә русча иде. Русча белмәгән казыйларга бу бик авыр иде. Дүртенчедән, Мөхәммәджан мөфтинең гыйлеме аз булуга карамастан, үзен гаять югары тотуы, казыйларга начар мөгамәлә кылуы.

Икенче нәүбәт казыйлар

1. Ярмөхәммәд Бикбау улы 1793

2. Шәфә Гали улы 1794

3. Бикчәнтәй Җәгъфәр улы 1795-1796 елларда

Өченче нәүбәт казыйлар

1. Мөхәммәдәмин Мөхсин улы 1797

2. Габделвәһһаб Габделҗәлил улы 1798

3. Сафкол Котлыәхмәд улы 1799

Менә шушы тәртиптә 1789 елдан алып 1917 елдагы февраль революциясенә кадәр 128 ел вакыт эчендә һәр өч ел саен сайланып, барлыгы 63 кеше казый булып хезмәт иттеләр. Арада кайберәүләре 8 әр мәртәбә сайланды. Шушы 128 елның 100 елында фәкать Казан имамнары гына казый итеп сайландылар. 100 еллык юбилейда бу хакта сүз булгач Мөфти Солтанов Министерствога докладной язып биргәч, башка җирдәге имамнардан да казыйлар куела башлады. Безләргә исеме бик мәшһүр һәм китаплары белән бик киң файдаланган остазыбыз Ризаэддин бин Фәхреддин хәзрәт 1891 елда беренче мәртәбә казыйлык мәнсабына сайланды. 1906 елга кадәр биш мәртәбә сайланып 15 ел казый булып хезмәт итте. 1906 елда алтынчы мәртәбә сайлангач, май аенда мөфти Солтанов белән үпкәләшеп казыйлык мәнсабыннан истигъфа кылды (бушады).

Гыйнәятулла Капкаев 1893 елдан 1917 елга кадәр 8 мәртәбә казый булып сайланды.

Җәлаледдин Максудов 1866 елдан 1891 елга кадәр җиде мәртәбә казый булып сайланды. Бик зур байлыкларга хуҗа булды. Менә шулай итеп

1789 елдан 1917 елга кадәр 6 кеше мөфти һәм 63 кеше казый булды һәм болар барсы да падишаһ хөкүмәте тарафыннан куелдылар. Революциядән соң казыйларны сайлау хокукы мөфти ихтыярында булмыйча, халык сайлавына ихтыяр бирелгәч, Гыйнәятулла казыйлыкка үтмәде.

Монархия хөкүмәтенең һәм Духовное Собрание каршында мөселман руханиларының дәрәҗәләре падишаһ хөкүмәте закон китабының 1345-1399 нчы статьяларында мөселман руханиларының хокукы хакында ачыклап сөйләнгән иде. Фәкать Собрание мәхкәмәсе үзе

1. ахунд вә мөдәррис

2. имам-хатыйб

3. мөәззин дип, өч төрле дәрәҗә бирәдер иде. Күп мәхәллә мәчетендә бер имам бер мөәззин хезмәт итсә дә, бәгъзе мәхәлләдә ике имам бер мөәззин булып өч кеше хезмәт итәдер иде. Бу исә мәхәлләдә эш күп булып, бер имам җитешә алмаудан түгел, бәлки мәхәлләдә куштаннар тарафыннан гавам халкы арасында низаг чыгарып, ихтилаф чыгарыр өчен эшләнгән эш иде. Мулла сайлау мәхәллә халкының хокукы булып, әүвәл халык мулла сайлап, приговор төзиләр иде. Шул приговорга сайлаучылар кул куярга тиеш иде. Әмма авыл халкының күбесе кул куяр өчен яза белмәгәнлектән, авылдагы башбаштак, куштаннар җыелып берәүне имам итеп сайлыйлар да, приговор язалар, соңрак берсе кул куя белмәгән кешеләр өчен һәм үзем өчен кул куйдым... дип имза итәдер иде. Аннан соң волостной управлениедә халыкның имзасы тәсдикъ ителеп, земский начальник карамагына җибәрелә иде. Аннан соң Духовное Собрание мәхкәмәсенә җибәрелә. Аннан соң сайланган кеше Уфага имтиханга җибәрелә яки чакырыла. Ничә яшендәлеге, митрикәсе, яки паспорты, гаризасы секретарьда журналга теркәлә иде.

Имтихан кылынып, балл куелгач, шәкертнең бөтен документлары үзен сайлап куйган җирдә полициягә яки волостной управлениегә һәм губернский управлениягә тәсдикъ итәр өчен җибәрелә иде. Губернский за-

кон китабының 1435 нче пункты буенча имтихан мәҗлесендә күрсәтелгән дәрәҗәгә карап, тәсдикъ итә һәм үз исменнән свидетельство бирәдер иде. Бу исә указ дип атала иде. Бу указны мулла яки мөәзингә полиция яки исправниклар (илгә, ватанга тугры хезмәт итү, хөкүмәт законнарына хыянәт итмәскә, полиция тарафыннан бирелгән фәрманны һич каршылыксыз адә итәргә) дип ант иттереп бирелә иде. Кулына указ алган кеше инде хөкүмәт кешесе була, гаскәри хезмәткә бармый, әгәр мулла берәр хата эшләсә, аны инде түбән суд кына хөкем итә алмый, бәлки судебная палата яки окружной суд хөкем кыладыр. Вә янә имам булган кеше нәүбәт белән сайланмый, бәлки император кебек гомерлеккә сайланадыр иде.

Шул вакытта дин хезмәтчесенә менә ошбу йөкләмәләр йөкләнә иде.

1. Халыкка дин хөкемнәрен, әхлакый вәгазь вә нәсыйхат кылу, дини мәсьәләләрне халь итү, мәчеттә имам тору.

2. Дини мәрасимнәрне үтәү, исем кушу, никах уку, мәетләр күмү.

3. Ир-хатын арасында, яки халык арасында низагъ чыкса, аларның арасын нинди юл белән булса да төзәтү.

4. Хезмәт урынында хуҗа, яки эшләүче арасында гадәләт урнаштыру.

5. Үлгән кешеләрнең малын бүлүдә гадел рәвештә катнашу.

6. Туган, үлгәннәрне язуга беркетеп митрикә язу.

7. Балаларга дини тәрбия бирү.

8. Илдә һәм халык арасында тыныч лык саклау хакында вәгазьләү. Ләкин кайбер муллалар бу вазыйфаны тулысынча үти алмыйча, җиренә җиткерә алмады. Наданлык сәбәпле кимчелек кылдылар. Ислам кушканны бөтенләй борып җибәрүчеләре дә булды.

1917 елда – 1336 һиҗридә барлык гөлләр дә чәчәк атты. 1917 ел 17 нче февральдә Петроградта падишаһны газел кылдылар (төшерделәр). Күп еллардан бирле барган көрәш соңында Россиядә монархия хөкүмәте җимерелде. Барча халык җәбер, золым каһәре, милли тигезсезлектән

тәмам туйган иде. Бу ерткычлыкта күп кан агызган иде. Шуңардан котылырга барча халык зар-интизар булган иде. Шул көннән һәр милләт үзен рәхәт тормышка чыккан кош кебек сизә иде. Менә нәкъ шул вакытта 3,5 гасыр коллыкта изелеп җәбер, золым һәм контроль астында яшәгән мөселман да зур итеп сулап куйды. Фикерләрен әйтә, сөйләшә, киңәшә башлады. Хөкүмәттән рөхсәт алып 1 нче майда Мәскәүдә 1 нче мәртәбә мөселманнар съезды ачылды. 1 нче майдан 11 нче майга кадәр дәвам иткән съезда һәр тарафтан мөселманнар катнашты. Эчке Россиядән, Себердән, Кавказ, Кырым, Төркстан, Каспий, Бухара, Хивалардан эшчеләр, крестьяннар, сәүдәгәрләр, сугышчылар, руханилар барлык мандатлылар җыйналды. Барлыгы 830 кеше вәкил бар иде. Көн тәртибендә 10 төрле мәсьәлә каралачак иде. Шулардан безгә кагылышлысы 4 нче маддәдә булган Диния Нәзарәтенә вәкилләр сайлау иде. Менә Россиядә беренче мәртәбә мөфти һәм казыйларны мөселманнар үзләре сайлый. Нихаять 5 нче майда сайлаулар уздырылды. Җыелышта мөфти итеп Галимҗан Барудины сайладылар. Ак шар (292) кара шар (258) булды. Казыйлардан:

1. Салихҗан Урмановка (489) ак (90) кара шар булды.

2. Кәшшаф Тәрҗеманига (354) ак (213) кара шар.

3. Габдулла Сөләймани, Нижни мулласы (423) ак (166) кара шар.

4. Себердән Акмулла мулласына (364) ак (219) кара шар.

5. Мөхлисә Бубиягә (307) ак (280) кара шар.

6. Гомәр Әл-Краш, башкорт казые да керде. Хөкүмәткә белдерелде. Хөкүмәт өчесен саф казый дип таныды.

Съезда аларга түбәндәге эшләр йөкләнде. Имамлар кую, мәчет, мәдрәсәләр салдыру, Диния Нәзарәте эшләрен ана телендә алып бару, мөхтәсибләр, мөтәвәллиләр булдыру, Диния Нәзаратен дәвам иттерү өчен иганәләр җыю юлын ачу һәм башка дини эшләрне карау.

Җиденче мөфти – Галимҗан Баруди

Мәскәүдә мөселманнар съездында сайланган Казан шәһәре «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөдәррисе Галимҗан хазрәтнең тәрҗемәи хәле: Туган авылы Кече Кавал Казан вилаяте 1859 елда 2 нче февральдә бабасы Хәбибулла йортында дөньяга килә. Бу вакытта атасы Мөхәммәтҗан Галиев Нурмөхәммәд исемле бер сәүдәгәрдә приказчик иде. Бераздан Казанга күчеп, үзе сәүдә итә башлады һәм 6 яшендәге Галимҗан Күл буе мәдрәсәсенә укырга керде. Шунда ул вакыттагы программаларны узды. Галимҗан оялчан булса да, бик зирәк иде. Мәдрәсәдәге программалар белән генә канәгать булмыйча, башка китапларны да үзлегеннән укый иде. 15 яшендә гарәпчә дә аңлаша башлады. Безнең мәдрәсәләрдә тәгълим хәлләре кимчелекле икәнен аңлап, бу хакта чаралар эзли башлады. 1874 елда бер докторның киңәше белән Галимҗан Казахстанга кымыз эчеп дәваланырга китте. Бу сәфәре аңа матди тәрбия дә, зур мәгънәви тәрбия дә бирде. 1875 елда остазы Салахеддин хәзрәт васыяте һәм киңәше буенча 19 яшендә бөрадаре Газизҗан белән Бохарага гыйлем тәхсыйл кылырга китте.

Татарлар ул вакытта никадәр җәбер, золым астында булсалар да үзләренең мәчет, мәдрәсәләре булган һәм моның өстенә читкә чыгып, кайда теләсәләр, шунда барып кереп укый алганнар. Ләкин мәгаттәссеф (үкенечкә каршы) бүгенге иркенлектә, Советлар Союзында бөтен Нәзарәт белән берлектә бер кеше укыта алмау бик кимчелек. (Ягъни 1930 дан 1990 га кадәр). Галимҗан әфәнде 7 ел гыйлем эстәп йөреп кайта. Укыган фәннәре: тәфсир, хәдис, фараиз, әдәбият, гарабияттан мәган, гыйлем бәян, мөкаддәмәтел җәзәри, хикмәтел-гаен, мәллә җәләл, тәүзых, риязият; хисабел-җәбр, мәкабәлә (сопрамат) һәндәсә һәйәт, нәҗме тыйб һәм башкаларны укыган. 1882 нче елда Галимҗан Бохараны тәмамлап ике йөк китап төяп кайта. Галимҗан әфәнде Мәрҗани белән 7 ел яшәп калды.

Мәрҗани бу яшь кешедә аерым бер истиъдат (хазерлек) барын аңлап, 5 нче мәхәлләгә Йосыф хәзрәт янына икенче имам итеп тәкъдим итте һәм Галимҗан шунда урнашып, Йосыф хәзрәт белән мәдрәсәдә дәрес укыта башлады. Бохари мәдрәсәсен тәмамлап кайткан яшь мөдәррис янына төрле яктан шәкертләр җыйнала башлады. Ләкин мәдрәсә бинасы кечкенә булганлыктан яңа мәдрәсә (Мөхәммәдия) салу кирәк булды. Галимҗан хәзрәт Бохарада тәхсыйл вакытында мәдрәсәнең ике төрле эшенә нык тәнкыйть итә иде.

1 нче, мәдрәсәдә программа һәм тәртип юк.

2 нче, вәгазь – нәсыйхәттә аңлаешлы мөгамәләт юклык иде.

Галимҗан Баруди үзенең мәдрәсәсендә ислах (тәртип) кертү өчен программа төзеде. Ул программалар («Әд-дин вәл әдәб») дигән журналында язылган. Теләгән кешегә шуннан файдалану мөмкин булган. Ул программалар буенча чын китап вә сөннәт гыйлемнәрен өйрәтеп, фәкать чын ислам тәрбиясе укытылса, шунда дөнья вә әхыйрәт гыйлемнәре барсы да булачактыр. Галимҗан әфәнде матбугат эшенә дә керешеп 1906 елда («Әд-дин вәл әдәб») дип аталган журнал чыгара башлады.

Үзенең мәдрәсендә бик күп шәкертләр булып, программа белән укытылды. Анда гарәби әдәбият, сарф, нәхү, бәләгате гарәбия, риязият, хисап, һәндәсә, тәфсир, хәдис, әхлак укытылды. Бик күп көчле мөгаллимнәр чыгарыла иде (һәр, һәммә җирдә шулай булган булсачы). Кызганычка каршы, 1908 елда җәдид вә кадим низаглары көчәеп китү өстенә монархиянең Ислам дине голәмәсен ничек итеп кенә дә гаепләргә белмичә тору чорында, Галимҗан мөдәррисне һәм бертуган Салихҗан бөрадарене «Вологда» шәһәренә сөргәнгә өч елга озаталар. Сылтау: мәдрәсәдә халыкка яңа белем бирүне – хөкүмәткә каршы хәрәкәт дип карау иде. (1910 елгы «заман» календарында үз соравы белән, гарәп илләрендә сәяхәт итә дип язылган). Чит илдән кайткач та, һаман эшен дәвам итте, шулай ук «Әд-

дин вәл-әдәб»не чыгаруда катнашты, ләкин һаман контроль астында тикшерелеп торылды.

1917 елгы Мәскәүдәге мөселманнар съездында булмыйча, Төркстанга сәфәр кылган иде. Шулай булса да аны мөфти итеп кандидатурасын үткәрделәр. Кәшшаф Тәржемани һәм Садыйк Иман-Кулый ике кеше аның ризалыгын белдерделәр. Шуннан соң үзенә телеграмма бирделәр, шуны ишеткәч Казанга кайтты. Казан халкы бик зурлап каршы алдылар. Мөфтилеген тәбрикләделәр, бер җигүле ат бүләк иттеләр. Ләкин Галимҗан хәзрәт атны алмады, гафу үтенде. Мин мөфтиләрнең ришвәт алуларына каршымын диде.

Галимҗан хәзрәтне Казаннан Уфага берничә имамнар озата бардылар. Шулай ук Уфаның һәр сыйныфтан булган кешеләре тәбәррекләп каршы алдылар. 666 нчы сан «Тормыш» гәзитәсендә түбәндәгечә язылган:

1917 ел. 14 нче май

«Мөфти Галимҗан Әл-Баруди Сорокин пароходына утырып, 12 нче июньдә төнге сәгать 10 да килсә дә, пароходның 1 нче класс залында кунып калды, иртәгесен 13 нче июньдә сәгать 9 да Уфаның төрле вәкилләре пристәнгә төштеләр. Мөфти хәзрәт башында ак чалма, өстендә кара җөббә кигән, олуг голәмә кыяфәтендә чыгып халык белән исәнләште. Соңрак Салихҗан казый белән бергә аңа махсус хәзерләнгән дишлага утырып, шәһәргә юнәлделәр. Артларыннан атларга утырган ханымлар, алар артыннан башкалар юнәлде. Тезелеп үзәк урам беләм Нәзарәт мәчетенә килеп кереп, «тәхыйятел мәсҗид» намазы укылды. «Мәваи Мөбәрәк»не зиарат кылынды. Соңрак бөтен һәйәт белән Нәзарәт йортына килделәр. Мөфтинең мөбарәк мәҗлесе ачылып Салихҗан казый: «Сезне Нәзарәт һәйәте мөфтилек мәнсабыгыз белән тәбрик итә. Мөселманнар тарафыннан сайланган беренче мөфти буларак сезгә мокаддәс китап Кәләми шәриф Һәдия кыла, эшегездә хәерле фал булсын», – дип тәкъдим итте һәм кабул ителде. Бу мәрасим халыкка нык тәэсир итте, әзерләнеп җылаучылар

да булды. Мөфти үзе дә яшьле күзе белән шул Коръәнне ачып үтте. «Чын күңелдән шул Кәләмуллаһны һәр эшемдә вә хезмәтемдә раһбәр булсын», – дип гаһед (вәгъдә) бирде, китапны кабул итеп алды. Моннан соң тәбрикләү тыңланды. Мөфти хәзрәт түбәндәге җавапны бирде: «Хөрмәтле казыйлар, руханилар, матбугат хадимнәре, вә комитет вәкилләре, барысы да минем хакта өметләре зур булуны белдерәләр. Мин моңа зур тәшәккер кылам. Ләкин мин үземдә шул кадәр үк көч сизә алмыйм. Шулай да, сез ярдәмдә булсагыз, бергәләп эшләсәк, шәт эшләребез хәерле булыр, дип шатланып, үзем шул Коръән Кәримне дәстүрел гамәл итүне өмет итәм. Ислам диненә мәхәббәтем зур һәм гыйлмемә рагбәтем сәбәпле 35 ел инде шул юлда хезмәт итәм, һәрвакыт яхшы фикерле галимнәр белән булырга тырыштым. Күптән инде Россия мөселманнары мөфтиләрен үзләре сайларга телиләр иде. Ләкин әле мөселман шул теләгенә яңа гына ирешмәде. Олуг урынга мин фәкыйрне сайладылар. Картайган вакытымда шул олуг хезмәтне кабул иттем. Тугры эшемне тәхсин итсәгез, хаталарымны тәнкыйть итсәгез мәмнун (канәгать) булырмын», – диде.

«Тормыш» газетасы мәкаләсе тәмам.

Мәскәү съездында сайланган казыйлар һәйәте килеп урнашты. Салихҗан казый эш программасын мөфтигә тапшырды, һәрберсе хезмәтенә керештеләр. Ял итү якшәмбедән җомга көнгә күчерелде. Һәм Нәзарәт расходлары ихтиярый иганәгә калдырылды, чөнки инде совет хөкүмәттән аерды.

1918 елда август аенда Галимҗан мөфти Казакъ сахрасына чыгып китте. Труецкий, Кустанай, Кызылъяр, Күкчәтау, Акмулла буйларына чыгып, мәхәлләләрне карап, барлап йөрде. Ул вакытта большевиклар белән Колчак сугышы барган вакыт иде, кисәк кенә Уфа юлы камалып калу аркасында Галимҗан мөфти Колчак ягында камалып калды. Ләкин 18 нче ел ахырында Колчак гаскәре чигенде, шулар белән буржуйлар да Себергә күченделәр, шул вакыт Милли Идарә да Колчаклар белән Себергә күчте.

Милли Идарәнең бер шөгъбәсе булганлыктан Диния Нәзарәте дә күчеп китәргә тиеш диеп тәклиф (мәҗбүр) ителде. Шулвакытта Нәзарәт казыйлары икегә бүленделәр. Салихҗан һәм Хемҗҗәтелхәким Сибириягә күчү ягында булдылар. Аларның дәлилләре:

1. Беренчедән, яз көне большевиклар Милли Идарәны тараткан вакытта, Нәзарәт исеменнән подписьлар белән Мәскәүгә дини советка протест язган идек, инде Уфада утырып калсак большевиклар ягына авышу була. Милли идарә ягында булу артыгырак һәм безнең өстән Нәзарәт ябылса да мөсүлият төшәчәк диләр. Галимҗан мөфтине Мәскәүгә җибәреп дин хакындагы декретне алмаштыруны сорадык: алар кабул итмәделәр. Димәк, дингә ирек булмаячак. Әмма Милли Идарә дингә ирек бирә, бәс безнең өчен монысы яхшырак, диделәр. Калган өч казый, Кәшшаф Тәрҗемани, Ризаэддин бин Фәхретдин, һәм Мөхлиса Бубия Уфада калуны якладылар, вакыйган, хәерле дә булды.

Боларның дәлилләре:

Беренчедән, партия сугышында аумакайланып, күчеп йөрү сәяси эш, әмма Нәзарәт дини мәхкәмә. Шулай булгач без сәясәттән ерак булырга тиеш.

Икенчедән, Кәгъбәтулла урнындагы Нәзарәтне ятим калдырсак, аны тараткан булабыз, һәм мөсүлияттә булачакбыз.

Өченчедән, Себергә күчеп, эшсез калсак, 130 елдан бирле яшәп килгән мәхкәмәне таратсак, ни булачак? Күчүгә караганда монда калу язмышын күрү муафик, диделәр. Әүвәл сөйләгән ике Казый Петропавелга күчтеләр һәм анда Галимҗан мөфтине күрделәр. Мөфти Колчакны күреп сөйләште. Колчак әүвәлгә хокукыгыздан башка һич нәрсә артмас диде. Мөфти карагөруһлар арасында камалганлыгын белә иде.

1919 елда большевиклар Уфаны ташлап киттеләр һәм Колчак Уфага килде. Шул вакытта Галимҗан мөфти дә Уфага кайтып керде. 2 айдан

соң Колчак янә Уфадан китте. Гүяки мөфтине генә кайтарган кебек булды. Мөфти һәм казыйлар Уфада утырып калдылар.

1782 елда Әби патша заманында казакълар үз теләүләре белән Россиягә кушылганнар иде. Шулвакыт Кече йөз казакъларының ханы Бүкәй хан Нургали хан улы иде. 1788 елда Россия мөселманнарына мөфтилек бирелгәч, Бүкәй белән Вәли хан киңәшеп, без дә бит мөселман, безнең дә дини эшләребез бар, дип Диния Нәзарәтенә кушылдылар. Падишаһка да белдерү керттеләр. Әлбәттә, падишаһ баскынчылыкта йөргәнче, бик яхшы дип хуп күрде. Аларга куелган муллалар бик наданнар иде. Шул наданлыклары сәбәпле таркау казакъ халкын тәмам юлдан чыгардылар. Чөнки Нәзарәт тарафыннан җибәрелгән муллалар казакъ тормышы белән, гореф-гадәтләре белән таныш түгел иде. 1865 елда хөкүмәт тарафыннан вәкилләр чыгып казахларның тормышын тикшергәндә, казакълар Нәзарәттән аерылу ниятене белдерделәр, һәм бу хөкүмәткә бик кирәк тә иде. Шулай итеп Нәзарәттән ул вәкилләр аердылар. Фәкать Бүкәй хан казакъларны гына Нәзарәттә калдырды, чөнки Бүкәй ханның хатыны Фатыйма Мөхәммәтҗан мөфтинең кызы иде.

Казакълар Нәзарәттән аерылгач эшләре губернатор һәм әрхәрәйләр кулына бирелде. Шунлыктан эшләре бик читенләште. Русларның кыйланышларыннан шул кадәр нәфрәтләнделәр, бүредән качкан хайван кебек качтылар. Әгәр монархия вакытында чыгарылган «Правительственный вестник» газетасын укып карасаң, миссионерлар җәмгыятнең ничек халыкны чукындыру һәм руслаштыру өчен тырышып хезмәт итүләрен һәм дә чукынган халыкка бүләк бирү өчен тоткан расходларын күреп, шаккатарсың.

Миссионерлар тырышлыгы белән император акрынлап чукындырып бетерү ниятен тотып, Александр I 1808 елда фәкыйрь кыргыз, казакъ балаларын русларга сатарга рөхсәт дигән закон чыгарып, кулга төшкән

балаларны чукындырдылар һәм чукынган олуг казакъларга зур бүләкләр бирделәр: дөяләр, атлар-сыерлар.

1909 елда Духовное Собрание тарафыннан бастырылып таратылган мәгълүматлардан күрәбез:

1. Уфа губернасында 1681 мәчет – 4220 рухани була;

2. Казан губернасында 936 мәчет –1608 рухани булган.

Шулай булып торганда, Тургай-Кустанай кебек Казакъ областьларыннан һичбер мәчет булмаган. Димәк казакъ арасында мәчет салырга рөхсәт булмаганлыгын аңлата[1].

1917 елдагы Мәскәүдәге мөселманнар съездында казакълар да катнашты һәм Диния Нәзарәтенә кертелделәр. Казакълардан да казый да сайланып, бераз эшләттеләр.

1919 нчы елда Уфа шәһәре Колчактан арынгач, Галимҗан мөфти Уфа губерния исполкомына «безне дә үз химәягезгә алыгыз» дип гариза кертсә дә, дин хөкүмәттән аерым, дип кабул итмәделәр. Болай кагылып-сугылып йөреп булмый, без бит 17 нче елда Мәскәү съездында халык тарафыннан сайландык, дип казыйлар бөтен тарафтан мөтәвәлли һәм вәкилләр чакырып җыелыш үткәрделәр, (311) вәкил җыелды. 1919 ел 16/IX дә башланып, 8 көн дәвам иткән бу җыелышта яңадан мөфти сайланды.

1. Галимҗан хәзрәт 257 ак, 44 кара шар белән мөфти булды.

2. Риза казый 295 ак, 14 кара;

3. Кәшшаф Тәрҗемани 281 ак, 29 кара;

4. Мөхлисә Бубия 168 ак, 24 кара белән сайландылар.

5. Казакъ казыйсы Мәһди Мәгъкулый казый булды.

Зур ачлык! 1921 ел

Ачларга ярдәм итү теләге белән иганә җыярга рөхсәт алу нияте белән Галимҗан мөфти һәм Кәшшаф казый икәүләп рөхсәт алып, Сталин янына керделәр. Олуг даһи Сталин бик яхшы каршылады һәм зур

[1] Бу мәсьәлә белән танышу өчен Ризаэддин хәзрәтнең «төрек-болгарлар» исемле китабыннан карарга була.

ригая күрсәтте. Күп сүзләр сөйләшелде. Сталин болай дип әйтте: «Капиталистлар кулында изелгән, колония булып яшәгән халыкларга ярдәм итү коммунистларның якын бурычы». Мөфти бик канәгать булып чыкты. Ләкин бу эш Кәшшаф казыйның үзенә генә калды, чөнки икенче көнне Мәскәү имамы Габделвәдүд хәзрәт йортында Галимҗан мөфти бик нык авырды – үпкәсе шешкән. Кәшшаф казый мөфтинең хәлен белдереп Казанга-Уфага ашыгыч телеграмма бирде. Авыруга профессор да чара таба алмады, кыска һәм кискен авырудан Габделвәдүд хәзрәт йортында Галимҗан әл-Баруди хәзрәт 1921 ел 6 нчы декабрьдә вафат булды, һиҗри елның 1340 елы.

Мәрхүм 1859 елда туган, 62 яшендә 1921 елда вафат.

Мөфти Галимҗан Әл-Барудины күмү

Мөфти вафат булу белән Кәшшаф хәзрәт яңадан Казанга-Уфага телеграмма бирде. Икенче көндә Казан имамы Шәһәр Шәрәф Казан халкыннан үтенеч белән Мәскәүгә килде. Үтенече шул: Казан мөселманнары Мөфти Галимҗан хәзрәтнең җәсәд шәрифен үзенең төп ватаны – Казан зиратына алып кайтып күмүне сорадылар. Шәһәр Шәрәфне шул үтенеч белән җибәрделәр. Шуның буенча Кәшшаф казый Сталинга кереп киңәш итте. Казанга мәрхүмне алып кайтырга вагон сорады. Сталин бу эшне башкару өчен Калинига бирде, тимер юл комиссарына ике вагон бирергә кушты. 8 нче декабрьдә Мәскәүнең икенче мәхәллә мәчетендә Кәшшаф казый имамәтчелегендә җеназа намазы укылды. Бу озатуга Төркия, Иран, Әфган консуллары катнаштылар. Актыккы ихтирам, саубуллашу өчен озату мәрасименә вокзалда Мәскәүнең барлык мөселманнары катнашты.

Икенче көнне Казанның күп халкы Казан вокзалына чыгып мәрхүмнең гәүдәсен каршы алдылар. Җәсәден үзенең йортына алып кайтып, Казанның меңләгән кешесе һәм голәмәләре Яңа бистә зиаратына

күтәреп алып барып, дәфен кылдылар. Җеназасын туганы Салихҗан укыды. Диния Нәзарәте архивасында Кәшшаф казыйның кулы белән язылган озын доклад бар икән. Галимҗан хазрәт 4 елда 4 ай мөфти булып хезмәт итте.

Габделхак хәзрәт Саматовның

«Милләтебездә Ислам дине» китабыннан

Корбан

Корбан чалу

Гарәп телендә корбан чалу «удхиййә» дип атала. Ул вәҗиб булып тора һәм хаҗга бармаган кеше тарафыннан бәйрәм көнне башкарыла.

Аның фарыз булу шартлары:

1. Мөселман булуы;
2. Ирекле булуы;
3. Камил акылга ия булуы;
4. Мокыйм булуы (даими яшәү урынында булу);
5. Төп ихтыяҗларыннан артык мөлкәткә ия булу, корбан чалу гаилә бюджетына зыян китермәсен.

Бу максатларда дөя, сыер һәм сарык кебек хайваннарны гына корбан итү рөхсәт ителә. Әлеге хайваннарга түбәндәге таләпләр куела:

1. Мәгълүм бер яшькә җитүе (дөягә – биш яшь, сыерга – ике яшь, сарыкка – бер яшь, әмма алты айлык бәрән бер яшьлек сарык кадәр булса, ул да яраклы санала);
2. Кимчелекләрсез булуы (аягы, койрыгы, колагы, күзе булмаган яки аксак хайваннар корбан итеп чалына алмый)[1].

Әгәр хайванның колагы яисә мөгезенең күбрәк өлеше булмаса, ул корбан өчен ярамый, ә бу органнарының зуррак өлеше сакланса, ул яраклы санала.

Сыерны яисә дөяне җиде кеше исеменнән чалу рөхсәт ителә, әмма барысы да моны Аллаһ ризалыгы өчен башкарырга ния итәргә тиеш. Җиде кешенең берсе корбанны ите өчен генә чалырга уйласа, ул дөрес булмый[2].

---

[1] Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) болай дип әйткән: «Дүрт төрле хайванны корбан итеп чалу рөхсәт ителми: бер күзле, авыру, аксак һәм баш мие булмаган хайванны» (Сүнән җыентыкларында китерелә).

[2] Җәбирдән (Аллаһ аннан разый булсын) риваять ителә: «... һәм без дөя һәм сыерны җиде кеше исеменнән чала идек» (Мөслим).

Корбанга әзерләнгән терлекнең хуҗасы аны чалу эшләрен кемгә дә булса йөкләсә, аның хезмәте өчен корбан ите белән түләргә хакы юк.

Корбан чалуның вакыты – бәйрәм көнне кояш тәмам чыкканнан соң утыз минуттан алып, бәйрәмнең өченче көнендә кояш баеганчыга кадәр. Бәйрәм намазы укыла торган торак җирлекләрдә намазга кадәр корбан чалу дөрес түгел, ә намаз укылмаган авылларда – дөрес.

Корбан ите, гадәттә, өч өлешкә бүленә: бер өлешен туганнары белән ашыйлар, икенчесен мохтаҗларга бирәләр, өченчесен үзләрендә калдыралар. Әмма мондый бүленеш мәҗбүри түгел, һәр гаилә үзенең тормыш муллыгына карап эш йөртә.

Корбан чалган җиргә, гадәттә, имамны чакыралар. Чалыр алдыннан терлекне бәйләргә һәм бугазы белән кыйблага таба яткырырга кирәк. Шуннан соң имам түбәндәге доганы укый:

اللهم هذا منك وإليك. إن صلاتي ونسكي ومحياي ومماتي لله رب العالمين لا شريك له وبذلك أمرت وأنا أول المسلمين. اللهم تقبل منا هذه الأضحية. بسم الله الله أكبر.

Аннары терлек кичекмәстән бугазлана. Ит хайван тулысынча җан биргәннән соң гына бүленә, бу вакытта имам булмаска да мөмкин.

Гает көнне корбан чалу вакытына имамны, гадәттә, күп җиргә чакыралар. Бер үк вакытка туры килеп, мәхәллә халкы арасында үпкәләшүләр булмасын өчен, имам кая һәм кайсы вакытка чакырылуын алдан ук ачыкласа яхшы.

Гадәт буенча корбан чалганнан соң берничә көн эчендә мәҗлесләр үткәрелә. Мәҗлесләрдә корбан ите чыгарылыр алдыннан йола буларак Татарстанның кайбер районнарында тәшрик көннәрендә әйтелә торган тәкбир әйтелә. Ашаганнан соң имам Коръәннән берәр сүрә укый һәм

Аллаһы Тәгаләдән бу корбанны кабул итүне сорап һәм аны чалган гаилә өчен игелекләр теләп, дога кыла.

Р. К. Әдһәмовның «Дингә өндәү нигезләре һәм имамның вазифалары» китабыннан

Корбан чалу турында сораулар

С.: Корбан чалу нәрсә ул?

Ж.: Ул хаҗ белән гомрәдә түбәндәге максатлар белән хайван сую:

1. Ихрамнан чыгу өчен;

2. Бер йоланы үтәү өчен (моны карин яисә мөтәмәттигъ үтәр);

3. Кәффәрат түләү өчен;

4. Үз ихтыярың белән Аллаһка гыйбадәт кылу өчен.

С.: Корбан өчен нинди хайваннар ярый?

Ж.: Дөя, сыер һәм сарык. Ата яисә ана булса да – барыбер.

С.: Корбанлык хайваннарның нинди дә булса чикләмәләре бармы?

Ж.: Алар сәламәт вә кимчелексез, билгеле бер яшьтә булырга тиешләр.

С.: Бу билгеле яшьнең чикләре нинди?

Ж.: Сарык – бер яшь һәм аннан олы, сыер ике яшьтән олырак, дөя биш яшьтән олырак булырга тиеш. Әгәр дә 6 айлык сарык, бер яшьлек сарык кебек күренсә, шул да ярый.

С.: Сарыкны сәламәт итеп санау өчен, ул нинди шартларга туры килергә тиеш?

Ж.: Барлык әгъзалары да бөтен булырга тиеш, хәтта койрыгы, колаклары, күзләре дә. Әгәр койрыгының яки колагының аз өлешендә генә кимчелек булса, мондый хайванны корбанга чалырга рөхсәт ителә.

С.: Кайчан сыерны яки дөяне корбанга чалырга кирәк?

Ж.: Әгәр дә хаҗи зиярәт тәвафын җөнеб хәлендә кылса һәм тәһарәт кылганда кайтармаса, Гарәфәттә басып торганнан соң кырынуга вә зиярәт тәвафына кадәр якынлык кылса, сыер яки дөяне корбан итеп чалырга кирәк. Калган очракларда корбанга сарык китерсә дә җитә.

С.: Берничә хаҗи бергәләшеп корбан чалсалар ярыймы?

Ж.: Әйе, әгәр дә хаҗиның һәрберсе корбан чалырга теләсә, сыер белән дөяне бергә кушылып чалырга мөмкин.

С.: Әгәр дә җиде корбан чалучыларның берсе корбанны фәкать ит өчен генә чалса, бу ничек бигеләнә?

Ж.: Җидесенең дә корбаннары кабул булмый.

С.: Җиде корбан чалучының да корбанының итен ашарга рөхсәт ителәме?

Ж.: Хаҗ йоласы итеп корбан чалган хаҗига корбанның итен ашау мөмкин, ә кәффәрат өчен чалынган корбанның итен ашау тыела.

С.: Корбан чалу өчен аерым вакыт билгеләнгәнме?

Ж.: Хаҗ йоласы итеп, корбан чалу фәкать хаҗ көннәрендә генә (10 нчы зөлхиҗҗәдән алып 12 нче зөлхиҗҗәгә кадәр) үтәлә, тик хаҗ көнендә баганага таш бәргәнче рөхсәт ителми.

С.: Корбан итен әл-Хәрамдагы фәкыйрьләргә таратырга ярыймы?

Ж.: Таратырга ярый, вә әл-Хәрамнан читтә булган фәкыйрьләргә дә рөхсәт ителә.

С.: Кайсы очракта чалырга (кадап) һәм кайсы очракта суярга?

Ж.: Дөяне чалу (кадау), сыер белән сарыкны сую – сөннәт.

С.: Корбанлык хайванны үзеңә үзең чалу тиешме?

Ж.: Моны башка берәүгә дә тапшырырга мөмкин, әгәр дә үзең әйбәт чалсаң, үзеңә эшләү хәерлерәк.

С.: Корбанлык хайванга утырып йөрергә ярыймы?

Ж.: Әгәр дә моңа зарурлык булмаса, моны эшләмәү хәерлерәк.

С.: Корбанлык хайванны саварга ярыймы?

Ж.: Юк, ярамый. Ләкин сөте җыелмасын өчен җиленен салкын су белән суытырга кирәк.

С.: Әгәр дә корбанлык хайван юлда авырса яисә аңа кимчелек килсә, ягъни корбанга ярамаса, бу очракта нишләргә?

Җ.: Әгәр дә корбанлык хайван өстәмә гыйбадәт кылу өчен булса, аны суеп, итен фәкыйрьләргә таратырга кирәк. Әгәр дә вәҗиб корбан өчен булса, аны сәламәт хайван белән алыштырырга кирәк.

С.: Корбан суючының эше өчен корбанлык ит белән түләргә ярый-мы?

Җ.: Юк, корбан суючыга өстәмә түләргә кирәк.

Мөхәммәд Гашыйк Илаһи Әл-Бәрнинең

«Әт-Тәсһил әз-зарури ли мәсәил Әл-Кудури» китабыннан

Хаж

Хаҗның фарызлары, вәҗибләре һәм сөннәтләре

Хаҗның 3 фарызы бар: ихрам кию, гарәфәт тавында басып тору, тәваф кылу.

Хаҗның вәҗибләре:

1. Корбан гаетенең таңы атканда Моздәлифә үзәнлегендә басып тору.
2. Сафа һәм Мәрва таулары арасында йөгерү.
3. Таш ату.
4. Саубуллашу тәвафы.
5. Чәчне кыскарту яки бөтенләй кыру.
6. Кояш баеганчы Гарәфәт тавында басып тору.
7. Карин һәм мөтәмәттигъ өчен корбан чалу (аңлатмасы түбәндә).
8. Мөфриднең тәртибе болай: баштан таш ата, аннан соң чәчен кыра яисә кисә. Карин вә мөтәмәттигъның тәртибе: башта таш ата, аннары корбан чала, ахырдан чәчен кыра яисә кисә.
9. Зиярәт тәвафын корбан көннәренең берсендә үтәү.
10. Чәч кыру яисә кисү изге Әл-Хәрам территориясендә булырга тиеш.
11. Корбан көннәрендә хаҗ кылу.

Хаҗның сөннәтләре:

1. Карин һәм ерактан килүченең (мөфрид) килеп җитү тәвафы (тәваф кудум).
2. Тәваф өчен ихрам кигәннән соң, Сафа һәм Мәрва таулары арасында йөгерергә ниятләү.
3. Зөлхиҗәнең 8 нче көнендә Минага барып куну.

4. Гарәфә көнендә (зөлхиҗҗәнең 9 нчы көне) кояш чыкканнан соң Минадан Гарәфәт тавына чыгу.

5. Корбан чалу көнендә Моздалифәдә куну.

6. Гарәфәт тавында госел алу.

7. Корбан чалуның калган көннәрендә Минада куну.

Микатлар

(хаҗ яки гомрә кылу өчен Мәккәгә кергәндә ихрам кигән хәлдә керергә кирәк булган урыннар)

1. Мәдинә әһелләре һәм шул яктан килүчеләр өчен ул урын – Зөл-Хүләйфә;

2. Гыйрак ягыннан килүчеләргә – Зәтү-Гыйрак;

3. Сүрия һәм Ливан ягыннан килүчеләргә – Әл-Жүхфә;

4. Нәҗдә ягыннан килүчеләргә – Карнүл-Мәнәзил;

5. Йәмән ягыннан килүчеләргә – Яләмләм.

Ихрамның сөннәтләре

Ихрам – ул Аллаһны сәламләп, хаҗ яки гомрә кылырга ниятләнү. Кеше ихрамга керергә ниятләсә, аңа госел яки тәһарәт алырга, тегелгән җире булмаган ике кисәк пакь булган материал белән үзен чорнарга (бер кисәге белән билдән чорнап, икенчесен уң җилкә аша ташлап, гәүдәне чорнарга), әгәр булса, ислемай сөртергә, ябык баш белән 2 рәкәгать намаз укырга кирәк, аннан соң баш киемен салып, хаҗ кылуга ния сүзләре әйтелә: «Әллаһүммә инни уридуль-хәҗҗә фәссирһү ли вә тәкаббәлһү минни» («Йә, Аллаһ, мин хаҗ кылырга ниятләндем, аны миңа җиңеләйт һәм миннән кабул ит»).

Аннан соң Аллаһны сәламләү сүзләре әйтелә: «Ләббәйкә, Аллаһүммә, ләббәйкә, ләббәйкә лә шәрикә ләкә ләббәйкә, иннәл хәмдә вән-нигъмәтә

ләкә вәл-мулькә, лә шәрикә ләкә» («Мин Синең каршыңда, йә Аллаһ, мин Синең каршыңда, мин Синең каршыңда. Дөреслектә, хәмед Синдадыр, нигъмәт һәм куәт Синдәдер, Сиңа тиңдәшләр юктыр!») Һәрбер гыйбарәгә нәрсә дә булса өстәргә мөмкин, ләкин башка сүзләр белән бутарга ярамый. Ошбу сүзләрне әйткәннән соң, кеше ихрамга керә һәм аңа билгеле булган тыелулар йөкләнелә.

Ихрамда ниләр тыела

1. Буш сүз сөйләшү.
2. Җимагъ кылу.
3. Бәхәсләшү, тарткалашу.
4. Җирдә йөрүче хайваннарны, кошларны үтерү.
5. Ауга чыгу.
6. Ауда хайванның яшеренгән урынын әйтеп, аучыга ярдәм итү.
7. Тегелгән һәм гәүдә формасын күрсәтә торган кием кию.
8. Перчатка һәм аяк киеме кию (башмаклары булмаган очракта аяк киеменең тубыкка кадәр булган өлешен кисәргә кирәк).
9. Башны яки битне каплау.
10. Ислемай сөртү.
11. Кырыну, чәч кыскарту яки тәндәге төкләрдән арыну.
12. Тырнакларны кисү.
13. Ислемай сөртелгән һәм бизәлгән, юылмаган кием кию.

Мәккәгә керү һәм тәваф кудум

Хаҗи әл-мөфрид Мәккәгә кергәннән соң, тәһарәт алып, Әл-Хәрам мәчетенә юнәлә. Мәчетне күрүгә тәкбир, тәһлил («лә иләһә иллә Аллаһ») әйтергә, аннан соң тәваф кылырга (Кәгъбәне 7 мәртәбә әйләнергә) тиеш. Бу гамәл микатларга, чит җирләрдән килүче кешеләргә – сөннәт, һәм

ул «тәваф кудум» дип атала. Мәккә әһелләренә, микатларга, аның тирә-ягыннан килүчеләргә тәваф-кудум кылу кирәкми.

Тәваф Кәгъбәнең тыштагы почмагында булган Кара таштан башлана. Аңа йөз белән борылып, ике кулны күтәреп, тәкбир һәм тәһлил әйтергә, әгәр мөмкинчелек булса, уң кул белән ташка кагылырга яки үбәргә кирәк. Әгәр мөмкин булмаса, бер әйбер белән ташка кагылып, шул әйберне үбәргә кирәк. Әгәр бу да мөмкин булмаса, Кара ташка каршы басып, тәкбир вакытында кебек кулны колакка кадәр күтәреп, аннан соң ташка тигән кебек ишарәләп, кулларны үбәргә кирәк. Аннан сул кул як белән Кәгъбәгә борылып һәм аның ишеге ягына юнәлеп, тәваф кылына. Әл-Хатыйм стенасы артыннан үтеп (бу стена Кәгъбәнең бер кисәге тирәсендә), аннан соң Әр-Рөкнел Йәмәни почмагын үткәндә почмакка һәм таш яныннан үткән саен, ташка кагылып үтәргә кирәк. Бу тәваф 7 мәртәбә кабатлана һәм һәрбер тәваф ташка кагылудан башлап, ташка кагылу белән тәмамлана.

Тәвафтан соң 2 рәкәгать намаз укырга кирәк. Аны Ибраһим мәкамы дип аталган урында уку әйбәтрәк, ул урын Кәгъбә белән намаз укучылар арасында була. Әмма мәчетнең башка бер җирендә дә укырга ярый. Пәйгамбәребез бу намазда «Кәфирун» һәм «Ихлас» сүрәләрен укыган.

Сәгъи (Сафа белән Мәрва арасында җиңелчә йөгерү)

Тәвафның ике рәкәгать намазыннан соң, Кара таш ягына борылып, аңа кагылырга, аннан соң Сафага азрак күтәрелеп: «Иннәс-Сафа вәл Мәрватә миншәгәирилләһ» аятен укырга кирәк. Аннан соң Кәгъбә тарафына борылып тәкбир, тәһлил әйтергә һәм Пәйгамбәребезгә салават әйтергә, үз хаҗәтләреңне сорап дога кылырга һәм 3 мәртәбә: «Лә иләһә иллә Аллаһу вәхдәһү лә шәрикә ләһ, ләһүл мүлкү вә ләһүл хәмдү вә һуә галә күлли шәйин кадыйр, сәдака Аллаһу вәгъдәһу вә нәсара габдәһү вә һәзәмәл әхзәбә вәхдәһү», – дип әйтергә кирәк (мәгънәсе: «Аллаһтан башка бөек көч юк, Аңа шәриклек итүчеләр юк, мөлкәт Аныкы гына һәм

хәмед-мактаулар Аңа гына, һәм Ул һәрнәрсәдән дә кодрәтлерәк, Аллаһ үзенең вәгъдәсен тотты һәм үзенең колына җиңү бирде һәм бер Үзе гаскәрне тар-мар итте»).

Аннан соң Мәрва тарафына омтылырга һәм яшел баганага якынайгач, икенче баганага кадәр йөгерә башларга кирәк. Һәм бу вакытта: «Рабби гъфирли вәрхәм вә әнтәл әгаззуль әкраму вә тәҗәуәз гаммә тәгләм» (мәгънәсе: «Раббым, гафу ит һәм рәхимле бул, Син – иң бөек һәм юмарт, бөтен-бөтен гөнаһларыбызны гафу кыл»).

Икенче баганадан соң йөгерү атлауга күчә. Мәрвага менгәч, Сафада нәрсә эшләнелсә, монда да шул ук гамәлләр кылына. Һәм шулай 7 мәртәбә кабатлана, ягъни Сәгъи Сафадан башланып, Мәрвада тәмамлана. Сәгъи вакытында Аллаһны зикер итәргә һәм Коръән укырга, ике яшел багана арасында йөргәндә һәрберсендә йөрешне тизләтергә кирәк. Хатын-кызларга йөгерергә кирәкми.

Сафа белән Мәрва арасындагы сәгъине тәмамлагач, Хәрам мәчетендә, җәмәгатьтән аерылмыйча, биш вакыт намаз укырга кирәк, чөнки бу мәчеттә намаз уку башка мәчеттән 100 мең намаз укудан да әйбәтрәк.

Тәрвия көне туу белән, ягъни зөлхиҗҗәнең 8 нче көнендә, хаҗи Минага барып, зөлхиҗҗәнең 9 нчы көненең кояшы чыкканчыга кадәр анда калырга тиеш. Һәм шунда, җәмәгатьтән аерылмыйча, биш вакыт намаз укый.

Кояш чыкканнан соң, Гарәфәт тавына барып, кояш баеганчыга кадәр калырга кирәк. Өйләдән соң имам кешеләр белән бергә өйлә һәм икенде намазларын укый, алар алдыннан намаз уку, Гарәфәт тавында басып тору, Моздәлифәгә килү, ташларны дөрес ату, корбан чалу, ничек кырыну һәм тәваф кылу хакында ике вәгазь сөйли. Аннан соң югарыда искә алынган 2 рәкәгать намазны өйлә вакытында бер азан вә ике камәт белән укыйлар. Әбү Хәнифә хаҗ өчен ихрам кигән хәлдә һәм хаҗда имамның булуын

шарт итеп куя. Әгәр берәү, үзе генә яки имам белән хаҗ өчен булмаган намазын укыса, аңа һәрбер намазын аерым укырга кирәк.

Намаздан соң Гарәфәт тавына килеп госел алырга вә кояш батканчыга кадәр гыйбадәттә булырга кирәк. «Рәхмәт» тавына якын басып торып дога кылу – мөстәһәб. Имамга Гарәфәт тавында үз дөясендә булып дога кылырга вә хаҗ тәртипләрен өйрәтү – мөстәһәб.

Моздәлифә үзәнлегенә килү

Гарәфә көнне кояш батканнан соң хаҗи Моздәлифә үзәнлегенә китәргә һәм шунда ахшам һәм ястү намазларын азан вә камәт белән, имамга ияреп, укырга тиеш (ахшам намазы Гарәфәттә дә, Моздәлифәгә бару юлында да укылмас). Моздәлифә үзәнлегендә таң атканчы төн уздырырга, таң җиткәч, иртәнге намазны укырга вә кояш чыкканчыга кадәр Аллаһка догада булырга кирәк. «Батый Махсар» дигән урыннан кала, Моздәлифәнең теләсә кайсы җирендә булырга мөмкин.

Минага бару, таш ату, корбан чалу һәм чәч кисү

Кояш чыгарга берничә минут калгач, Мина үзәнлегенә барырга кирәк. Барып җитүче таш атарга тотына. Баганага борчактан зур булмаган 7 таш атарга кирәк. Һәрбер таш атканда «Бисмилләһи, Аллаһу әкбәр, ридан ли рахмәни вә рагъмән лишшәйтани», – дип әйтергә кирәк. Тәрҗемәсе: «Аллаһ исеме белән, Аллаһ бөек, Аллаһ ризалыгы өчен вә шайтанга каршы». Таш атканнан соң, баганадан шул минутта ук китәргә кирәк.

Хаҗи-мөфрид корбан чалмаса да була, чалса – мөстәһәб. Хаҗи-мөфрид корбан көнендә таш атканнан соң, чәчен кыра йә кыскарта. Бу эшләрне эшләгәннән соң, ихрамнан чыккан дип санала һәм якынлык кылудан башка бөтен тыелулар өстеннән төшә. Хаҗи-мөтәмәттигъ һәм карин таш атканнан соң корбан чалалар.

Зиярәт тәвафы

Зиярәт тәвафын кылу фарыз гамәлләрдән санала. Аның вакыты – 3 көн, ягъни Корбан көненнән алып, кояш чыкканнан соң, 12 нче зөлхиҗҗәнең кояшы батканчыга кадәр. Әмма корбан көнендә кылу әйбәтрәк. Чәчне кырганнан яки кыскартканнан соң, Мәккәгә барып җиде мәртәбә тәваф кылына. Зиярәт тәвафы кылганнан соң хаҗига хатыны хәләл була.

Әгәр тәваф-кудумнан соң хаҗи сәгъи кылмаган булса, бу тәвафтан соң сәгъи кылырга кирәк. Тик бу вакытта идтыйба кылынмый.

Әгәр дә зиярәт тәвафы әйтелгән көннәрдә үтәлмәсә, Әбү Хәнифә фикеренчә, корбан чалу вәҗиб була. Ә аның укучылары уенча, соңга калучылар өстенә бернәрсә дә төшми.

Корбан көннәреннән соң өч көн эчендә өч таш ату

Зиярәт тәвафыннан соң Минага кайталар вә киләсе ике көндә дә өч баганага зәвал вакытыннан соң таш атарга кирәк. Таш башта кечкенә баганага, аннан соң уртанчысына, ахырдан «җөмрәтел гъакабә» дигән зур баганага атыла. Һәр атканда тәкбир вә тәһлил әйтелә, кечкенә вә уртача таш атканнан соң, таш аткан урыннан уң тарафка юнәлеп, басып дога кылына. Җөмрәт көбра янында басып дога кылынмый, ә юлда булганда дога кылына.

Әгәр хаҗи таш атмаса, ул моны зөлхиҗҗәнең 13 нче көнендә эшли ала. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

«Берәү хаҗ кылганда Минадан ашыгып, икенче көнне Мәккәгә кайтса, аңа гөнаһ юк, берәү кичегеп, өченче көнгә калса, аңа да гөнаһ юктыр, гөнаһтан куркучылар өчен!»

«Бәкара / Сыер», 2:203

Ләкин кояш баткач, 13 нче көндә таш атмыйча торып, Мәккәдән чыгу – мәкруһ. Әгәр дә 13 нче көннең таңы атса һәм ул Минада булса, бу көндә дә аңа таш ату важиб була.

Вәдәгъ (саубуллашу) тәвафы

Таш атудан соң, хаҗи вәдәгъ тәвафы кылырга кала, аны тагын икенче төрле «Садыр тәвафы» да диләр. Бу тәваф монда яшәмәүчеләргә – вәҗиб. Мәккәгә кайтканнан соң, вәдәгъ тәвафы кылырга кирәк, шуннан соң үз ватанына кайтып китсә дә ярый. Бу тәвафта таш ату да, идтыйба да юк.

Әл-Хәрамда ниләр тыела

Әл-Хәрам территориясендә ике төрле гамәл тыела:

1. Ауга чыгу.

2. Агачларны кисү һәм үлән чабу.

Әл-Хәрам территориясендә хайван үтерелсә, үтерелгән хайван бәясе кадәр фәкыйрьләргә сәдака бирелергә тиеш.

Әгәр шәхси милектә булмаган бер тотам үлән өзелсә яки агач киселсә, ул чакта өзелгән үлән яки киселгән агач бәясе кадәр сәдака бирелер. Әгәр шәхси милектәге агач киселгән һәм кибеп бетмәгән булса, бу очракта агач бәясе кадәр сәдака бирергә һәм хуҗага китерелгән зыянны түләргә тиеш. Әгәр агач кибеп беткән булса, зыянны түләми. Изһир үләнен һәм шулай ук кипкән үлән яки агачны кисәргә ярый.

Мөхәммәд Гашыйк Иләһи Әл-Бәрнинең

«Әт-Тәсһил әз-зарури ли мәсәил Әл-Кудури» китабыннан

Нәсыйхәт

Сәүдә һәм гаделлек

Көннәрдән бер көнне сөекле Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) базарга бара. Бодай сатучы яныннан узып барганда, ул туктап, кулын бодай өеменә тыгып карый һәм бодайның аста бераз юеш булуын белеп ала. Кулын чыгарып ул сатучыдан: «Нәрсә бу?» – дип сорый. Бодай сатучы: «Йә Расүлүллаһ! Күптән түгел генә яңгыр явып китте, шуңа күрә бодай бераз юешләнде», – дип җавап бирә. Аллаһның илчесе: «Алай булгач, кешеләр күрсен өчен, юешләнгән өлешен өстә калдырырга иде», – дип таләп итә. Алга таба: «Безне алдаучы кеше бездән түгел», – дип өстәп куя.

Ислам дине кеше яшәешенең һәр тармагын колачлый. Әлеге хәдис безгә нәрсә хакында сөйли? Мөселманнар бервакытта да кешеләрне алдаган, үзләренең бер мизгеллек дөньяви файдалары өчен башкаларны ялгыш юлга этәргән кешеләр белән бергә булмаслар. Һичшиксез, Ислам дине сәүдә белән шөгыльләнүне хуплый. Расүлүллаһның әйтүе буенча, тугры сүзле, ышанычлы һәм гадел сәүдәгәрләр пәйгамбәрләр, әүлияләр һәм изге гамәлле кешеләр белән бергә кубарылачаклар. Шуңа күрә сату-алу яисә башка табыш китерә торган эшчәнлек белән шөгыльләнгән кешеләр бик гадел һәм намуслы эш итәргә тиешләр. Әгәр дә сатыла торган әйбернең берәр кимчелеге булса, сатучы ул хакта сатып алучыны кисәтергә бурычлы. Гыйбадәт кылганда үзеңне Аллаһ Тәгалә каршында басып торгандай хис итеп, ихсан белән кылырга кирәк булган кебек, сәүдә, бизнес һәм башка эш белән бәйле мөнәсәбәтләрдә дә Аллаһы Тәгалә безне һәрдаим күреп торуын истә тотарга кирәк.

Хәзрәти Гомәргә бер кешенең намуслы һәм гадел булуы хакында хәбәр итәләр. Гомәр разыйаллаһу ганһү: «Сез аның намуслылыгын һәм гаделлеген раслар өчен аның белән сәүдә мөнәсәбәтләрендә булдыгыз-

мы?» – дип сорый. Аңлашылганча, кешенең әхлакый сыйфатлары һәм тәкъвалыгы сату-алу эшләрендә чагыла.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

وَالسَّمَاءَ رَفَعَهَا وَوَضَعَ الْمِيزَانَ ﴿٧﴾ أَلَّا تَطْغَوْا فِي الْمِيزَانِ﴿٨﴾ وَأَقِيمُوا الْوَزْنَ بِالْقِسْطِ وَلَا تُخْسِرُوا الْمِيزَانَ ﴿٩﴾

«Аллаһ күкне күтәрде һәм һәрнәрсәгә гаделлек белән үлчәү куйды. Гаделлектән, дөрес үлчәүдән читкә чыкмавыгыз өчен. Үлчәүләрне гаделлек белән торгызыгыз һәм үлчәүне киметмәгез, ягъни кешегә үлчәп биргәндә киметеп үлчәмәгез һәм үзегезгә алганда арттырып үлчәмәгез!»

«Әр Рәхман / Рәхимле», 55:7-9

Шулай ук:

وَيْلٌ لِّلْمُطَفِّفِينَ ﴿١﴾ الَّذِينَ إِذَا اكْتَالُوا عَلَى النَّاسِ يَسْتَوْفُونَ ﴿٢﴾وَإِذَا كَالُوهُمْ أَو وَّزَنُوهُمْ يُخْسِرُونَ ﴿٣﴾

«Киметеп үлчәүчеләргә үкенечле каты газаптыр. Алар башка кешеләрдән берәр нәрсә үлчәп алсалар, үлчәүне тутырып, мул үлчәп алалар. Әгәр башка кешеләргә савыт яки бизмән белән үлчәп биргәндә, киметеп үлчиләр».

«Мүтаффифин / Киметүчеләр», 83:1-3

Аллаһы Тәгалә сүрәнең беренче аятендә үк, җөмләнең беренче сүзе белән зур кисәтү ясый: «вәйлүл-лил мутаффифин». «Вәйлүн» сүзе «үкенечле каты газап» дип тәрҗемә ителә. Ни өчен? Чөнки алар алдаганнарын белә торып, бу эшкә баралар. Ә бит Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Безне алдаучы кеше бездән түгел», – дип әйтте.

Бу аятьне тәфсир кылучылар болай дип әйтте: «Мондый төр кешеләр үзләренә ни дә булса алырга җыенсалар, алар аласы әйберне тулысы белән, киметмичә алалар. Ә калган кешеләргә бу товарларны саткан вакытта, алар ул товарны бераз киметеп үлчиләр (килограммлы әйберләрне үлчәүдә киметеп, тукыма ише әйберләрне метрын азайтып саталар). Бу кешеләрнең милекләрен урлау һәм аларның хакларына керү була. Әгәр дә бу сәүдәдә алдаганнар үзләре өчен генә шундый куркыныч кисәтү дип уйласалар, дөреслектә, бу аять өстендә кешеләрнең милекләрен көч белән урлаучыларга, каракларга бик нык уйланырга кирәк.

Бу аятьләрдән, хәдисләрдән сәүдә эшенең ни кадәр җаваплы хезмәт икәнен аңлап була. Сәүдә эшенә керешкән һәрбер кеше, иң башта үзенең ниятен билгеләргә тиеш. Сату-алу эшендә күңелендәге изге нияте кешене гөнаһлы юлга кереп китүдән, ин шә Аллаһ, саклап калыр. Гаиләсенең матди хәлен яхшыртам дип, сәүдә яисә башка төрле гамәл белән шөгыльләнүченең нияте дә, максаты да изге, күркәм булырга тиеш. Имам Бохари һәм Мөслимнең хәдис җыентыкларында килгән хәдистә: «Дөреслектә, гамәлләр ниятькә карап бәяләнәләр», – дип әйтелә. Ягъни кеше көндәлек эшләрен дә гыйбадәткә әйләндерә ала: йокы, ашау-эчү, гаиләндә бер-береңә яхшы мөгамәләдә булу һ.б. Сәүдә итү дә шулай ук гыйбадәткә кайтып кала, бу Аллаһы Тәгалә бер төркем мөселманнарга кушкан фарыз кифая, чөнки бөтен кеше дә сәүдәне ташласа, кешеләр ачтан үләрләр иде. Шулай ук сәүдә белән шөгыльләнүчеләрнең нияте хәерче булып, хәер сорап йөрмәү була ала. «Кем дә кем үзенә бер хәер сорау ишеген ачса, Аллаһ аңа 70 хәерчелек ишеген ачар»[1].

Сәүдә белән шөгыльләнгән һәр мөселман кешесе бу гамәлне үз гаиләсен, әти-әнисен тәэмин итеп тору өчен, шулай ук күршеләренә, туганнарына ярдәм итү йөзеннән башкарырга тиеш.

---

[1] Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан

Бервакыт иртә белән, Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) һәм аның сәхабәләре утырып торган вакытта, таза гәүдәле бер яшь егетнең үз эше белән чабып йөргәнен күрделәр. Кайберләре шунда: «Бу үзенең көчен Ислам дине өчен тотса, хәерлерәк булыр иде бит», – дип әйттеләр. Шулвакыт Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын): «Алай дип әйтмәгез. Әгәр ул үзен хәер сораудан азат итәр өчен тырыша икән, ул Аллаһы Тәгалә юлында. Һәм әгәр дә ул үзенең хәлсез әти-әнисен тәэмин итү өчен чабып йөри икән, ул Аллаһы Тәгалә юлында. Үзенең гаиләсен туендырыр өчен, дип чабып йөрсә дә, ул Аллаһы Тәгалә юлында. Әмма калганнардан байрак булыр өчен йә үзенең тәкәбберлеге аркасында чабып йөрсә, ул шайтан юлында», – дип әйткән.

Аллаһы Тәгалә дә сәүдә эшләрендәге гаделлек турында Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا تَدَايَنتُم بِدَيْنٍ إِلَىٰ أَجَلٍ مُّسَمًّى فَاكْتُبُوهُ ۚ وَلْيَكْتُب بَّيْنَكُمْ كَاتِبٌ بِالْعَدْلِ ۚ وَلَا يَأْبَ كَاتِبٌ أَن يَكْتُبَ كَمَا عَلَّمَهُ اللَّهُ ۚ فَلْيَكْتُبْ وَلْيُمْلِلِ الَّذِي عَلَيْهِ الْحَقُّ وَلْيَتَّقِ اللَّهَ رَبَّهُ وَلَا يَبْخَسْ مِنْهُ شَيْئًا

«Ий, мөэминнәр! Көтәргә вакытын билгеләп бурычка малбирсәгез, малны һәм вакытны языгыз! Бу эшләрне арагызда бер язучы гаделлек белән язсын! Яза белгән кеше язудан баш тартмасын, Аллаһ аңа язуны өйрәткәне өчен шөкер итеп язсын! Бурычка алып торучы да күпме алганлыгын һәм кайчан бирәчәген дөрес әйтеп яздырсын һәм хыянәт итәргә тәрбиячесе булган Аллаһтан курыксын, үзенең бурычларыннан һәрнәрсәне кимет еп әйтмәсен».

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:282

Күргәнебезчә, сәүдә эшеме ул, түгелме, һәрбер эштә Аллаһы Тәгалә гадел булырга куша. Бурычка алучы кеше үзенең кайчан бирәчәген

әйтергә, алай гына да түгел, аны язма рәвештә күрсәтергә тиеш. Кызганычка, бүгенге көндә без бер-беребездән: «Берничә көнгә генә бер-ике меңсум биреп тор әле», – дип, әҗәткә кереп, акча алып торырга гадәтләндек. Әмма бу гамәлләр барысы да сүздә генә кала, ягъни, бүгенге көн сүзе белән әйткәндә, расписка яздырылмый. Әлбәттә, 100 меңтурында сүз барганда, без тизрәк кәгазьгә ябышабыз. Әмма аз суммадагы килешүләр дә шулай ук язмача төзелсә, шәригатебезгә муафыйк гамәл булачак.

Шул рәвешле, гыйбадәттә күркәм әхлаклы, ихлас һәм тәкъва булырга тырышкан кебек, кешеләр белән мөнәсәбәттә, шул исәптән сәүдә эшләрендә дә, без шундый булырга тиешбез. Сату-алу эшләре белән шөгыльләнгән кеше беренче чиратта гаделлек һәм намуслылык нигезләренә таянырга тиеш. Пәйгамбәребезнең хәдисе безгә шул хакта сөйли.

«Мәрхәмәтле булмаганнар мәрхәмәткә ирешә алмас...»

Көннәрдән бер көнне Аллаһның хак хәбибе, мәрхәмәт иясе Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең оныгы Хәсәнне кулына ала һәм аны кочаклый, иркәли, үбә башлый. Шулвакыт аның янына җаһилият вакытында зур дәрәҗәләргә ирешкән Әфрабил Харис исемле кеше килә. Ул четерекле мәсьәләләрне хәл иткәндә чакырыла торган казый була, һәм гадел хөкем итәргә омтылуы белән дан казана. Пәйгамбәрнең оныгын иркәләвен күргәч, ул: «Йә Расүлүллаһ! Йә Мөхәммәд! Минем ун балам бар, ләкин мин аларның берсен дә үпкәнем юк», – дип әйтә. Пәйгамбәребез моңа: «Мәрхәмәтле булмаганнар мәрхәмәткә ирешә алмас. Кечкенәләргә карата йомшаклык белән, яратып, олыларга карата хөрмәт белән карамаган кеше бездән булмас», – дип җавап бирә.

Ярату бик мөһим. Кечкенә балалар моңа аеруча мохтаҗ. Аллаһның илчесе үзенең өммәтен дә һәрвакыт бер-берсен якын итәргә, бер-берсен яратырга чакырган. Ярату һәм мәрхәмәтлек күрсәтү бала тәрбиясенең аерылгысыз бер шарты булып тора.

Бер көнне Аллаһның илчесе янына бәдәви гарәпләрдән булган бер кеше килә һәм: «Йә Мөхәммәд! Димәк, сез балаларыгызны үбәсезме?» – дип сорый. «Әйе, әлбәттә», – дип җавап бирә Расүлүллаһ. Бәдәви аңа: «Без исә беркайчан да үпмибез», – дип әйтә. Пәйгамбәребез: «Аллаһ Сөбхәнә вә Тәгалә сезнең йөрәгегезгә аз булса да ярату һәм мәрхәмәт хисен салмаган икән, мин нәрсә эшли алыйм?!» – дип әйтә. Шуңа күрә балаларга карата мәрхәмәтле булырга, аларны яратырга кирәк. Балаларның үзаңнарын үстерүнең иң төп һәм мөһим нигезе булып нәкъ менә ярату хисе тора. Бөтен галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән Аллаһның илчесе үзенең сәхабәләренә һәм шулай ук безгә дә шул принципны аңлатып калдырган. Без балаларны бик яраткан Пәйгамбәрнең иярүчеләре. Аны үзебезгә

үрнәк итеп алганбыз икән, без аның юлыннан барырга, балаларыбызга карата мәрхәмәтле һәм яратучан булырга омтылырга тиешбез.

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) болай дип әйтә торган булган: «Мин еш кына намазымны озаграк итеп укырга ниятләп баса идем, ләкин җәмәгать арасында елаган бала тавышларын ишетсәм, намазымны кыскарта торган булдым».

Расүлүллаһның балаларны яратуы аның көндәлек тормышында бик ачык чагыла иде. Ул аларны иңнәренә утыртып йөрткән, алар белән шаярган һәм уйнаган, үзе башлап сәлам бирә торган булган. Башкаларга Пәйгамбәр: «Баласы булган кеше баласы белән үзе дә бала кебек булсын», – дип киңәш итә торган булган. Бер көнне ул кошын ерткыч хайваннар алып киткән баланың кайгысын уртаклашырга бара. Кайвакыт авырып киткән балаларның хәлен белергә чыгып китә торган була. Шуңа күрә балалар да аны бик каты яратканнар.

Бәйрәм көннәренең берсендә кечкенә бер малай бер читтә елап утырган була. Пәйгамбәребез аның янына килеп, нигә елаганын сорый. Бу бала: «Минем әтием дә, әнием дә юк», – дип җавап бирә. Аллаһның илчесе (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булсын) бу баланың башыннан сыйпап: «Әгәр теләсәң, бүгеннән башлап синең әтиең Мөхәммәд, әниең Гайшә, апаң Фатыйма булыр», – дип әйтә. Бала да: «Әлбәттә, Расүлүллаһ, мин моны бик телим», – дип җавап бирә. Һәм Пәйгамәр аны җитәкләп: «Алай булгач, әйдә минем белән», – дип аны алып китә һәм үзенең өенә алып кайтып, аны ашата, шатландыра, иркәләп сөя.

Ятим балаларны шатландыра белү бигрәк тә әһәмиятле. Аеруча бүгенге көндә, чөнки җәмгыятебездә начар холыклар һәм золым бик киң таралган. Баланы гел ачуланып тормыйча, нәфрәт һәм золымнан саклап, ярату һәм мәрхәмәт эчендә игътибар биреп үстерү – менә нәрсә әһәмияткә ия. Шул очракта гына без өммәтебезнең һәм шулай ук бөтен кешелек дөньясының бәхетен кайгырткан булабыз.

Коръән кыйссалары: «Сөеклеләр һәм көнчеләр турында»

Коръән ул – гади генә китап түгел, ул вакытлар узуга бәйле булмаган һәм барлык мөселманнар тарафыннан яратылып укыла торган әсәр. Ул һәр укучысының шәхесен формалаштыра һәм аның рухи дәрәҗәсен күтәрә. Әмма Кәлам шәрифтә сөйләнгән күпсандагы вакыйгаларның мәгънәләренә төшенү, аларны сиземләү һәм аңлау сәләте һәр кешегә дә бирелми. Шуңа күрә, мин әлеге китап буенча үземнең белемнәремне уртаклашырга телим, ә яхшылык һәм яманлык, дөреслек һәм ялган арасындагы каршылыклар турында мавыктыргыч һәм гыйбрәтле хикәятләр анда бихисап. Әнә шул сәбәпле мин «Коръәндәге кыйссалар» циклыннан пәйгамбәрләребез тормышы турында сайланма сюжетларга берничә мәкалә багышларга исәплим. Сез үзегез дә инанырсыз: аларның һәммәсе маҗараларга һәм сынауларга бай һәм, билгеле, Аллаһының Гафу итүче һәм Бар яктан камил зат булуына ышану белән сугарылган. Шулай итеп, беренче Коръән кыйссасы – Йосыф галәйһис-сәләм турында.

«Иң яхшы кыйсса»

«Әхсанел-кыйсса» («Иң яхшы риваять») исемен алган һәм бик күп гыйбрәтле мисалларга ия булган әлеге тарихи вакыйга турында Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйткән:

لَّقَدْ كَانَ فِي يُوسُفَ وَإِخْوَتِهِ آيَاتٌ لِّلسَّائِلِينَ ﴿٧﴾

«Тәхкыйк, сораучыларга Йосыф вә аның кардәшләренең кыйссаларында, әлбәттә, гыйбрәтләр бар».

«Йосыф», 12:7

Ягъкубның галәйһис-сәләм унике баласы арасыннан иң яратканы – сурәтләп, язып бетереп булмаслык матурлыкка ия Йосыф булган. Йосыфтан галәйһис-сәләм соң Ягъкуб барлык балаларынннан да ныграк үзенең кечкенә улы Бинйәминне яраткан. Башка тугыз балалары Ягъкубның башка хатыннарыннан булган. Әнә шул сәбәпле һәм үзләренең көнчелеге аркасында, әлеге тугыз угыл Йосыфны һәм Бинйәминне ят күргәннәр һәм алар турында искә төшереп, «Йосыф һәм аның абыйсы...» дип әйткәннәр...

Йосыфның һәм Бинйәминнең әнисе вафат булганнан соң, Ягъкуб галәйһис-сәләм аларга тагын да күбрәк игътибар бирә башлый. Аның калган улларын көнчелек һәм хөсетлек хисе биләп ала, әлеге хис көннәнкөн ныграк үсә бара һәм ахырдан нәфрәткә, дошманлыкка ... аннары Йосыфтан котылу уена кадәр үсеп җитә. Аллаһы Тәгалә бу хакта Коръәндә болай дип әйтә:

إِذْ قَالُوا لَيُوسُفُ وَأَخُوهُ أَحَبُّ إِلَىٰ أَبِينَا مِنَّا وَنَحْنُ عُصْبَةٌ إِنَّ أَبَانَا لَفِي ضَلَالٍ مُّبِينٍ ﴿٨﴾ اقْتُلُوا يُوسُفَ أَوِ اطْرَحُوهُ أَرْضًا يَخْلُ لَكُمْ وَجْهُ أَبِيكُمْ وَتَكُونُوا مِن بَعْدِهِ قَوْمًا صَالِحِينَ ﴿٩﴾

«Йосыфның олуг кардәшләре әйттеләр: «Әлбәттә, Йосыфны вә аның кардәше Бинйәминне атабыз бездән артыграк сөя, без кәсепче вә хезмәтчеләрбез, атабызны да без тәрбиялибез, Йосыфлардан бер файда күрмәсә дә, аларны бездән артык күрәдер. Тәхкыйк, атабыз безнең хакта ачык ялгышадыр». Агалары җыелып сөйләштеләр вә бәгъзеләре әйтте: «Йосыфны үтерегез яки билгесез бер урынга илтеп ташлагыз, аннары атагызның йөзе сезгә генә калыр, башкача һич карамас, шуннан соң тәүбә итеп, яхшы кешеләрдән булырсыз».

«Йосыф», 12:8-9

Әлеге аятьләрдән аңлашылганча, агалары үзләренең сан ягыннан күп булуларын әтиләре мәхәббәтеннән күпкә лаеклырак санаганнар.

Йосыф галәйһис-сәләм үзе сурәтләп бетереп булмаслык матурлыкка ия булган – бу турыда «бар булган нәрсәләрнең ярты матурлыгына» дип әйтелә. Ул беркемне дә битараф калдыра алмый. Моннан тыш, Йосыф бары тышкы матурлыгы белән генә түгел, саф күңеле белән дә нурланган була. Аның эчке дөньясы да тышкы гүзәллеге кебек күркәм була. Шуңа күрә бик тә табигый ки, үз балаларыннан Ягъкуб бигрәк тә Йосыфны ярата – ул үзенең әхлагы һәм тәкъвалыгы белән аерылып тора, бу сыйфатлар исә аның абыйларында җитенкерәми.

Ә Ягъкуб? Зирәк һәм алдан күрүчән кеше, ул пәйгамбәр була. Шуңа да карамастан, уллары аның турында да ихтирамсызлык күрсәтеп сөйләүгә юл куялар: «Безнең әтиебез ачыктан-ачык адашуда», – диләр.

Йосыф төш күрә

Йосыф турында сюжет линиясендә мөһим рольне төш күрүләр уйный. Бервакыт төнлә Йосыф галәйһис-сәләм төшендә унбер йолдыз, кояш һәм айның аңа сәҗдә кылуын күрә. Йосыф уянуга ук, тиз арада күргәннәрен әтисенә сөйли. Бу хакта Коръәндә түбәндәгеләр әйтелә:

إِذْ قَالَ يُوسُفُ لِأَبِيهِ يَا أَبَتِ إِنِّي رَأَيْتُ أَحَدَ عَشَرَ كَوْكَبًا وَالشَّمْسَ وَالْقَمَرَ رَأَيْتُهُمْ لِي سَاجِدِينَ ﴿٤﴾ قَالَ يَا بُنَيَّ لَا تَقْصُصْ رُؤْيَاكَ عَلَىٰ إِخْوَتِكَ فَيَكِيدُوا لَكَ كَيْدًا ۖ إِنَّ الشَّيْطَانَ لِلْإِنسَانِ عَدُوٌّ مُّبِينٌ ﴿٥﴾

«Йосыф атасына әйтте: Ий атам, мин төшемдә күрдем: унбер йолдыз һәм ай белән кояш көлеп миңа сәҗдә кылдылар». Атасы әйтте: «Ий углым, син төшеңне агаларыңа сөйләмә! Әгәр аларга сөйләсәң, хөсетләнеп сине һәлак итәр өчен хәйлә кы-

лырлар, чөнки шайтан адәмнәргә ачык дошман, агаларыңны хәйләгә котыртыр».

«Йосыф», 12:4-5

Ягъкуб галәйһис-сәләм бернинди шиксез ышана: аның улы бөек мәртәбәләргә ирешә, дөнья һәм ахирәт тормышында югары дәрәҗәләргә күтәрелә, һәм абыйлары аның кул астында булалар һәм буйсыналар. Әтисе улын куркынычлыктан кисәтә һәм аңа төшендә күргәннәрен сөйләмәскә киңәш итә.

Әмма, ни кызганыч, әлеге төш турында бертуган абыйларга билгеле була. Аларның көнчелек белән томанланган башларында Йосыфтан ничек котылырга дигән уй бер дә тынгылык бирми.

Бервакыт ачык төшне Ягъкуб галәйһис-сәләм үзе дә күрә: ун бүре Йосыфка ташланалар. Ягъкубны куркытып торган борчулар бик тиз арада тормышка аша. Абыйлары Йосыфны үзләре белән дала буйлап сәфәргә алып чыгалар.

قَالَ إِنِّي لَيَحْزُنُنِي أَن تَذْهَبُوا بِهِ وَأَخَافُ أَن يَأْكُلَهُ الذِّئْبُ وَأَنتُمْ عَنْهُ غَافِلُونَ ﴿١٣﴾

«Аталары әйтте: «Йосыфны алып китүегез мине кайгы вә хәсрәткә төшерә, мин аңардан башка сабыр итә алмыйм, аннары аны бүре ашаудан да куркамын вә сез Йосыфтан гафил йөрерсез».

«Йосыф», 12:13

Асылда, Ягъкуб галәйһис-сәләм бүреләрдән түгел, ә үзенең улларыннан курыккан, әмма аларның үзсүзлелегенә каршы тора алмый һәм Йосыфка да алар белән китәргә рөхсәт бирә.

«Күз яшьләренә алданма...»

Өеннән һәм әтисеннән ераクта, далада, каты мыскыллауларда соң Йосыф иске коега ыргытыла. Нәкъ менә шул вакытта Аллаһы Тәгалә Йосыфка ачыш биреп түбәндәгеләрне җиткерә:

فَلَمَّا ذَهَبُوا بِهِ وَأَجْمَعُوا أَن يَجْعَلُوهُ فِي غَيَابَتِ الْجُبِّ ۚ وَأَوْحَيْنَا إِلَيْهِ لَتُنَبِّئَنَّهُم بِأَمْرِهِمْ هَٰذَا وَهُمْ لَا يَشْعُرُونَ ﴿١٥﴾

««Йосыфны алып киткәч, аны кое төбенә салырга итфак кылдылар һәм күлмәген салдырып, үзен кое төбенә төшерделәр, күлмәген сорагач: «Унбер йолдыз, ай вә кояш бирсеннәр», – дип көлделәр. Без Йосыфка вәхи кылдык: «Бу җафалардан, әлбәттә, бер көнне котылырсың да, сиңа кылган явызлыкларын үзләренә сөйләрсең», – дип, ләкин алар Йосыфка вәхий кылганыбызны сизмиләр».

«Йосыф», 12:15

Үзләренең җинаятьләрен яшерү өчен, Йосыфның агалары аның күлмәген чалынган бәрән канына буйыйлар һәм күз яшьләре белән әтиләренә алып киләләр. Хикмәткә ия борынгылар әйткәннәр: «Кайгысы белән зарланганнарның яшьләренә алданма. Үзләрен күз яше агызучы итеп күрүчеләр арасында күпме явызлар бар. Йосыфның агалары түккән күз яшьләре турында уйла. Алар дөм караңгы төндә каты кычкырып елап әтиләре янына килделәр. Әмма алар моны үз аңлатмаларын ачып салу өчен түгел, бәлки кылган явызлыкларын күрсәтү өчен эшләделәр».

– И, әтиебез! – дип мөрәҗәгать итте уллары. – Без ярыш оештырдык, ә Йосыф безнең әйберләрне карап торырга тиеш иде. Без кире әйләнеп килгәндә аны бүре ашап бетергәнлегенә тап булдык.

Йосыфның канга баткан, әмма ертылмаган киемен күреп, Ягъкуб галәйһис-сәләм аны үз битенә куя.

Ачы көлеп, ул болай ди:

– Нинди мәрхәмәтле бүре булган бу. Ул минем улымны ашап бетергән, ә аның күлмәген ертмаган да.

Йосыфның агалары әтиләреннән үз хәйләләрен яшерәләр, әмма алар алып килгән күлмәк аларның ялганлавы турында сөйли.

وَجَاءُوا عَلَىٰ قَمِيصِهِ بِدَمٍ كَذِبٍ ۚ قَالَ بَلْ سَوَّلَتْ لَكُمْ أَنفُسُكُمْ أَمْرًا ۖ فَصَبْرٌ جَمِيلٌ ۖ وَاللَّهُ الْمُسْتَعَانُ عَلَىٰ مَا تَصِفُونَ ﴿١٨﴾

«Йосыфның күлмәген ялган канга буяп аталарына китереп бирделәр. Аталары әйтте: «Юк, Йосыфны бүре ашамагандыр, бәлки нәфесегез бер хәйләне сезгә яхшы итеп күрсәткәндер дә, сез аны кылгансыз, инде миңа күркәм сабырлык кирәк! Сезнең хәйләгезгә каршы Аллаһыдан ярдәм сорыймын».

«Йосыф», 12:18

Коедан – йөрәк түренә

Йосыфның бәхетенә, коедан ерак түгел генә Мисырга юнәлә торган кәрван узган. Шул кәрваннан ике кеше Йосыфны табып алалар. Әмма коедан ул коллар, әсирләр сатыла торган базарга эләгә, аны Мисыр хакиме вәзире сатып ала. Үз балалары булмаганлыктан, аның йөрәгендә аталарга хас кайгырту хисләре уяна. Гадел, тәрбияле, югары әхлаклы, тәртипле Йосыф яңа гаиләдә дә, хәтта Мисырның хөкүмәт сараендагы кешеләр арасында да алмазга тиң яратылуга ия була, вакытлар узу белән вәзир янәшәсендә үзенең лаеклы урынын ала.

Әмма төп сюжет линиясе Йосыф белән вәзирнең Зөләйха исемле хатыны арасында үстерелә. Мисырның иң матур хатын-кызларының берсе булган Зөләйха кияүгә чыккан чы ук төш күрә. Ул төшендә ай нуры уза торган якты йолдызга әверелә. Әлеге төшнең Йосыф турында икәнен Зөләйха белми һәм төшне үзенчә юрый: вәзир тарафыннан кияүгә чыгар-

га ясалган тәкъдимгә уңай җавап кайтара. Сөюдән яну хисе соңрак килә... Аның йөрәге ире өенә алып кайткан акыллы, ягымлы, яшь матур егеткә тартыла.

Үз хисләре белән җәфаланган һәм бу хәлдән бернинди чыгу юлын күрә алмаган Зөләйханы хәтта җитмеш дөягә төяргә мөмкин булган кыйммәтле әйберләр дә шатландыра алмый. Ул, бернигә дә карамыйча, Йосыфка булган мәхәббәте өчен көрәшне дәвам итә.

Бөек сынау

Зөләйханың җавапсыз мәхәббәте тиз арада кайгы-хәсрәт, борчу-сагышка үсә һәм аның акылыннан өстен чыга – ул үзенең матурлыгын сөйгәненең игътибарын яулап алуда файдаланырга уйлый. Бер тапкыр, иң матур күлмәген киеп, Зөләйха Йосыф галәйһис-сәләмне үзенә чакыра. Йосыф башын иеп аның алдында басып тора, ә ул гаҗәеп караш ташлый. Коръәндә аларның шушы очрашулары турында болай диелә:

وَرَاوَدَتْهُ الَّتِي هُوَ فِي بَيْتِهَا عَن نَّفْسِهِ وَغَلَّقَتِ الْأَبْوَابَ وَقَالَتْ هَيْتَ لَكَ ۚ قَالَ مَعَاذَ اللَّهِ ۖ إِنَّهُ رَبِّي أَحْسَنَ مَثْوَايَ ۖ إِنَّهُ لَا يُفْلِحُ الظَّالِمُونَ ﴿٢٣﴾

«Вәзир хатыны Зөләйха үз өеңдә Йосыфтан ялынып вә ялварып нәфесе теләгәнне үтәвен таләп итте вә барча ишекләрне бикләде һәм: «Ий Йосыф, кил минем яныма, мине мәхрүм итмә», – диде. Йосыф әйтте: «Бу эштән Аллаһка сыгынамын, тәхкыйк тәрбиячем Газиз миңа хөрмәт күрсәтте, торачак җиремне күркәм кылды, инде мин аңар ничек хыянәт итим! Бу эшне кылсам залимнәрдән булырмын бит, әлбәттә, залимнәр Аллаһ газабыннан котыла алмаслар».

«Йосыф», 12:23

Бу аятьтән аңлашыла ки, Йосыф галәйһис-сәләм Зөләйханың тәкъдимен кире кага. Зөләйха үзенең матурлыгын, гүзәллеген Йосыфны гөнаһка алып бару өчен ничек кенә файдаланырга тырышмасын, бу эш мөмкин булмый. Зөләйхага: «Мин Аллаһтан куркам һәм үземнең Хуҗама хыянәт итмим», – дип әйтеп, ул үзе ишеккә таба юнәлә, ә аның йөрәге сагыштан сыкрый. Зөләйха, Йосыфның шундый килеш-килбәтеннән кире кагылганнан соң, җәһәт адымнар ясый, аның күлмәген ертып ташлый, һәм шул мизгелдә бүлмәгә... аның ире килеп керә.

Коръәндә бу хакта түбәндәгеләр әйтелә:

وَاسْتَبَقَا الْبَابَ وَقَدَّتْ قَمِيصَهُ مِن دُبُرٍ وَأَلْفَيَا سَيِّدَهَا لَدَى الْبَابِ ۚ قَالَتْ مَا جَزَاءُ مَنْ أَرَادَ بِأَهْلِكَ سُوءًا إِلَّا أَن يُسْجَنَ أَوْ عَذَابٌ أَلِيمٌ ﴿٢٥﴾

«Икесе дә ишекләргә таба йөгерделәр. Йосыф Зөләйхадан котылыр өчен йөгерде, Зөләйха Йосыфны чыгармас өчен артыннан йөгерде, Йосыфның күлмәгенең артыннан тотып үзенә тартты, күлмәк ертылды. Йосыф ишекләргә килгәндә бикле ишекләр Аллаһ кодрәте белән ачыла бардылар. Шулай куышып ишек алдына чыксалар, Зөләйханың ире Газизгә очрадылар. Зөләйха үзенең иренә әйтте: «Синең хатыныңа яман касд кылган кешегә җәзасы нәрсә булыр? Әлбәттә, төрмәгә бикләү яки рәнҗетә торган газап булыр».

«Йосыф», 12:25

Вәзиргә якын булган кеше әлеге вакыйганы аңларга ярдәм итә:

قَالَ هِيَ رَاوَدَتْنِي عَن نَّفْسِي ۚ وَشَهِدَ شَاهِدٌ مِّنْ أَهْلِهَا إِن كَانَ قَمِيصُهُ قُدَّ مِن قُبُلٍ فَصَدَقَتْ وَهُوَ مِنَ الْكَاذِبِينَ ﴿٢٦﴾

«Әгәр Йосыфның күлмәге ал яктан ертылган булса, Зөләйха сүзе дөрес булыр, Йосыф сүзе ялган булыр. Әгәр Йосыфның күлмәге

арт яктан ертылган булса, Зөләйха сүзе ялган булып, Йосыф сүзе дөрес булыр».

«Йосыф», 12:26

Йосыфның гаепле булмаганына ышанган хәлдә, вәзир үз хатынынан таләп итә:

وَاسْتَغْفِرِي لِذَنبِكِ ۖ إِنَّكِ كُنتِ مِنَ الْخَاطِئِينَ ﴿٢٩﴾

«Син Зөләйха тәүбә ит, миннән гафу сора гөнаһың өчен! Тәхкыйк, син хаталанучылардан булгансың».

«Йосыф», 12:29

Йосыф галәйһис-сәләм янәдән төрмәдә

Әмма мәхәббәт өчпочмагыннан Йосыфка шулай да уңышлы котылу насыйп булмый. Хатынының хыянәтеннән интегүче вәзирне яңа һөҗүм көтә: Зөләйханың хисләре, булып узган вакыйгаларны яшерергә омтылыш булуга карамастан, Мисырның барлык почмакларында бу хәлләр гайбәт булып сөйләнә башлый. Һәм ул җитди адымга барырга карар кыла: Йосыфны күрсәтер өчен, затлы нәселдән булган хатын-кызларны өстәл янына җыя. Ул нәрсә буласын чамалый: аның матурлыгы кунакларга бик көчле тәэсир итә, алар аннан бер дә күзләрен ала алмыйлар, һәм җиләк-җимешләрне чистартканда, хәтта сизмәстән үзләренең кулларын кисәләр:

حَاشَ لِلَّهِ مَا هَٰذَا بَشَرًا إِنْ هَٰذَا إِلَّا مَلَكٌ كَرِيمٌ ﴿٣١﴾

«Аллаһ пакьтер, бу кеше түгелдер, бу һичкем түгел, мәгәр хөрмәтле фәрештәдер».

«Йосыф», 12:31

Хатын-кызлар бердәм рәвештә Зөләйхага теләктәшлек күрсәтәләр.

Әмма Зөләйха үзе һәм вәзир әлеге мәхәббәт һәм гайбәт тарихыннан һичнинди башка котылу юлын күрмиләр: Йосыфны төрмәгә ябалар. Ләкин, ни генә булмасын, чынлыкта, Зөләйха югары әхлакка ия һәм бик тә зирәк хатын-кыз була. Әмма Йосыфка булган кайнар мәхәббәте аны аек акылдан, фикерләү сәләтеннән мәхрүм итә. Зөләйха аерылышуның авырлыклардан котылырга ярдәм итәчәгенә ышана, вәзир исә үз гаиләсенең намусын сакларга тели.

Йосыф галәйһис-сәләм төрмәдә озак утыра. Ә Зөләйха һәм вәзир бу чакта «намус төрмәсендә» ябылып калалар: алар гаепсез кешене котыртуларын аңлыйлар. Зөләйха шулкадәр җәфалана ки, хәтта үзенең матурлыгын һәм яшьлеген югалта. Һәм бу аның үзенең нәфесе һәм Йосыфка карата булган хисләренә җавап кайтаруы була. Әмма күз яшьләре һәм ихлас күңелдән тәүбә итүе сәбәпле, ул әлеге гөнаһтан пакьләнә.

Күптән көтелгән ирек һәм хаклыкның өскә чыгуы

Йосыф галәйһис-сәләм үзенең хак юлга чакыру, киңәш бирү һәм инандыру эшчәнлеген хәтта иректә булмаган чакта да дәвам итә, ул төрмәне мәдрәсәгә әверелдерә. Монда аның төшләрне юрау сәләте дә ачыла.

Тәкъдиренә язганга күрә, Йосыф галәйһис-сәләм белән тоткында бергә тагын Мисыр хакиме ялчысына якын торган кешеләр – эчемлекләр ташучы һәм пешекче була. Алар үзләренең төшләрен Йосыф белән уртаклашалар: берсе ничек итеп йөземне изеп суын алуны, ә икенчесе – башында ипи алып баруны һәм аны кошлар чукуын күрә. Йосыф сүзен кыска тота:

يَا صَاحِبَيِ السِّجْنِ أَمَّا أَحَدُكُمَا فَيَسْقِي رَبَّهُ خَمْرًا ۖ وَأَمَّا الْآخَرُ فَيُصْلَبُ فَتَأْكُلُ الطَّيْرُ مِن رَّأْسِهِ ۚ قُضِيَ الْأَمْرُ الَّذِي فِيهِ تَسْتَفْتِيَانِ ﴿٤١﴾

«Берегез зинданнан чыгып әүвәлге урынында хәмер ясаучы булыр, әмма икенчегезне асарлар вә башын кошлар ашар. Сез сорадыгыз – мин җавап бирдем, әлбәттә, эш мин тәгъбир кылганча булыр».

«Йосыф», 12:41

Шулай килеп чыга да. Күпмедер вакыт узганнан соң, пешекчене үлем җәзасына тарталар, ә эчемлекләр йөртүчене гафу итәләр, төрмәдән чыгаралар һәм ул янәдән хакимнең ялчысы булып эшли башлый. Йосыф галәйһис-сәләм белән хушлашып, ул аның турында хуҗасы алдында искә алырга вәгъдә бирә, әмма оныта һәм Йосыф төрмәдә берничә елга кала әле... Мисыр хакименең үзенә төшләр кергәнчегә хәтле...

Аларны юрау бернинди астрологларга, күрәзәчелек кылучыларга һәм акыл ияләренә дә бирелми. Бары онытылган тоткын гына барлык баш ватулардан азат итә – ул Йосыф булып чыга, бу хакта эчемлекләр йөртүче искә төшереп җиткерә.

– И, Йосыф! Җиде ябык сыер җиде таза сыерны кабып йотканны, ә җиде коры башак җиде яшел башакны ашаганны ничек юрарга? Мин синең төш юравыңны тапшырачакмын, һәм сине төрмәдән чыгарырлар, – дип мөрәҗәгать итә аңа эчемлекләр ташучы.

Йосыф галәйһис-сәләм хакимнең төшен юрый: «Җиде таза сыер һәм җиде яшел башак җиде ел муллыкта яшәүне аңлата. Аннары җиде ел ачлык һәм коточкыч корылык киләчәк. Беренче җиде елда күбрәк чәчегез, ә уңышны җыеп алу вакыты җиткәч, үзегезгә туклану өчен кирәк булган кадәрен җыеп алыгыз, ә калганын башакларда калдырыгыз һәм амбарларга кертеп урнаштырыгыз. Ә ачлык җиткәч, сез әлеге ашлыкны кул-

лана алачаксыз. Җиде еллык ачлыктан соң муллык еллары җитәчәк һәм кешеләр янәдән имин, бәхетле тормышка ирешәчәкләр».

Хаким Йосыф галәйһис-сәләмнең хикмәтен югары бәяли һәм аны, барлык кешеләргә гаепсез булуын игълан итеп, азат итә. Йосыфның гаебе булмавын аның төрмәгә ябылуына катнашы булучыларның барысы да раслый. Алар арасында Зөләйха да була. Ул бик тә ялварып үзенең җинаятен һәм Йосыфка булган мәхәббәтен аңлата:

الْآنَ حَصْحَصَ الْحَقُّ أَنَا رَاوَدتُّهُ عَن نَّفْسِهِ وَإِنَّهُ لَمِنَ الصَّادِقِينَ ﴿٥١﴾

«Менә хәзер хаклык өскә чыкты, Йосыфның миңа якынлык кылуын мин үзем өстәдем, әмма Йосыф хыянәт итмәде, аның сүзләре хак».

«Йосыф», 12:51

Ә Йосыф, үзенең югары әхлакый сыйфатларга ия булуы, алдан күрүчәнлеге һәм туры сүзле булуы сәбәпле, баш казначы итеп билгеләнә һәм... тол калган Зөләйхага өйләнә. Аңа Аллаһның рәхмәте белән яшьлеге һәм матурлыгы кире кайта.

«Авырлыктан соң Аллаһы Тәгалә җиңеллек бирә»

Йосыф галәйһис-сәләм үзе, Мисыр хакименең баш вәзире булып, барлык ил кешеләренең хөрмәтен казана. Йосыф галәйһис-сәләмнең тырышлыгы белән Мисыр җиде еллык корылыкны имин рәвештә кичерә. Киресенчә, күрше дәүләтләр авыр хәлдә кала, анда яшәүчеләр, ачлыктан интегеп, Мисырга барырга омтылалар. Алар арасында Йосыфның Филистыйнда яшәүче абыйлары да була. Туганнар белән очрашу көтелмәгәндә була, һәм Йосыф галәйһис-сәләм аларны гафу итә:

قَالَ لَا تَثْرِيبَ عَلَيْكُمُ الْيَوْمَ ۖ يَغْفِرُ اللَّهُ لَكُمْ ۖ وَهُوَ أَرْحَمُ الرَّاحِمِينَ ﴿٩٢﴾

«Бүген сезне гаепләп битәрләү юк, курыкмагыз, мин сезне хөкем итмим. Кылган гөнаһларыгызны Аллаһы ярлыкасын, Ул бик шәфкатьле вә рәхимле!»

«Йосыф», 12:92

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай ди:

وَرَفَعَ أَبَوَيْهِ عَلَى الْعَرْشِ وَخَرُّوا لَهُ سُجَّدًا ۖ وَقَالَ يَا أَبَتِ هَٰذَا تَأْوِيلُ رُؤْيَايَ مِن قَبْلُ قَدْ جَعَلَهَا رَبِّي حَقًّا ۖ وَقَدْ أَحْسَنَ بِي إِذْ أَخْرَجَنِي مِنَ السِّجْنِ وَجَاءَ بِكُم مِّنَ الْبَدْوِ مِن بَعْدِ أَن نَّزَغَ الشَّيْطَانُ بَيْنِي وَبَيْنَ إِخْوَتِي ۚ إِنَّ رَبِّي لَطِيفٌ لِّمَا يَشَاءُ ۚ إِنَّهُ هُوَ الْعَلِيمُ الْحَكِيمُ ﴿١٠٠﴾

«Йосыф үзенең Мәнзилендә ата-анасын хөрмәтләп тәхеткә утыртты, аннары Йосыфны зурлап шөкер йөзеннән барчасы сәҗдәгә егылдылар, вә Йосыф әйтте: «Ий атам, күп еллар элек күргән төшемнең тәэвиле ошбудыр, тәхкыйк Раббым бу төшемне дөрес кылды вә тәхкыйк Раббым миңа ихсан кылды, мине зинданнан чыгару белән вә сезне сәхрәдән Мисыргa китерү белән минем белән кардәшләрем арасына шайтан вәсвәсә белән дошманлыкны салганы соңында, тәхкыйк Раббым теләгән нәрсәсен шәфкать белән кылучы, әлбәттә, Ул белүче вә тиешенчә эш кылучы».

«Йосыф», 12:100

Аллаһның рәхмәте белән Йосыф барлык авырлыкларны имин уза һәм күркәм сыйфатлар, гамәлләр белән бүләкләнә: көч, байлык һәм хакимият. Аллаһы – бар нәрсәгә дә көче җитүче Зат. Ул һәрвакытта да Үзенә иман китергән, итагатьлелек күрсәткән, ихластан ислам диненә хезмәт иткән колларына булыша. Мөселманнарның бурычы булып иманлы булу, туры юлдан тайпылмау һәм ныклык күрсәтү тора. Мөселманнарны авыр-

лыклардан соң һәрвакытта да иминлек һәм бәхетле тормыш көтә. Коръән безгә бу хакта турыдан-туры әйтә:

سَيَجْعَلُ اللَّـهُ بَعْدَ عُسْرٍ يُسْرًا ﴿٧﴾

«Аллаһы Тәгалә авырлыктан соң җиңеллек урнаштырачак».

«Талак», 65:7

فَإِنَّ مَعَ الْعُسْرِ يُسْرًا ﴿٥﴾

«Дөреслектә, файдалы булган җиңеллек авырлыктан соң».

«Инширах / Ачмак», 94:5

Камил хәзрәт Сәмигуллин,

Татарстан Республикасы мөфтие

Әдәби сәхифә

Яшел күлмәк

Без очрашканда азан яңгырый иде.

– Әйдә, сине мәчеткә алып барам. Бүген җомга бит, үзең беләсең, – дидем.

– Син минем мәчеткә йөрмәгәнемне беләсең бит, – диде.

– Белүен беләм дә, ләкин сәбәбе ни икәнен аңламыйм, – дидем.

– Каян белим, менә шулай. Булмый инде миннән, – диде. – Бәлки җәмгыятьнең тәэсиредер... Моннан тыш, шулкадәр тырышып үтүкләгән чалбарым бозылыр, тезләре ышкылыр дип куркамын.

Шулай дигәч, ихтыярсыз көлергә тотындым.

– Һаман шаяртасыңмы? – дидем. – Мәчеткә йөрмәүнең сәбәбе шулмы?

– Чынлап әйтәм. Үзең беләсең бит, мин киемгә карата бик игътибарлы, бигрәк тә яшел төстәге киемнәремне аеруча саклап тотам.

Дөрестән дә, кигән кайсы киемен генә алма, алар берсеннән берсе матур һәм яхшылап үтүкләнгән булыр иде. Яшел төснең дә нинди генә тоннарын сайламый торган иде.

– Ярый, алайса... Соң син гомереңдә бер тапкыр да мәчеткә бармадыңмыни? – дип сорадым аптырагач.

– Кечкенә чагымда бабай белән баргалаган булды үзе. Ул вакытта тезләрем ышкылыр дип тә борчылмый торган идем. Әмма башка мәчеткә барырмын дип уйламыйм, – диде.

Бу сөйләшүебез мине гаҗәпкә калдырды. Бу теманы күтәрүемә бераз уңайсызланып та куйдым. Шулай итеп бер-беребезнең кулларыбызны кысып аерылыштык.

Шул сөйләшүдән соң ике ай вакыт үтте. Миңа аның мәчеттә икәнлеген хәбәр иттеләр. Ике дә уйламыйча мин тизрәк аның янына ашыктым. Мәчетнең ишегалдында, намаз укучылар каршында торуын

күреп алдым. Бу юлы да өстендә яшел кием. Әкрен генә якынрак килдем һәм ишетелер-ишетелмәс тавыш белән аңа:

– Йә, мәчеткә башка аяк та атламыйм дигән идең? – дип дәштем.

Ул җавап бирә алмады, чөнки җансыз тәне яшел япма астындагы табут эчендә ята иде.

Җүнәйд Суави

(төрекчәдән Гөлназ Ситдикова тәрҗемәсе)

Күперләр салучы мөәзин

(мәчет картлары сөйләгәннәрдән)

Бу хикмәтле дә, гыйбрәтле дә хәл булганга инде байтак вакыт узып китте, шулай да авыл халкы аны әле һаман искә ала, туганнарына, шәһәрдән кайткан оныкларына сабак булсын диптер инде, шул турыда хисләнеп-тәэсирләнеп сөйли, “үз күзем белән күрим әле” диючене Вәлиәхмәт белән Фәсхетдин яшәгән тыкрыкка алып барып, “экскурсия” үткәреп тә җибәрә.

Безнең авылда Гыйльметдин исемле атаклы нәселле бер карт яшәгән иде. Карчыгы Гөлнисә апа белән бик тату, матур яшәп, 6 малай үстергәннәр. Шушы алты малайның берсе генә авылда калып, башкалары кайсы кая – төрле якларга таралыштылар, зур дәрәҗәләргә ирешеп, үзләре урнашкан шәһәрләрдә мәртәбәле затлар булдылар. Авылда калган төпчекләре Вәлиәхмәт исә, артыгына кызыкмыйча, СПТУда трактарчыга укыды да, колхозга эшкә урнашты. Тора-бара үз эшенең остасы булды, район күләмендә үткәрелгән чараларда макталып, грамоталар алды, күрше авыл кызы Гөлбизәне үзенә каратып, өйләнеп тә куйды, әтиәнидән мирас итеп калган йортны төзекләндереп, гаиләсе белән шунда матур гына яшәп китте.

Ямьле җәйләрнең берсендә, әниләрен соңгы юлга озатырга дип читтәге биш абыйсы кайтып төшкәч, төп нигезнең хәйран калырлык үзгәрүенә – барлык уңайлыклар булуына, каралты-кураның төзеклегенә, бакчаның пөхтәлегенә исләре китеп, алар төпчек энеләренең уңганбулганлыгына шаккатканнар иде. Хәтта: “Без шәһәрдә машина төтене сулап, “таш капчыкта” тилмереп яшәп ятабыз, ә син монда саф һавада, табигать хозурында рәхәтләнеп яшисең икән!” – дип көнләшеп тә куйдылар. Шунда Фәсхетдин исемле уртанчы абыйсы, бакча ягындагы күрше җир кишәрлегенә күзе төшеп:

– Якутия якларында байтак хезмәт иттем, туган авылыма кайтып, монда төпләнергә исәпләп торам. Бакча күршебез Мәфруза апа инде вафат дип ишеткән идем – туганнары поджумнарын сатмаслармы икән? – дип сорады.

– Әйе, Мәфруза карчык былтыр гүр иясе булды, шуннан бирле йорты буш тора, кызының кайтканы юк, – дип белгәнен җиткерде Вәлиәхмәт.

Озак вакыт үтмәде – Мәфруза карчыкның кызы шәһәрдән кайтып, нигез йортлары торган участокны каралтылары, бакчасы белән бергә Фәсхетдингә сатып, китеп тә барды. Фәсхетдин якуттан шактый зур мал белән кайткан, күрәсең: җыен иске-москыны сүттереп, ике ай эчендә диярлек, йортын өч катлы, биек һәм затлы итеп салдырып куйды. Вәлиәхмәтнең моңа исе китмәде, кулыннан килгәнчә абыйсына булышты да әле ул, ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, хатынының күңеленә көнче корты кереп, җелеген кимерә башлагач, хәлләр үзгәрде.

– Ыштуты! Имеш, кәттиҗ сала! Безне уздырам дип юри кылана бит ул, дөмеккере! – дип мырлавына Вәлиәхмәт башта игътибар итмәде, ләкин хатынының килендәше белән аралары бозылып, тегесе дә ирен котырта башлагач, ике гаилә арасындагы мөнәсәбәт тагын да начарайды: төрле юк-барны да сәбәп итеп, Фәсхетдин белән Вәлиәхмәт үзара әрләшә башлады, ә көннәрдән бер көнне... шайтаннарның олысы килеп вәсвәсә салгандыр – ике бертуган арасында зур җәнҗал купты... Аларның кычкырышулары күршеләренә җәйге аяз кичтә күк күкрәүне хәтерләтте: авылда мондый дауның инде күптән купканы юк иде.

Бу хәлләрдән соң Фәсхетдин белән Вәлиәхмәт бөтенләй аралашмый башлады. Алай гына да түгел – бер-берсен күрә алмас булды. Моның белән дә бетмәде: шайтан-ләгыйнь котыртып, Вәлиәхмәт беркөнне тракторын кабызды да, экскаватор чүмече белән ике бакча арасындагы ерганакны зурайтып, буйдан-буйга ярыйсы гына киң һәм тирән чокыр казып куйды.

– Шәп булган! – диде аның хатыны, чокырны күргәч. – Безгә таба бүтән аяк атлыйсылары булмасын!

Шайтан-ләгыйнь Фәсхетдиннәргә дә кереп, күңелләрен үч алу теләге белән мөлдерәмә тутырган, ачу капчыкларын шартлардай хәлгә җиткереп, бу хәлләргә шатланып, бик канәгать булып киткән.

– Ничава-а! Сезгә керү түгел – үзегезне дә, йортыгызны да күрмәслек итеп биек киртә ясатачакмын! Потыгыз бер тиен!

Өен район үзәгеннән килгән төзүчеләр эшләгәнлектән, Фәсхетдин энекәшеннән башка биек киртә тота алырдай балта остасын белми иде. Сораштыра торгач, аңа Нургали исемле бер абзыйны тәкъдим иттеләр. Нургали абый бик өлкән яшьтә булмаса да, даими мәчеткә йөри, шунда азан әйтә торган ыспай гына кыяфәтле, матур кәләпүшле 60 яшьләр тирәсендәге ир заты булып чыкты. Фәсхетдин гозерен аңлаткач, ул ялындырмый-нитми генә ризалашып, базар көнне иртүк килермен дип вәгъдә биреп калды.

Якшәмбе иртән инструментлары белән килгән Нургали абыйга эшне төгәл аңлатып, булачак киртәнең урынын һәм әзерләнгән агач материалларын күрсәткәннән соң, хуҗа кеше, күңелендәге ярсуын яшерә алмыйча, кулы белән һава яра-яра катгый күрсәтмәсен бирде:

– Киртә биек булсын, рәшәткә такталары арасында бернинди дә ярык калмасын – озак еллар дәвамында бик нык “глухой” забор булып торсын!

Шулай кызарынып-бүртенеп үз сүзен әйткәч, базардан кирәк-яраклар аласы бар дип, Фәсхетдин һәм аның хатыны машиналарына утырып, район үзәгенә чыгып китәләр. Шунда базар-кибетләрдә йөргәннән соң, туганнарына кереп чәйләр эчә-эчә гәпләшеп утыргангадыр, көн узып китүе сизелмичә дә кала, һәм авылга алар шәфәкъ вакытында гына әйләнеп кайта. Капка төбендә аларны Нургали абый каршы ала.

– Эшемне төгәлләдем, кабул итеп алыгыз! – ди ул, иске машинасына эш коралларын урнаштырып. – Бик тырышып, төшке ашка һәм өйлә белән икенде намазларына гына бүленеп, көне буе эшләдем…

Фәсхетдин ишегалды, каралтылары аша тиз генә үтә дә, җил-җил атлап, бакчаның икенче башына ашыга. Әмма килеп җитүгә ул кинәт туктап кала һәм артта басып торган балта остасыннан калтыраган тавыш белән сорый:

– Бу… нәрсә?..

– Нәрсә-нәрсә… Күрмисеңмени – күпер… – дип тыныч кына җавап бирә оста.

Чыннан да, моңарчы ике бакчаны аерып торган шыксыз чокыр аша үзе гади, ләкин җиренә җиткезеп эшләнгән култыксалы матур агач күпер сузылып ята иде. Гаҗәпләнүеннән нәрсә әйтергә дә белмичә аптырашта калган Фәсхетдин бермәл сүзсез тора. Соңыннан тыныч ланып бераз хушына килгәннән соң, ул күпернең икенче башына күз сала. Батып баручы кояш нурларында шатлык-сәгадәт хисләрен балкытып, анда энекәше Вәлиәхмәт авызын ерып басып тора иде. Нәрсә эшләгәнен әле аңлап бетермичә, Фәсхетдин дә киң итеп елмаеп җибәрә, аннан, күпергә басып, алга таба атлап китә. Вәлиәхмәт тә көттереп тормый – елмаюын югалтмыйча, Фәсхетдиннең каршысына килә.

– И абый, бик шәп нәрсә уйлап тапкансың бит әле син, ә, ну абыый… – ди Вәлиәхмәт, Фәсхетдинне кочагына алып, һәм аркасына суккалый-суккалый: “Син мине, җүләрне, гафу ит инде, яме!” – дип үкенгәндәй өстәп куя.

– Мин дә кичерәм, син дә кичер – бәхилләшик, энекәш! Һәм бүтән болай ямьсезләнеп кыланмыйк, – дип җаваплады Фәсхетдин, бугазына төер утырганын тоеп. – Әрләшмик, матур яшик… Бу өч көнлек дөньяда барыбызга да урын җитә…

Шулай итеп, шайтан аерып, дошманлаштырып куйган ике бертуган янә дуслашып, туганлык җебен яхшылап беркетеп куя. Нургали абыйны озатканда, Фәсхетдин рәхмәтләрен әйтеп, эш хакын түли дә, хуҗалыкта әле тагын эш булганын әйтә:

– Күңелең дә чиста, кулларың да оста – иртәгә дә кил әле син безгә, Нургали абый!

– Булмастыр, авылдаш, – дип баш тарта бу тәкъдимнән мөәзин. – Иртәгә күрше авылда нәкъ шундый ук күпер ясыйсым бар. Нишләмәк кирәк – кирәге чыга да тора, чыга да тора...

Кояш баегач, мәчет манарасыннан моңлы азан тавышы яңгырады. Ахшам намазына чакырып, мөәзин авыл кешеләре белән Аллаһ арасында гаҗәеп күпер салды. Чакыруны кабул итүчеләр шушы күпер аша Раббыларына таба атлады.

Тирә-юньдәге кешеләрне үзе төзегән күперләре аша татулаштырган, бәхет-тәүфыйк сукмагына юнәлткән Нургали абый озак еллар дәвамында шушы изге-игелекле эшне башкарганнан соң, былтыр Рамазан аеның җомга кичендә җан тәслим кылды. Авыл кешеләре аны әле дә яратып, хөрмәт итеп телгә ала. Ә ул салган күпер аша узып үз кыйбласын табучылар, югалткан кадерле туганын кайтаручылар рәхмәтләрен белдереп кенә калмыйча, аның рухына ихлас дога кыла, “күперләр салучы мөәзинебез урыны җәннәтнең түрендә булсын” дип Аллаһтан сорый, ди... Бик үтенеп сорый...

Ришат Курамшин,

Кукмара мәдрәсәсе мөдире

Карга бәхете

Күпмедер вакыт тыныч кына яшәгәннән соң, бүген Гүзәлнең кәефе тагын кырылды. Инде ничәмә-ничә тапкыр үз-үзенә кино һәм концертлар карамаска вәгъдә бирсә дә, әнисе телевизорны кабызгач, күзе төште шул, нишләмәк кирәк... Әнисенә ул бу хакта берни әйтми, ләкин үзе концерт-кинолардагы матур артистларны күрсә, шундук төшенкелеккә бирелә. Моның сәбәбе шунда – чибәр артист кызлар күзенә ташланып кына китсә дә, Гүзәл аларга кара көнләшү белән карап, бик борчыла иде, чөнки исеме Гүзәл булса да, кыяфәте... кем әйтмешли, кыз бу дөньяга җисеме исеменә туры килмичә, ямьсез булып туган. Әллә яшьтәш кызлары бер-бер артлы кияүгә чыга башлагангамы, әллә башка вәсвәсәләр тәэсирендәме, 23 яшен тутыргач, Гүзәл үзенең әлеге кимчелегенә аеруча сизгер була башлады.

Икенче көнне эштән кайтканда, Гүзәл, әрнүле йөрәген тынычландырырга теләп, сәдака салырга дип мәчеткә кереп чыгарга булды. Кизү торучы бабайга гозерен аңлаткач, ул аны имам бүлмәсенә кертеп җибәрде:

– Бар, сеңлем, хәзрәт янына кереп, бер дога кылдырып чык. Кәефең дә шәптән түгел бугай – борчыган мәсьәләңне аңлат, шәт иншә Аллаһ, берәр киңәш бирер...

Шундый җылы, йомшак мөгамәлә күрсәтелгәнгәме, имам бүлмәсенә кергәндә, Гүзәлнең күңеле тәмам тулган иде.

– Сәдака бирергә килдем... Дога кыла алмассызмы... – дип авызын ачуга, Гүзәл күз яшьләрен тыя алмыйча елый башлады. Мәчеттә инде озак еллар эшләп, мондый күренешләргә күнеккән өлкән яшьтәге имам, бер дә исе китмәгәндәй, урындыкка ишарәләп, тыныч кына болай диде:

– Бер ни эшләп булмый, кызым, бу дөньяга килгән кеше кайчандыр китәргә дә тиеш... Кемегез вафат?

– Беркем дә вафат түгел... Башка нәрсә борчый мине... – диде Гүзәл, бетчәле битеннән күз яшьләрен сөртә-сөртә. – Башка кызлар шундый матур-чибәр, ә мин... Нигә бу дөньяга шундый шыксыз булып туганмын икән?..

Каршысындла утырган кызның чыннан да иләмсезрәк булган йөзенә бер карап алганнан соң, хәзрәт Коръән укый башлады. Аның тәэсирләнеп, күңелгә ятышлы мәкам белән ихластан укуыннан Гүзәл тынычланып китте, хәзрәт дога кылганда исә, бер-ике генә сулкылдап алып, "әмин-әмин" дип утырды.

Дога кылып бетергәч, инде шактый тынычланган кызга ягымлы дәшеп, хәзрәт шулай диде:

– Авыру кызга охшамагансың, сәламәт кул-аякларың, күз-колагың булганда, нәрсәгә борчылырга?

– И, абый, алай түгел ул, тормышта бәхетен табар өчен хатын-кызга күркәм кыяфәт тә бик кирәк ул. Әнә, бергә укыган сыйныфташларым инде кияүгә дә чыгып бетә яздылар, ә мин... мондый килбәтсез кемгә кирәк соң инде, йә?

– Күктә никах укылмаса, җирдә дә ул укылмас, күктә никах укылса – җирдә чарасы калмас... Бер дә борчылма, өлешеңә тигән көмешең барыбер синеке булачак, иң мөһиме – күңелең матур булсын, – дип тынычландырып карады Гүзәлне имам.

– И, хәзрәт, менә телевизордагы җырчы кызларга, кинолардагы артистларга карасам, йөрәгем бигрәкләр дә өзгәләнә башлый минем, – диде Гүзәл. – "Менә кемнәр бәхетле!" дип көнләшеп тә көнләшәм мин, аларны күрсәм.

– Юкка, кызым, әй, юкка... – диде имам, күзләрен серле кысып. – Менә мин сиңа бер әкият сөйлим, тыңла да – нәтиҗәне үзең ясарсың...

...Зур, куе урманда яшәгән ди бер карга. Бернигә борчылмыйча, тыныч кына шулай яшәгәндә, көннәрдән бер көнне урман читендәге күлдә ул аккошны күрә. Аның матурлыгына исе китеп, карга хөсетләнеп уйлап куя: "Ул шундый ап-ак, ә мин... шундый кара... Бу гаҗәеп аккош дөньядагы

иң бәхетле коштыр”. Шушы фикерләрен ул аккошның үзенә дә ирештерә. Ләкин аның җавабы карганы аптырашта калдыра.

– Дөрестән дә, моңарчы мин үземне дөньядагы кошларның иң матуры, иң бәхетлесе дип тойган идем, ләкин… тутый кошны күргәч, моның шулай түгеллеген аңладым: мин бит, мескен, бер төсле генә, ә попугай – ике-өч төсен ялтыратып горур утыра! Менә кем бәхетле!..

Бу сүзләрне ишеткән карга тутый кошны эзләп очып китә. Эзләп тапкач, мәсьәләне аңлата да:

– Димәк, кошлар арасында иң матуры, иң бәхетлесе син? – дип сорый.

Әмма попугайның җавабы да көтелмәгәнчә була:

– Байтак вакыт мин дә шундый фикердә идем, ләкин… тавис кошын күргәч, шаккаттым: менә ул чын матурлык! Миндә бит беткәнче ике-өч төс кенә, ә павлинда… Юк, иң матур һәм иң бәхетле кош – ул, һичшиксез, тавис…

Шушы дөньядагы иң бәхетле кошны кайда күреп була икән, дип кызыксынгач, тутый кош зоопаркка очарга кушты. Шунда килеп җиткәч, попугай тавис читлеге янындагы дистәләгән кешене күреп, хәйран кала. Кешеләрнең һәммәсе дә соклану белдереп, тел шартлата-шартлата, купшы койрыклы тависның матурлыгын мактый иде. Зоопаркның эш вакыты чыгып, кешеләр таралышып беткәч, карга тависка эндәшә:

– Кадерле, хөрмәтле тавис! Син шундый матур! Көн саен йөзләгән, ә ай дәвамында, бәлки, меңләгән кеше сине карарга дип килә, мактый, хозурлана, соклана… Ә менә алар мине күрсәләр, бер дә сокланмыйлар, әле куып та җибәрәләр. Шулай булгач, син – дөньядагы кошларның иң бәхетлесе!

Канатлы кардәшенең аны олылап шундый сүзләр әйткәненә карамастан, тавис моңсу иде. Ул, боек һәм кызганыч тавыш белән, ачынып, болай ди:

– И, карга-карга… Читтән караганда гына бу шулай. Чынбарлыкта исә шушы матурлыгым аркасында мин читлектә гомер кичерергә мәҗбүр. Әле кичә генә, беләсеңме, нәрсә уйлап куйдым? Шушы зоопаркның

читлекләрендә нинди генә кошлар юк, ләкин берсендә дә каргалар күренми. Мин, беләсең килсә, шундый нәтиҗәгә килдем: бу дөньядагы кошларның иң бәхетлесе – ул, әлбәттә, карга. Минем бик тә, бик тә карга буласым килә! Карга булсам, кайда телим – шунда очар идем, нәрсә телим – шуны эшләр идем... Бәхетләләрнең бәхетлесе – ул син, сөекле карга!

Хәзрәтнең хикәятен тын да алмыйча, дулкынлануыннан йодрыкларын йомарлап куеп тыңлаган Гүзәл шушы мизгелдә сискәнеп куйды. "Вәт җүләр икән мин, җүләр! Шул бәхетле карга – мин бит инде ул!" – дип уйлап куйды ул эчтән генә.

– Менә шулай, матурым! – диде имам, әкиятен тәмамлап. – Әйе, әйе – матурым! Ихлас елый белгән кешенең күңеле матур була ул. Әйдә, бер дә борчылма, Аллаһы Тәгалә биргәненә шөкер итеп яшә. Кияүгә чыгасы булсаң, никах укырга миңа әйтерсең...

Өенә кайтканда, Гүзәл хәзрәт сөйләгән әкиятнең эчтәлеген башында кат-кат әйләндерде. "Чыннан да, үземне башкалар белән чагыштырып, бик ялгышканмын икән", – дип уйлап барды ул. Телевизордагы "тавис кошлары" да аны инде бүтән борчымады. Кем белгән, бәлки, алар да читлектәге кошлар кебек бәхетсездер? Юк, Гүзәл аларның бәхетсез булуларын теләми иде, юк. Шунысы гына мөһим: бу вакытта аның күңелендә матурлыгын сөйләп, аңлатып бетереп булмый торган бер чәчәк үсеп чыкты. Шушы чәчәк белән бергә ул күңелендә сөенечле өмет тә барлыкка килгәнен тойды. Бүген, шулай итеп, моңарчы бик олы булып тоелган үзен башкалар белән чагыштыру бәхетсезлеге нәни генә булса да "карга бәхете" белән алышынды. Аның күңелендә ул әле бик кечкенә чәчәк үсентесе хәлендә генә булса да, Гүзәл шул чәчәкнең ныгып үсеп китүенә инде шикләнмәде. "Иң мөһиме – күңелең матур булсын... Аллаһ биргәненә шөкер итеп яшә..." – дип исенә төшерде ул хәзрәт киңәшен, өенә кайтып кергәндә.

Ришат Курамшин,

Кукмара мәдрәсәсе мөдире

Гашура бәйрәме

Мөхәррәм ае турында
Уйлап караган бармы?
Тарих битләрендә аннан
Бик күп вакыйга калды.

Күкләр, җирләр яратылган,
Таулар хасил булганнар.
Адәм-Хава халик булган,
Йолдызлар балкыганнар.

Гашурә көн-шушы айның
Иң гүзәл бер бизәге.
Ураза тотып бу көнне,
Гыйбадәт итик әле.

Муса, Гайсә, Нух пәйгамбәр
Котылган көн газаптан.
Чын күңелдән ярдәм сорый
Белгән алар Аллаһтан.

Белеп яшик бәйрәмнәрнең
Нигә кирәк икәнен?
Гыйлем туплап, үзебезгә
Ачыйк җәннәт ишеген.

Гашура көн

Гашүрә көн туды, һәркем белә
Бу бәйрәмнең ерак асылын.

Пәйгамбәрләр тарихыннан укып,
Кабул итә шуны акылым.

Нух пәйгамбәр суга батмый, кавем
Явызлыктан шулай котылган.
Муса пәйгамбәр дә фиргавеннән
Бер Аллаһка барып сыенган.

Бәрәкәтле көн ул- Гашура көн,
Уразага керә кешелек.
Аллаһ ярдәменә таянганнар
Аннан ярдәм көтә иң элек.

Иман нуры булсын күңелләрдә,
Кылган гөнаһ тәүбә ителсен.
Ышанычны саклау бер Аллаһка
Һәр кешегә бәхет китерсен.

Хаҗ

Хаҗ кылу-олы гыйбадәт,
Көче җиткән кешегә.
Фарыз гамәлләрнең берсе-
Иман китергәннәргә.

Мәккәи Мөкәррәмәдә
Изге йорт-Кәгъбәтуллаһ.
Көче җитеп хаҗ кылуны
Кабулдан кылсын Аллаһ.

Изге йорт, мәчет Әл-Хәрам,
Пәйгамбәр узган җирләр.
Хак юлны тапкан кешегә
Аллаһ рәхмәте иңәр.

Ашыгалар хаҗ кылырга,
Һәр эшнең үз вакыты.
Ният итеп, хаҗ кылулар,
Яшьлектә насыйп булды.

Аллаһтан башка иләһ юк,
Хакимлек һәм аңа дан.
Мөмкинлекне ычкындырма,
Яшь чагында хаҗга бар.

Мең мәртәбә өстенерәк,
Хәрамда кылган намаз.
Хаҗны берни алыштырмый,
Ният итеп куегыз!

Йә, Аллаһым, синең алда,
Хаҗым кылам, кабул кыл!
Гөнаһларымны ярлыка,
Бирче миңа дөрес юл.

Лә иләһә иллә Аллаһ,
Кабулдан булсын намаз.
Раббым ризалыгы өчен,
Хаҗ кылу тиеш, фарыз.

Дөньяда да, ахирәттә
Ирешим рәхмәтеңә.
Аллаһ Раббым, ирештер син
Фирдәвес җәннәтенә.

Аклыкка илтсен юллар

Аклыкка илтсен юллар,
Тагы күпме гомер бар?
Билгесез безнең яшәеш,
Үзе киң ул, үзе тар.

Җитми сыман дөнья малы:
Кеседән ага, кулдан.
Кем дә туктатмый: Кара,-дип,
Чыгып барасың юлдан!

Киңлек беркөн тарая,
Вакыт шунда туктала.
Аңлый һәркем соңарганны,
Тиеш юлны сайларга.

Аклыкка илтсен юллар,
Һәркемгә мөмкинлек бар!
Билгесез безнең яшәеш,
Үзе киң ул, үзе тар!..

Нурфия Халикова, Казан шәһәре